А. И. Кравченко, Е.А. Певцова

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

11

СЫЙНЫФ

«РУССКОЕ СЛОВО»
«ХӘТЕР»

11
А. И. Кравченко, Е.А. Певцова
ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

А.И. Кравченко, Е.А. Певцова

ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ

11 сыйныфы өчен дәреслек

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Тәрҗемә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган

Москва
«Русское слово»
2009

Казан
«Хәтер»
2010

ББК 60я72
К78

Авторлар:
2, 3, 4, 5 нче бүлекләр – *Кравченко А.И.*, социология фәннәре докторы, профессор;
1 бүлек – *Певцова Е.Л.*, педагогика фәннәре докторы һәм хокук фәннәре докторы.

Сериянең художество бизәүчесе: *Войткевич Т.Н.*
Рәссамнар: *Сергеев В., Шабельник Е.С., Путина Л.Н.*

Тышлыкта *Пауль Клееның* «Физиогномик этюд. Яшен» картинасының бер фрагменты кулланылды. – 1927 ел.

Методик аппаратны эшләүдә *Хромова И.С.* катнашты.

Кравченко А.И., Певцова Е.А.
Җәмгыять белеме : 11 с-ф өчен д-лек. / Русчадан Р.Хәмидуллина тәрж.— Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты ҖЧҖ, 2010. – 183 б.

ISBN 978-5-94113-329-1

Әлеге дәреслек җәмгыять белеме буенча дәреслекләрне төгәлли. Биредә социология, хокук, мәдәният нигезләре тагын да тирәнрәк һәм киңрәк яктыртыла.

Дәреслек РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы расланган мәҗбүри белемнәр минимумына тулысынча туры килә.

ISBN 978-5-9932-0266-2
ISBN 978-5-94113-329-1

© ООО «ТИД «Русское слово-РС», 2001, 2009
Все права защищены

© Татарчага тәрҗемә, Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты ҖЧҖ, 2010
Барлык хокуклар сакланган

Эчтәлек

1 (7) бүлек. **Закон һәм хокук**

§ 1 (§ 22). Хокукның барлыкка килүе, аның рәвешләре һәм структурасы....4
§ 2 (§ 23). Хәзерге Россиядә гадел хөкем....15
§ 3 (§ 24). Хокук бозулар һәм юридик җаваплылык....22
§ 4 (§ 25). Хосусый хокук....32

2 (8) бүлек. **Җәмгыятьнең социаль системасы**

§ 5 (§ 26). Социаль стратификация....42
§ 6 (§ 27). Социаль хәрәкәтчәнлек (мобильлек)....51
§ 7 (§ 28). Гаилә һәм никах....59

3 (9) бүлек. **Кешеләрнең җәмгыятьтәге бәйләнеше**

§ 8 (§ 29). Социаль үзара мөнәсәбәт....67
§ 9 (§ 30). Низаг һәм каршылык хәрәкәте....74
§ 10 (§31). Социаль контроль....84
§ 11 (§ 32). Тайпылышлы һәм хокукка каршы тәртип....92

4 (10) бүлек. **Мәдәният һәм рухи хәят**

§ 12 (§ 33). Мәдәниятнең этик нигезе....97
§ 13 (§ 34). Әхлак хисләре һәм кешенең моральгә нигезләнеп үз-үзен тотышы....103
§ 14 (§ 35). Әхлакый категорияләр һәм игелек....111
§ 15 (§ 36). Бәхет, ләззәт, гедонизм....118
§ 16 (§ 37). Гаделлек һәм тигезлек....127

5 (11) бүлек. **Кешенең күңел дөньясы һәм социальләшүе**

§ 17 (§ 38). Кеше психикасының төзелеше....134
§ 18 (§ 39). Кеше психикасы һәм аңының элементлары....140
§ 19 (§40). Җәмгыятьнең шәхескә йогынтысы....146

Йомгаклау....154

Сүзлек....161

1 (7) бүлек

Закон һәм хокук

§ 1 (§ 22). Хокукның барлыкка килүе, аның рәвешләре һәм структурасы

Бик борынгы заманнардан ук кешеләр хокук ул аллалар ихтыярының гәүдәләнеше дип ышанганнар. Илаһтан иңгән мәрхәмәт нәтиҗәсе буларак, законнар гомерлек дип уйланылган. ***Дини теория*** тарафдарлары Ходайдан килгән хаклык һәм гаделлек идеаллары нигезендә законнар тормыш тәртибен билгели дип фикер йөрткәннәр. Гасырлар дәвамында, кайбер фикерләре үзгәреш кичерсә дә, алар хокукны өстен көчләр булдыруы турындагы карашларны яклый килгәннәр. Үз инануларының хаклыгын исбатлау өчен алар күп кенә мисаллар китергәннәр: борынгы һиндлеләрнең юлбашчылары булган Ману б.э. кадәр I гасырда, аллалар белән бәйләнешкә кереп, алардан законнар язып алган (Ману законнары); б.э. VII гасырында Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы сүзләрен мөселманнарның изге китабы Коръән рәвешендә җиткергән; яһүдиләр пәйгамбәре Муса (Моисей) 40 көн буена Синай тавында ходай белән әңгәмәдәш булган, Яхве әйткәннәрне күрсәтмәләр рәвешендә ташларга язып калдырган һәм болар киләчәктә хокукый күрсәтмәләргә нигез итеп алынган. Күп кенә илләрдә (Иран, Пакъстан, Судан, Согуд Гарәпстаны һ.б.) дәүләтнең хокукый системасы дини нормаларга корылган.

Табигый хокук теориясен яклаучылар, дини теория тарафдарларына каршы төшеп, хокукның табигать, кеше тарафыннан барлыкка китерелүен исбатларга тырышалар. Кеше дөньяга үзенең аерылгысыз табигый хокуклары белән туа (тереклек хокукы, иреккә хокук).

Борынгы грек философлары ***Гиппий*** (б.э. кадәр 528–510 еллар), ***Аристотель*** (б.э. кадәр 384–322 еллар) һ.б. хокукны кешеләргә табигать тарафыннан бирелгән иң бөек хакыйкать дип саныйлар. Хокукны шулай ук һәркем өчен уңайлы тәртип саклау чарасы буларак кешеләр дә булдырырга мөмкин, дәүләт исә соңрак аны законнар калыбына сала. Урта гасырларда: хокук ул — кеше акылының гәүдәләнеше, дигән карашлар өстенлек итә (***Г.Гроций***, 1583–1645 елларда яшәгән акыл иясе). Француз философы ***Вольтер*** (1694–1778) һәркемнең табигый хокукка ия булуын һәм аны инкарь итү яисә тартып алу тыелуын искәртә.

Хәзерге вакытта хокукның барлыкка килүен төрлечә аңлата торган күпсанлы теорияләр барлыкка килде. ***Реалистик хокук теориясе тарафдарлары Р.Иеринг*** (1818–1892) һ.б. аның килеп чыгышын көчлеләрнең җиңүе белән тәмамланган сугышлар һәм хәрби конфликтларга бәйләп карыйлар. Җинелгәннәр җиңүчеләр урнаштырган кагыйдәләргә һәм тәртипләргә буйсынырга тиеш була. Нәтиҗәдә хокук җәмгыятьнең үсешенә йогынты ясаучы билгеле бер көч буларак күзаллана.

XX гасыр урталарында ***хокукның социологик теориясе*** формалаша. Аның тарафдарлары (***Р.Паунд*** (1870–1964) һәм башкалар) хокукны нормалардан түгел, бәлки чынбарлыктан эзләргә кирәклеген искәртәләр. АКШның һәм Скандинавия илләренең хокук мәктәпләре әлеге карашларны хәзер дә алга сөрә. Аларның вәкилләре кешеләр бер-берсе белән аралашканда гаделлек принципларына нигезләнгән һәм үзләре өчен уңайлы тәртип кагыйдәләрен үзләре үк уйлап таба дип раслыйлар. Дәүләт әлеге нормаларны, аларга мәҗбүрилек характеры биреп, санкцияли генә.

Хокукның төрлечә аңлатылуы үзенең табигате буенча бу күренешнең гаять катлаулы булуын, аны гади шәрехләүгә кайтарып калдырырга ярамавын дәлилли. Болар һәммәсе заманыбызның юридик теориясендә һәм практикасында хокукны шәрехләүдә төрлелек китереп чыгарды. Хәзергә кадәр хокукка бердәй аңлатма бирелмәгән. Хокук дигәндә, объектив мәгънәдә юридик нормалар системасы, ә субъектив мәгънәдә затларның үз-үзләрен тотышы мөмкинлекләре күздә тотыла (РФ гражданы референдумда катнашырга хокуклы һ.б.). Сүзнең мәгънәләре күптөрле. Әмма мондый хәл хокук төшенчәсе белән генә бәйлеме? Җәмгыять белемендә күп мәгънәле төшенчәләр

бик күп. Моның белән илебез галимнәре дә, чит ил галимнәре дә килешергә мәҗбүрләр.

Хокукның җәмгыятьне оештыруга, низагларны булдырмауга ярдәм итеп, аннан аерылгысыз яшәвен таныгач, аңа заманча аңлатма бирик. ***Хокук — җәмгыять тарафыннан гомум хакыйкать принципларына нигезләнеп барлыкка китерелгән яисә дәүләт хакимияте билгеләгән һәркем өчен мәҗбүри тәртип кагыйдәләре системасы ул, аларны бозган өчен дәүләт тарафыннан чаралар (санкцияләр) куллану һәм юридик җаваплылык каралган.***

Хокукка түбәндәгеләр хас:

а) үтәлеше һәркем өчен мәҗбүри булу;

б) чыганакларда бәян ителү (Россиядә болар нигездә норматив хокукый актлар);

в) дәүләт тарафыннан мәҗбүриләү мөмкинлеге булу.

Россия хокукы нигезен түбәндәге төп принциплар тәшкил итә:

— ***гаделлек принцибы.*** Юристлар, мәсәлән, бер җинаять өчен җәзаның бер тапкыр гына бирелергә тиешлеген; тәртип бозган өчен җинаять җаваплылыгына тарту, фикерләре, уйлары күпме генә мәкерле булмасын, алар өчен кешеләргә җәза бирелмәвен; хезмәткә түләүдә дискриминация тыелуын һ.б. яхшы беләләр;

— ***гадел хөкем принцибы*** һәр кешенең суд аша үз хокукларын якларга хакы барлыгын аңлата;

— ***кешеләрнең тигез хокуклылыгы принцибы.*** Кешеләр бер-



берсеннән яше, милләте, социаль хәле, дине һәм башка яклары белән аерылсалар да, алар барысы да бертигез конституциячел хокукларга ия.

Юристлар хокукый системаның асылын аңлату өчен түбәндәге терминнарны кулланалар.

ХОКУКЫЙ СИСТЕМА — хокук нормалары, институтлары, тармаклары, кешеләрнең хокукый гамәлләре һәм культурасы үзенчәлекләрен үз эченә ала торган хокукый күренешләр комплексы.

Дөньяда төрле хокукый системалар бар. ***Англия-Саксония хокукый системасы*** Англиядә, АКШ, Австралия, Канада һәм башка илләрдә барлыкка килә. XI гасырда Англия территориясендә үзәкләштерелгән суд системасы булдырыла башлый. Корольлек судьялары төрле урыннарга барып, корона исеменнән катлаулы юридик дәгъваларны хәл итә торган булалар. Охшаш эшләрне тикшереп хәл иткәндә, алар чыгарган карарлар өлге буларак кулланыла. *Прецедент хокук* шулай барлыкка килә.

ПРЕЦЕДЕНТ (лат. praecedens — моннан алдагы) — судның яисә вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи затның алга таба охшаш эшләрне хәл иткәндә кулланма буларак файдаланыла торган конкрет карары.

Хәзерге Англиядә прецедентларны бары югары суд инстанцияләре: Лордлар палатасы, Яшерен советның суд комитеты, Апелляция суды һәм Югары суд кына булдыра ала. Алар: хокук җәмгыятьтә туа, алдарак нинди карар кабул ителгән булса, хәзер дә шундыйны ук кабул итәргә кирәк, дигән карашка таянып эш итәләр («Stare decisis» кагыйдәсе). Англиядә 500 меңнән артык прецедент практикада кулланыла. Инглизләр гомуми хокукка, аның беркайда да язылмавын сылтау итеп, катгый билгеләмә бирмиләр, прецедентларга мөрәҗәгать итүне кулайрак күрәләр.

Европаның, Латин Америкасының, Африканың күп кенә илләре ***роман-герман хокук системасы*** кысаларында көн күрәләр. Мондый хокук XIII гасырда әле хәзер дә үз әһәмиятен югалтмаган мәшһүр Рим хокукының киң таралуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Закон

чыгаручылар хокукны гомумиләштереп, аны юридик нормалардан торган законнар һәм аларга бәйле актлар рәвешендә рәсмиләштереп эшлиләр.

Төп һәм икенчел әһәмияттәге нормалар була. Теләсә кайсы судья дәгъваны дәүләт исеменнән тикшереп хәл иткәндә законга таяна, билгеле очракларда аның гомумиләштерелгән тәгъбирләрен куллана. Роман-герман хокукый системасында хокук *ачык* һәм *хосусый* төрләргә бүленә.

Ачык хокук төре дәүләт мәнфәгатьләренә кагыла торган мөнәсәбәтләрне җайга сала. Гадәттә хокукый ситуациядә катнашучыларның берсенә боеру вәкаләтләре бирелә. Мәсәлән, милиционерның һәм җәмәгать тәртибен бозган гади гражданның вәкаләтләре бертигез була алмый. Милиционерга законлы боеру вәкаләтләре бирелә, шуңа күрә ул штраф сала яисә башка төрле чаралар куллана ала.

Хосусый хокукта барлык субъектлар тигез була һәм аларга гамәлләр кылуда күбрәк ирек бирелә. Эшкуарлык даирәсендә партнерлар, ата-аналар һәм балалар, ир һәм хатын һ.б. арасындагы мөнәсәбәтләр шушы ысул белән җайга салына.

Хәзерге заманда юридик фән **хокукый норманы** ул гамәлдә булган өлкәдә эш йөрткән субъектлар (кешеләр, оешмалар) тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле тәртип кагыйдәләре буларак аңлата; ул язма формада рәсми документларда теркәлә (хокук нормасы норматив хокукый актта теркәлергә мөмкин); дәүләткә мөнәсәбәтле (хокук нормасы бозылган очракта, дәүләт аны үтәргә мәҗбүр итә); субъектларның хокукларын һәм бурычларын билгели.

Хокукый нормалар күп рәвешле һәм күп төрле булалар. Алар гражданнарның үз-үзләрен тотышын тормыш-көнкүрешнең барлык өлкәләрендә — автотранспортта, кибеттә товарлар сатып алганда, эшкә урнашканда һ.б. — җайга салалар. ***Хокукый нормалар бер-берсеннән гамәлдә булу вакытлары белән аерылырга мөмкин***. **Даими** нормалар законнарда теркәлә һәм алар чагыштырмача озак гамәлдә була. **Вакытлы** нормаларның исә гамәлдә булу вакыты чикле. Мәсәлән, РФ Президентының акча тамгаларын алыштыру турындагы Указы нормалары нәкъ шундыйлардан иде.

Әмма хокукый нормалар, күпме генә төрле булмасын, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең җайга салынырга тиешле өлкәсе аларны бер-

берсенә ялгый. Шуңа нигезләнеп хокукый нормалар *институтларга* һәм тармакларга берләштерелә. ***Хокук институты — иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең аерым бер өлкәсен җайга сала торган юридик нормалар төркеме ул.*** Мәсәлән, гражданлык хокукында — милек хокукы институты яисә конституциячел хокук институтында — сайлау хокукы. ***Бер үк төрле иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салучы юридик нормалар һәм институтлар хокук тармагын тәшкил итәләр.***

Дәүләт хокукы яисә ***конституциячел хокук*** илнең дәүләти төзелешен җайга сала, хакимият һәм идарә органнары эшчәнлеге тәртибен билгели, гражданнарның төп хокукларын һәм ирекләрен терки.

Җинаять өчен җәза бирү хокукы кешенең җинаятьчел гамәлләрен, шулай ук аларны кылган өчен җәза чарасын билгели.

Административ хокук — дәүләт идарәсе өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Гражданлык хокукы — мөлкәт мөнәсәбәтләрен, шулай ук мөлкәткә кагылышы булмаган шәхси мөнәсәбәтләрне җайга сала. Мондый хокукый нормалар милек, мирас алу, кешеләрнең һәм оешмаларның вөҗданы һәм абруе мәсьәләләренә кагыла.

Хезмәт хокукы хезмәт процессында һәм хезмәткә кагылышлы мәсьәләләр буенча эш бирүчеләр белән хезмәткәрләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Процессуаль хокук, мисал өчен, җинаятьләрне тикшергәндә, судта җинаять, гражданлык эшләре, бүтән шундый эшләр буенча карарлар чыгарганда һәм башка очракларда юридик нормалар куллануның тәртибен билгели.

Хәзерге заман Россия хокукында яңа тармаклар барлыкка килде: ***муниципаль хокук*** (җирле үзидарә органнарының гражданнар белән мөнәсәбәтләрен җайга сала), ***салым хокукы*** (салым җыю кагыйдаләрен билгели), ***эшмәкәр хокукы*** (эшмәкәрләрнең икътисади эшчәнлекләре кагыйдәләрен билгели), ***компьютер хокукы*** (мәгълүмат әйләнешен хокукый җайга салуны башкара).

ХОКУК ЧЫГАНАКЛАРЫ — хокукый нормаларны чагылдыру рәвешләрен белдерү өчен кулланыла торган юридик термин.

Хокукый йола тарихта беренче хокук чыганагы дип санала. Озак кулланылуы нәтиҗәсендә җәмгыятьтә урнашкан, дәүләт тарафыннан гомуммәҗбүри норма дип танылган тәртип кагыйдәсе бу. Әгәр сез төзүчеләр бригадасы белән килешү шартнамәсен ничегрәк төзәргә кирәклеген белмәсәгез һәм юрист ярдәменнән файдаланырга теләмәсәгез, үрнәкләр (типовой) җыентыгына мөрәҗәгать итегез. Анда шартнамәнең килешүче яклар өчен катгый мәҗбүри булмаган һәм ирекле кулланыла торган үрнәк шартлары китерелә. Суд аларны ***эшлекле әйләнеш йоласы*** буларак исәпкә алырга мөмкин.

Шартнамә хокукның икенче бер чыганагы булып тора. ***Хокукый мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүен, үзгәртелүен яисә туктатылуын раслый торган ике яисә берничә зат арасындагы килешү шартнамә дип атала.*** Шартнамәләр арасында *индивидуальләре* һәм *нормативлары* булырга мөмкин. Күпчелек юристлар, билгеле булмаган яңа тәртип кагыйдәләре барлыкка китерүләре сәбәпле, бары норматив шартнамәләрне генә хокук чыганагы буларак таныйлар. Мәсәлән, Россия һәм Франция арасындагы сәүдә итү турындагы шартнамә яңа хокук һәм бурычларның үтәлүе һәр ике як өчен мәҗбүри булган тулы бер комплексын барлыкка китерә.

Хокукның тагын бер чыганагы — ***прецедент***. Россиядә хокукның иң таралган чыганагы булып ***норматив хокукый акт*** тора. Бу — вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан аерым тәртиптә кабул ителгән рәсми язма документ. Ул хокукый нормаларны билгели, үзгәртә яисә юкка чыгара. Мәсәлән, ветераннар турында кабул ителгән Закон аларга кайбер ташламалар бирүне кертте.

Норматив актлар юридик көчләре ягыннан бертигез булмый. Аларның системасы басмаларын хокукый актлар тәшкил иткән баскычка охшаган. Алар барысы да «өлкәннәр»дән һәм «кече»ләрдән торган бердәм «гаилә»дә яшиләр. Шуның белән бергә, кечеләр өлкәннәргә каршы төшәргә тиеш түгел, дигән гаять мөһим кагыйдә үтәлә.

Төп закон — **Россия Федерациясе Конституциясе** безнең дәүләтебездә иң югары юридик көчкә ия. Аны кабул итүдә илнең барлык гражданнары катнаша. Бу — «гаиләнең иң өлкән әгъзасы». Аннан соң Россия Федерациясе Конституциясендә каралган мәсьәләләр буенча кабул ителә торган **федераль конституциячел законнар** килә.

Норматив хокукый актлар иерархиясе

Федераль законнар аерым бер баскычта торалар. Россиядә законнар *кодлаштырылганнарга* һәм *агымдагыларга* бүленергә мөмкин. Беренче төркемгә — Гаилә кодексы, Җинаять кодексы, Граждан кодексы һәм башка шундыйлар, ә икенче төркемгә, мәсәлән, Федераль бюджет турындагы закон керә. Хәзерге Россиядә ***илнең вәкиллекле органнарының иң югары юридик көчкә ия булган һәм иң мөһим иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган актларын законнар дип атыйлар.***

Ил Президентының норматив актлары (указлары) түбәнрәк баскычта урнаша. Законнардан аермалы буларак, алар шактый тиз кабул ителәләр һәм рәсми басылып чыкканнан соң шулай ук тиз үз көчләренә керәләр. Ил **Хөкүмәте** норматив характердагы **карарлар** кабул итәргә хокуклы; үз көчләренә керү вакыты күрсәтелмәгән очракта, аларның гамәле кул куелганнан соң 7 көн узгач башлана.

Министрлыклар һәм ведомстволарның норматив хокукый актлары киләсе баскычны били. Алар эчтәлекләре ягыннан гаять төрле. Кайберләре гражданнарның хокук һәм ирекләренә кагылышлы, тармакара характерда була. Мондый актларның Юстиция министрлыгында теркәлүе мәҗбүри, һәм алар, теркәлгәннән соң 10 көннән дә сонламыйча, матбугатта басылып чыгарга тиешләр. Бу процедура тармаклар чыгарган актларда гражданнарның хокуклары бозылуга юл куймау өчен башкарыла.



Законның гамәл вакыты

Җирле үзидарә органнары шулай ук **хокукый актлар** кабул итә. Алар бары төбәк территориясендә (край, өлкә, шәһәр) генә гамәлдә булалар. Болар гаять зур норматив актлар гаиләсенең иң «кече әгъзалары».

Барлык норматив хокукый актларның да гамәли чикләре билгеләнгән. Һәрбер юристка ***законның кирегә эшләү*** көче юк дигән принцип яхшы таныш. Ул түбәндәгеләрне аңлата: норматив хокукый актлар бары хәзерге вакытта булган яки алар гамәлгә кертелгәннән соң килеп чыккан хәлләргә карата гына юридик көчкә ия булалар. Башкача әйткәндә, бүгенге законнар кичәге мөнәсәбәтләрне җайга сала алмый.

Әгәр гамәлдән чыгарылса, шулай ук гамәл вакыты тәмамланса, теләсә кайсы хокукый акт үз көчен югалта. Закон җайга сала торган мөнәсәбәтләр юкка чыккан, ә законны гамәлен югалтты дип игълан итәргә «онытканнар» икән, ул шулай ук эшләүдән туктый. Законның вакыт ягыннан гамәлдә булу кагыйдәләре шуннан гыйбарәт.

Дәүләт территориясе законның гамәлдә булу киңлеге (пространствосы) буларак билгеләнә. Россия дәүләте территориясенә илнең барлык коры җир һәм су киңлекләре, чит илләрдәге дипломатик вәкиллекләре, Россиянең җир шарындагы ачык су киңлекләрендә йөзүче хәрби һәм сәүдә көймәләре, дөньяның теләсә кайсы ноктасындагы һава кораблары керә.

Хокукый актлар гамәленең ниндирәк затлар даирәсенә кагылуына килгәндә, дәүләт законнарының аның барлык гражданнарына, территориясендә яшәүче чит ил гражданнарына, гражданлыгы бул-

маган затларга кагылышы булуына нигезләнеп эш итеQ. Кайбер хокукый актларның гамәле билгеле бер затларга гына кагыла. Мәсәлән, хәрбиләр турындагы законнар гражданнарның бары шушы контингентына карата гына үз көчендә була.

---

[1] **Төшенчәләр:** *хокук, хокукый система, прецедент, хокукый норма, хокук тармагы, хокук чыганагы, норматив хокукый акт, закон.*

---

[2] **Сораулар һәм биремнәр**

1. Россия хокукының конкрет тармагы тарафыннан җайга салына торган хокукый очракларга мисаллар китерегез.

2. Хокук чыганагы нәрсә ул? Сезгә аның нинди төрләре билгеле? Түбәндәгеләр хокук чыганагы булып торамы:

— гражданин Петровның N фирмасы белән төзегән хезмәт шартнамәсе;

— Котов эше буенча суд карары;

— РФ Президентының «Җинаятьчелеккә каршы көрәшүне көчәйтү турында» Указы?

3. Россия хокукы нигезендә нинди принциплар ята? Аларга характеристика бирегез.

4. Норматив хокукый актлар иерархиясен тасвирлап бирегез. Аларның гамәле чикләрен аңлатыгыз.

5. «Закон кире көчкә ия була алмый», дигән кагыйдә нәрсәне аңлата? Бу кагыйдәдән нинди чыгармалар беләсез?

***6.** Хокукның асылы турындагы сезгә таныш концепцияләрне анализлагыз. Аларның уңай һәм тискәре якларын аерып күрсәтегез. Җавабыгызны дәлилләгез.

***7.** «Хокукны дәүләт булдыра, һәм ул шул ук вакытта аның белән бәйле дә булырга тиеш» (*В.Н. Кудрявцев*), дип раслау белән килешәсезме?

***8.** Соңгы вакытта Россиядә кабул ителгән сезгә мәгълүм закон-

---

[1] Параграф ахырындагы төшенчәләр укытучы аларны эш барышында файдалана алсын өчен аерып күрсәтелде.

[2] Йолдыз (*) билгесе куелган сораулар аеруча катлаулы дигәнне аңлата.

нарны атагыз. Аларның характерлы сыйфатларын билгеләгез. Ихтыяҗ булса, «Российская газета», «РФ Законнар җыентыгы» кебек басмалардан файдаланыгыз.

***9.** Әлеге норматив хокукый актларның вакыт, урын һәм затлар даирәсе ягыннан гамәле нинди:

а) «Куллануччылар хокукларын яклау турында» 1996 елның 9 гыйнварындагы ФЗ-2 номерлы РФ Законы;

б) «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы ФЗ-53 номерлы РФ Законы;

в) РФ Хөкүмәтенең «Балигъ булмаган балаларга алиментлар тотып калына торган хезмәт хакы һәм башка керемнәр төрләре исемлеге турында» 1996 елның 18 июлендәге 841 номерлы карары.

? Проблема. Сез ничек уйлыйсыз, кешегә хокукларны дәүләт бирәме яки кеше дөньяга килгәндә үк дәүләт тартып ала алмый торган үз хокуклары белән туамы?

✍ **Практикум.** Таблицаның хокук тармаклары тасвирламалары бирелгән ике баганасы эчтәлеген чагыштырыгыз.

Таблица

Хокук тармагы атамасы	Хокук тармагы эчтәлеге
Җинаять өчен җәза бирү хокукы	Хакимият органнары һәм гражданнар арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала.
Административ хокук	Җинаятьчелекне һәм аның өчен җәза чарасын билгели.
Граждан-процессуаль һәм җинаять-процессуаль хокук	Мирас алу, вөҗданны һәм абруйны яклау, милеккә ия булу һәм аның белән эш итү, килешүләр төзү һ.б.
Хезмәт хокукы	Эш бирүчеләр белән хезмәткәрләр арасындагы мөнәсәбәтләр тәртибен билгели.
Гаилә хокукы	Никахлашканда, аерылышканда һәм гаилә тормышы дәвамында ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала.
Граждан хокукы	Граждан һәм җинаять эшләрен тикшереп хәл итү тәртибен билгели.

§ 2 (§ 23). Хәзерге Россиядә гадел хөкем

Дөнья тарихында низагларны хәл итүнең күпсанлы ысуллары һәм рәвешләре мәгълүм. Күп очракларда ярдәмгә дәүләт органнары килә. Антик чорда хөкем эшләре патшалар кулында була, соңрак аксөякләргә күчә (Римда — преторга һәм сенатка). Афинада халык суды зур роль уйный. Судьяларны, жирәбә салып, кандидатлар исемлегеннән сайлап алганнар. Бу исемлеккә яше 30 га җиткән теләсә кайсы ирекле Афина кешесе языла алган. Якларны һәм шаһитлар күрсәтмәләрен тыңлаганнан соң, суд яшерен тавыш бирү юлы белән кешенең гаеплелеге яисә гаепсезлеге турындагы мәсьәләне хәл иткән. Җәза күпчелек тавыш белән билгеләнгән. Карар чыгарылгач, аңа протест белдерү мөмкин булмаган.

Борынгы Русьта судья золым кылган кешене ут һәм су белән сынаган. Әгәр ул суда калыкса, яисә аны ут өтсә — бу кеше гаепле дип табылган. Еш кына суд үзара каршылыкка кергән ике якка кылыч сугышы уздырырга тәкъдим ясаган. Җиңүче як суд эшен отучы дип танылган. XIX гасыр кергәндә Россиядә тартышулы суд процессы, присяжныйлар суды барлыкка килә, эшне карап тикшерүдә прокурор һәм адвокат катнаша.

Хәзерге Россиядә суд хакимияте нидән гыйбарәт? Безнең илдә бары судлар гына хөкем карары чыгара ала, бер генә вазыйфаи зат та кем турында булса да җинаятьче дигән карар чыгара алмый. Хәзерге вакытта Россиядә бердәм **суд производствосы системасы** оешып житте. Аны ил территориясендә гамәлдә булган барлык судлар берләшмәсе тәшкил итә. **РФ Конституция суды** суд хакимиятенең әһәмиятле органы булып тора. Ул Конституциягә туры килмәгән һәм гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга китергән законнарның гамәлен туктата. Конституция суды тарихы 1991 елдан башлана. Аның составына Федерация Советы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән 19 судья керә. Бу вазыйфага 40 яшьтән алып 70 яшькәчә, юрист белгечлеге алган кешеләр билгеләнә. Вазыйфасына керешкәндә Конституция суды судьясы ант китерә һәм үз эшчәнлегендә законга таяна.

Мәсәлән, 1998 елга кадәр торак турындагы законнарда коммуналь фатирда күршеләре рөхсәтеннән башка кешегә үз бүлмәсен приватизацияләүне тыя торган кагыйдә бар иде. Конституция суды бу

норманың кешеләрнең шәхси милеккә берни белән дә чикләнмәгән хокукы теркәлгән ил Конституциясенә туры килү-килмәвен тикшерде. Әлеге хәлне җентекле анализлаганнан соң, суд бу кагыйдәне илнең төп законына каршы килә дип тапты һәм торак турындагы законнарның бу нормасын юкка чыгарды.

РФ Югары суды граждан, җинаять һәм административ эшләр буенча иң югары суд хакимияте органы булып тора. Ул гомуми юрисдикция судлары карамагындагы иң катлаулы эшләрне тикшереп хәл итә, түбәнрәк баскычтагы судларның теләсә нинди эш буенча карарларын, билгеләмәләрен кабаттан карый, суд практикасы мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә.

Илебез территориясендә республикаларның югары судлары, край һәм өлкә судлары, федераль әһәмияттәге шәһәрләр (Мәскәү, Санкт-Петербург кебек) судлары, автоном өлкәләр һәм округлар, шулай ук шәһәр (район) судлары, җәмәгать судьялары эшли. Алар граждан, административ, хезмәт дәгъваларын тикшереп хәл итәләр, шулай ук җинаять эшләрен карыйлар.

Хәзерге Россиядә эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче гражданнар һәм оешмалар арасындагы икътисади дәгъваларны ***арбитраж судлары*** хәл итә. Аларның системасына **РФ Югары арбитраж суды**, Федерация округларының һәм субъектларының федераль арбитраж судлары керә. РФ Югары арбитраж суды РФ Президентының, парламентының, хөкүмәтенең законга туры килмәгән, эшкуарларның хокукларын бозуга китерә торган актларын гамәлдән чыгару турындагы эшләрне, шулай ук Россиянең Федерация субъектлары белән икътисади дәгъваларын тикшерә. Ул эшләрне күзәтчелек тәртибендә карый, аларны, яңа билгеле булган хәлләрне исәпкә алып, кабаттан тикшерә. Моннан тыш, Югары арбитраж суды икътисад өлкәсендә гамәлдә булган законнарны куллану практикасын өйрәнә һәм гомумиләштерә, суд практикасы мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә. Югары һәм Конституция судларына кебек үк, аңа да закон чыгару инициативасы хокукы бирелгән. Шулай итеп, ул үз карамагындагы мәсьәләләр буенча нинди дә булса закон проектын Дәүләт Думасы каравына кертә ала.

1995 елдан округларның федераль арбитраж судлары эшли башлады. Мондый судларның саны унга тула. Округлар Россиянең аерым икътисади зоналарына туры килә. Бу судлар Федерация субъектлары

судларының суд актлары законлылыгын кассация инстанциясендә тикшерәләр, суд практикасын өйрәнәләр һәм гомумиләштерәләр, суд статистикасын анализлыйлар. РФ субъекты арбитраж суды беренче инстанциядә барлык үз карамагындагы эшләрне карый. Ул эшне апелляция инстанциясендә кабаттан карарга мөмкин. Гомуми юрисдикция судлары өчен мондый тәртип кертелмәгән.

Судларның кайсысында гына эшләмәсен, судьяларның хокукый статуслары бер төсле була. Алар сәяси хәрәкәтләрдә катнашудан, эшмәкәрлек белән шөгыльләнүдән тыелырга тиешләр. 25 яше тулган, юридик белеме булган Россия гражданы гына судья була ала. Моның өчен әле квалификация имтиханы да бирергә кирәк. Судьялар алыштырылмый, алар бәйсез һәм бары законга гына буйсыналар.

Россиянең суд системасы

Әлеге һөнәр ияләре кагылгысыз, аларны административ һәм дисциплинар җаваплылыкка тартып булмый. Аларга карата җинаять эшен, судьяларның квалификация коллегиясе рөхсәте булган очракта, бары РФ Генераль прокуроры гына кузгата ала. Аларның гомере, сәламәтлеге һәм милке федераль бюджет акчалары исәбеннән мәҗбүри иминиятләштерелә. Судьяның гомере һәм сәламәтлеге 15 еллык хезмәт хакы суммасына иминиятләштерелә.

Икътисади дәгъваларның билгеле бер категориясе өчен низагны җайга салуның дәгъва белдерүле (претензион) мәҗбүри тәртибе билгеләнгән. Шуңа бәйле рәвештә, судка мөрәҗәгать иткәнче якларның берсе икенчесенә үз йөкләмәләрен үтәү, хокук бозуны бетерү һ.б. шундый таләпләр белән дәгъва белдерә ала. Низагның шул рәвешчә хәл ителүе дә бар, бу очракта якларның судка мөрәҗәгать итү ихтыяҗы да калмаячак.

Килеп чыккан бәхәсне чишү өчен яклар килешүе буенча сайлап алынган *өченче як (третейский) судлары* да икътисади дәгъваларны тикшереп хәл итә ала. Дәгъваларны тиз арада, артык акча сарыф итмичә хәл кылу мөмкинлеге бирә торган мондый суд Россиядә борынгы заманнарда ук булган.

Әгәр өченче як судының карарын үтәү ирекле рәвештә башкарылмый икән, Арбитраж суды аны мәҗбүри үтәтергә мөмкин. Өченче як суды карарларны мәҗбүри үтәтү чараларына ия түгел. Мондый судлар илнең суд системасына кертелмәгән.

Җәмәгать судлары җирлекләрдә суд эшен башкаралар. Алар, беренче инстация судлары буларак, артык катлаулы булмаган җинаять, граждан эшләрен һәм административ эшләрне карап тикшерәләр. Әгәр суд тәгаен бер эшне тәүге кат карый икән, димәк, бу эшкә карата ул беренче инстанция суды булып тора. Әмма ул чыгарган хөкем яисә карар кассация шикаяте тәртибендә яки прокурор протесты буенча кабаттан каралырга да мөмкин. Эшкә катнашы булган затлар — шикаять, ә прокурор протест бирү хокукына ия булалар. Икенче инстанция суды беренче инстанция суды чыгарган карарның (хөкемнең) законлылыгын, нигезлелеген тикшерә. Ул шикаятьне яки протестны канәгатьләндермичә калдырырга яисә хөкем карарын юкка чыгарырга һәм төп эчтәлеге буенча эшне яңадан тикшерү өчен беренче инстанция судына җибәрергә мөмкин. Район суды җәмәгать судьялары өчен югары инстанция була. Өлкә судлары район судлары карарларын кабаттан карый торган икенче инстанция судлары буларак эш йөртергә мөмкиннәр.

Әйтик, без низаглы хокукый хәлгә тардык ди. Иң беренче нәүбәттә ни кылырга кирәк?

Беренчедән, элеге хәлдә кемнең хаклы, кемнең хаксыз булуын ачыклап, мәсьәләне тыныч юл белән чишәргә тырышып карау урынсыз булмас. Әмма сез үзегезне хаклы дип ышансагыз һәм икенче як сезнең таләпләрегезне үтәүдән баш тартса, судка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Нинди төр судлар булуын сез беләсез инде.

Судка мөрәҗәгать итү өчен **дәгъва гаризасы** язарга кирәк. Аны бирүче — **дәгъвачы,** ә таләпләр куелган кеше — **җавап тотучы** була. Дәгъва гаризасында судның атамасы, аның урнашкан җире, дәгъвачының һәм җавап тотучының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, кайда яшәүләре күрсәтелә, дәгъваның асы-

лы аңлатыла, законнарга нигезләнгән таләпләр куела. Әлеге документка белешмәләр, дәгъвага кагылышлы башка дәлилләр теркәлә. Безнең илдә дәгъва биргән өчен дәүләт пошлинасы турындагы закон нигезендә күпчелек очракта түләү каралган. Дәгъва гаризасын судьяга шәхсән тапшырырга, почта аша заказлы хат итеп җибәрергә яисә башка юл сайларга мөмкин.

Эш судта башкаруга кабул ителгәч, суд әзерлек эшләре алып бара һәм конкрет эшне карап тикшерә. Бу вакытта ул билгеле бер принципларга нигезләнеп гамәл кыла.

Безнең илдәге суд эшчәнлегенең кайбер үзенчәлекләренә тукталып китик.

1. ***Законлылык*** суд эшләрен башкаруның мөһим принцибы булып тора. Эшне судта тикшерү тәртибе законда билгеләнә, шулай ук судьялар да законга таянып кына эш итәләр. Кайбер категория эшләрне караганда судта профессиональ судьялардан тыш, әле тагын **антлы утырышчылар (присяжные заседатели)** да катнаша. ***Антлы утырышчылар суды (суд присяжных)*** Россиядә XIX гасыр урталарында эшчәнлеген башлый, 1917 елдан бетерелә, XX гасырның 90 нчы елларыннан — яңадан гамәлдә. 25 яшьтән кече һәм 70 яшьтән өлкән булмаган теләсә кайсы зат (хәрбиләр, дин әһелләре һәм судьялардан тыш) антлы утырышчы була ала. Антлы утырышчылар коллегиясенә 12 кеше һәм запастагы 2 кеше керә. Антлы утырышчылар эшнең юридик нечкәлекләрен җентекләп өйрәнмиләр, бары тик затның гаепле яисә гаепсез булуы турындагы мәсьәләне хәл итәләр. Гадәттә алар аеруча авыр һәм куркыныч җинаятьләр буенча кузгатылган эшләрне карап хәл иткәндә катнашалар. Әгәр антлы утырышчылар кешенең гаепсезлеге турында карар чыгаралар икән, ул суд залында ук кичектергесез рәвештә сак астыннан азат ителергә тиеш була.

2. Суд эшләрен башкаруда ***ачыклык*** суд утырышына кызыксыну белдергән теләсә нинди кеше — гаепләнүченең туганнары һәм дуслары, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре кертелә дигән сүз ул. Дәүләт яисә коммерция серенә кагылышлы, 16 яше тулмаган затлар кылган һәм аеруча авыр җинаятьләр буенча кузгатылган эшләр карап тикшерелгәндә, суд утырышы ябык булырга да мөмкин. Әмма ничек кенә булмасын, суд чыгарган хөкем карарлары һәрчак ачык игълан ителә.



3. Якларның ***тигез хокукларга*** ия булуы һәм ***һәр ике якның да дәлилләре исәпкә алынуы (тартышуы)*** суд процессында катнашучыларның үзара һәм закон алдында бертигезлеген, ә булган хәлләр төрле яклап тикшерелүен аңлата. Эшне карап тикшерүдә гаепләүченең һәм яклаучының дәлилләре бердәй исәпкә алына. Җинаять эшләрендә прокурор — гаепләүче, адвокат яклаучы була. Беренче кат артык авыр булмаган җинаять кылган кешенең, әгәр ул зарар күрүче белән килешкән һәм үзе китергән зыянны кайтарган булса, җинаять җаваплылыгыннан азат ителүе мөмкин. Граждан процессында дәгъва белдерүченең хаклыгын дәлилләүдә дәгъвачы үзе, аның вәкилләре яисә адвокат активлык күрсәтә.

4. Суд эшчәнлеге ***милли телдә*** алып барыла. Мондый очракта суд эшендә тәрҗемәченең катнашуы рөхсәт ителә. Эшләрне судта карау Россиядә рус телендә бара.

5. Гаепләнүченең үз гаепсезлеген дәлилләве мәҗбүри түгел. Шул ук вакытта җинаять эше буенча суд хөкеменә тартылган кешене, аңа карата гаепләү характерындагы хөкем карары чыгарылганга кадәр, җинаятьче дип атау тыела. ***Гаепсезлек презумпциясе*** нәкъ менә шуны аңлата. РФ Конституциясенең 49 статьясында гаепсезлек презумпциясе принцибы теркәлгән. Бу принцип нигезендә җинаять кылуда гаепләнүче һәрбер зат, законлы көченә кергән суд карары белән гаебе дәлилләнгәнче һәм билгеләнгәнче, гаепсез дип санала. Кемне дә бул-

са ирексезләп үзенә, хатынына (иренә) һәм туганнарына зыян китерә торган күрсәтмәләр бирдерү тыела.

Судның барлык карарлары һәм хөкемнәре мәҗбүри үтәлергә тиеш. Суд карарларының үтәлешен суд приставлары тәэмин итәләр. Алар шулай ук судта тәртип саклыйлар. Юстиция министрының урынбасары баш суд приставы булып тора. Закон нигезендә судның пристав-башкаручысына бурычлары булган гражданнар били торган биналарга керергә, аларны карап тикшерергә; бурычлы затның милкен кулга алырга; аның эзләнүе турында игълан итәргә рөхсәт бирелә.

Төшенчәләр: *Конституция суды, Арбитраж суды, гомуми юрисдикция суды, җәмәгать суды, дәгъвачы, җавап тотучы, антлы утырышчылар, гаепсезлек презумпциясе, кассация.*

Сораулар һәм биремнәр

1. РФ суд системасы нидән гыйбарәт?

2. Түбәндәге хокукый низаглар килеп чыкса, кайсы судка мөрәҗәгать итәргә кирәк:

а) әгәр ир белән хатын милек («Жигули» машинасын) бүлешәләр һәм үзләрен аеруны таләп итәләр;

б) кешене законсыз рәвештә эшеннән чыгаралар;

в) эшкуарга «N» фирмасыннан товарны тулысынча китереп бетермәгәннәр.

3. Россиядә суд эшләрен башкаруның төп принципларына аңлатма бирегез.

4. *Дәгъва, дәгъвачы, җавап тотучы, суд акты, апелляция, кассация, инстанция, суд приставы* дигән юридик терминнарның эчтәлеген аңлатыгыз. Кирәк булса, сүзлектән файдаланыгыз.

*5. Граждан Галиевнең сезгә бурычын кайтарудан баш тартуы белән бәйле рәвештә судка дәгъва белдерү гаризасы язарга тырышып карагыз.

*6. Законда ни өчен хәрбиләр, дин әһелләре һәм судьялар антлы утырышчылар була алмый, дип билгеләнгән, шуны аңлатыгыз.

7. Гаепсезлек презумпциясен гражданнарның мөһим хокукы дип саный алабызмы? Әгәр саный алсак, ни өчен?

? **Проблема.** Хәзерге Россиядә суд эшләрен оештыру демократик дәүләт принципларына туры киләме яисә бу өлкәдә ни дә булса үзгәртергә кирәкме?

✍ **Практикум.** Түбәндәге гыйбарәләр хакмы яисә хак түгелме:

а) Судта җинаять эшләре карап тикшерелгәндә прокурорның катнашуы мәҗбүри. (Юк.)

б) Өченче як судлары илнең суд системасына керми. (Әйе.)

в) Антлы утырышчылар суды Конституциягә туры килми торган законны гамәлдән чыгара ала. (Юк.)

г) Законнарнын үтәлешенә адвокатура күзәтчелек итә. (Юк.)

д) Теләсә кайсы эш буенча чыгарылган суд карарлары ачык утырышта игълан ителә. (Әйе.)

е) РФ Конституция суды, РФ Югары суды һәм РФ Югары Арбитраж суды закон чыгару инициативасы хокукына ия була. (Әйе.)

§ 3 (§ 24). Хокук бозулар һәм юридик җаваплылык

Хәзерге фәндә «юридик җаваплылык» төшенчәсенең бердәй билгеләмәсе юк. Берәүләр аны хокукый норма чарасы (санкциясе) белән бәйләп караса, икенчеләре хокук бозучы белән дәүләт арасындагы хокукый мөнәсәбәтләр турында сүз алып бара. Әмма алар эшнең асылын ахыргача аңлатып бирә алмый.

Юридик җаваплылык дигәндә, хокук бозучылар дучар була торган тискәре нәтиҗәләр җыелмасын күздә тотарга кирәк.

Аның төп сыйфатларын аерып күрсәтик:

— юридик җаваплылык конкрет хокук бозу өчен билгеләнә (хокук бозу булмаса — юридик җаваплылык та юк);

— ул дәүләт тарафыннан мәҗбүриләү белән бәйле;

— законда каралган аерым тәртиптә билгеләнә. Бер генә кеше дә ничек кирәк, шулай җаваплылык төрен һәм аны куллану тәртибен уйлап чыгара алмый.

Дәүләт тарафыннан мәҗбүр ителү һәрчак хокук бозучыларга карата кулланыла диеп булмый. Мәсәлән, йорт милекчесе проблемасын хәл иткәндә суд йортка *С* түгел, ә *В* ия дигән карар чыгара һәм *С* ны йортны иясенә тапшырырга мәҗбүр итә. Шулай итеп, бернинди дә хокук бозмаган килеш, С суд карарын үтәргә тиеш була. Әгәр ул баш тартса, дәүләт тарафыннан мәҗбүриләү чаралары күрелә.

Һәр юристка шунысы мәгълүм: юридик җаваплылык җинаятьләрне, начар гамәлләрне кисәтергә, хокук бозучыларны җәзага тартып, бәхәсле мөнәсәбәтләрдә гаделлек урнаштырырга мөмкинлек бирә.

Безнең илдә җинаять җаваплылыгы гомуми кагыйдә буенча уналты яшьтән башлана. Әмма бу уналтысы тулмаганнар кылган җинаятьләр җәзасыз кала дигән сүз түгел. Ундүрт яшьтән кеше үтергән, аны урлаган, аның сәламәтлегенә зыян китергән, көчләгән, урлаган, талаган, юлбасарлык кылган, куркытып акча яки әйбер алган, урлау максаты куймыйча гына автомобиль яисә башка транспорт чарасын куып киткән, белә торып мөлкәтне юкка чыгарган, террорчылык, тотык (заложник) алган, террорчылык акты турында ялган хәбәр биргән, хулиганлык, вандализм, корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр, наркотиклар һәм психотроп матдәләр урлаган яки куркытып алган, транспорт чараларын файдаланып булмый торган хәлгә китергән өчен җинаять җаваплылыгына тартыла.

Җинаять — хокук бозуның иң куркыныч төре. Җинаять хокукы өлкәсендә бердәнбер закон — илнең Җинаять кодексы гамәлдә. Анда юридик төшенчә буларак җинаятькә түбәндәге билгеләмә бирелә: «Әлеге Кодекста җәза билгеләнү белән куркытып тыелган, гаеп тагарлык итеп кылынган җәмгыять өчен куркыныч гамәл җинаять дип таныла» (РФ ЖК, 14 статья).

Хакимият тарафыннан теләсә нинди нигезсез гамәлләр кылынмасын өчен, һәрбер кеше бары тик түбәндә билгеләргә ия гамәлне генә җинаять дип атап булганлыгын белергә тиеш:

1) гамәл Җинять кодексы тыя торган эш булса;

2) кеше, җәмгыять, дәүләт өчен куркыныч булса;

3) кылынган гамәлдә кешенең гаебе булса;

4) җинаять составы булу мәҗбүри билге булып тора.

Россия законнары буенча җинаять кылган чагында кеше ка-

мил акылында булырга, ягъни үзенең куркыныч гамәл кылуын аңларга тиеш. Нинди генә дәрәҗәдә исерек булмасын, бу аны җаваплылыктан коткармый.

Нинди объектка карата кылынуына карап җинаятьләр түбәндәге төрләргә аерыла:

— шәхескә каршы җинаятьләр;

— икътисад өлкәсендәге җинаятьләр;

— җәмгыять куркынычсызлыгына һәм җәмгыять тәртибенә каршы җинаятьләр;

— дәүләт хакимиятенә каршы җинаятьләр;

— хәрби хезмәткә каршы җинаятьләр;

— тынычлыкка һәм кешелек куркынычсызлыгына каршы җинаятьләр.

Әлеге исемлектә кешегә каршы кылынган гамәлләр беренче урында тора. Җәмгыять шул рәвешле кеше гомеренең, сәламәтлегенең, вөҗданы һәм абруеның аеруча кыйммәткә ия булуын таный. XX гасыр ахырында гына гаиләгә һәм балигъ булмаган затларга каршы кылынган җинаятьләр дигән төшенчә барлыкка килде. Балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга тарткан, балалар белән сату иткән яисә аларны тәрбия кылу бурычларын үтәмәгән өчен җинаять җаваплылыгы билгеләнде. Урлау, мошенниклык, үзенә матди файда китерү максатыннан кылынган куркытып акча яисә әйбер алу гына түгел, бәлки саксызлык белән чит кеше мөлкәтен юкка чыгару да җинаять дип таныла. Милекне шундый юл белән саклана.

Җинаятьнең төп билгесе — кешенең гаепле булуы. Законда «җинаять кылган чагында авыру булу сәбәпле үз гамәлләрен аңлата һәм үзен кулда тота алмаган затның» җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш түгеллеге турында әйтелә. Мондый кешеләр *үз акылында түгел* дип таныла.

Гаеп **саксызлык** яисә **астыртын уй** белән кылынырга мөмкин. Моны мисалларда карап үтик. Ике егет мотоциклларда узышып, кемнең билгеләнгән урынга тизрәк килеп җитәсен ачыкларга уйлыйлар. Аларның яхшы мотоциклга ия булганы, юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәмичә генә, юлның теләсә кайсы урыныннан «очып кына» узмакчы. Ул бик күп тапкырлар шулай эшләгән, һәм

аны бер генә мәртәбә дә җаваплылыкка тартмаганнар. Әмма мондый фараз ялгыш булып чыга. Мотоциклчы, светофорның кызыл утын санга сукмыйча узып китә дә каршысына килүче машинага бәрелә. Машина йөртүчегә кисәк кенә тормозга басарга туры килә, шуның нәтиҗәсендә автомобильдәге пассажирлар җәрәхәтләр ала. Бу очракта егет үз гамәлләренең хәтәрлеген аңлый торып та, аларны булдырмый калырмын дип ышана. Мондый саксызлык — җиңел акыллылык нәтиҗәсе.

Юриспруденциядә җинаять нәтиҗәләрен ***күздә тотып*** яисә ***күздә тотмыйча*** гамәл кылу дигән төшенчәләр бар. Әйтик, менә мондыйрак очраклар килеп чыкты ди. Бизнестагы көндәшен үтерергә карар кылган бер фирма житәкчесе киллер (үтерүче) ялларга уйлый. Бу очракта ул башка кешенең гомерен өзүен, аның якыннарын хәсрәткә салуын яхшы аңлый, әмма үзенә матди файда китерү максатыннан бу адымны ясый. Әгәр җинаятьче үз гамәлләренең куркынычлыгын аңласа һәм шуның килеп чыгуын теләп гамәл кылса, ул нәтиҗәләрен алдан күздә тотып җинаять кылган була. Яисә менә тагын бер мисал: дус булып йөргән ике кеше низаглашып китә, берсе икенчесен тукмап ташлый, әмма моның үлемгә китерүен теләми, гәрчә шундый хәл булырга мөмкин икәнен ул яхшы аңлый. Нәтиҗәләрен күздә тотмыйча җинаять кылу шушы була инде.

Хокукка каршы гамәл моделе буларак, җинаять — гаять катлаулы категория. Күпчелек очракта җинаятькә җентекле әзерлек алып барыла, башка катнашучылар җәлеп ителә, план төзелә, җинаять кылу чаралары һәм кораллары хәстәрләнә. Монысы җинаять кылуга әзерлек чоры була. Кешенең җинаятькә әзерләнүен фаш итү авырлыгы тормыш тәҗрибәсе белән расланганлыктан, закон чыгаручы тарафыннан мондый гамәлләр өчен, аеруча авыр җинаятьләрдән кала, җаваплылык билгеләнми.

Җинаять, аны кылучыга бәйләнмәгән шартлар туу аркасында, ахырына кадәр җиткерелми дә калырга мөмкин. Мондый очракны **җинаять кылуга омтылу** дип атыйлар. Бер граждан (N) провинциаль шәһәрләрнең берсендәге кыйммәтле бизәнү әйберләре кибетен басарга озаклап әзерләнә. Шуннан алдагы көндә генә аннан бөтен товар алып китеп бетерелгәнен белмичә, ул урлау нияте белән яшерен рәвештә кибеткә үтеп керә. Биредә аны хокук саклау системасы хезмәткәрләре тотып ала. Бер караганда, кеше берни дә

урламады һәм ул моның өчен җаваплылыкка тартылырга да тиеш түгел кебек. Әмма әлеге шартлар аның ихтыярына бәйсез килеп чыккан. Мондый очраклар яраксыз объектны сайлап, җинаять кылырга омтылу буларак бәяләнә, шуңа да җәза да билгеләнә. Кешенең закон бозмыйча яшәргә, ягъни хокукка каршы планнарыннан баш тарту ирегe бар. Бу очракта җинаять җаваплылыгы булмый кала.

Теләсә нинди җинаять өчен кешене төзәтү, яңа җинаятьләрне кисәтү максатларында җәза бирелә. Шул ук вакытта җәза кешене түбәнсетергә яисә аңа газап китерергә тиеш түгел. Безнең илдәге төп җәза төрләре: шәхесне төзәтүгә юнәлтелгән мәҗбүри эшләр, хәрби хезмәт буенча чикләүләр, ирекне чикләү, кулга алу, билгеле срокка иректән мәхрүм итү, гомерлеккә иректән мәхрүм итү һәм үлем җәзасы. Россия җәмәгатьчелегендә соңгы елларда иң чик җәза чарасына аеруча зур игътибар бирелә. Россиянең Европа Советына керүе үлем җәзасы чыгарылган карарларны үтәүгә мораторий (тыю) кертелүгә сәбәп булды.

Җәза билгеләү — суд процессының гаять җаваплы өлеше, чөнки судья бу вакытта кешенең киләчәк язмышын хәл итә. Кызганыч ки, бер гаебе булмаган кешеләрнең җәзага тартылу очраклары мәгълүм. Аларның гаепсезлеге соңрак, инде җәза срогын үтәгәч ачыклана.

Законда кешегә бирелә торган җәзаны *җиңеләйтә торган* шартлар категориясе аерып күрсәтелә. Мондыйларга элегрәк җинаять кылмау, очраклы шартлар аркасында җинаять кылу, балигъ булмаган затларның, йөкле хатыннарның җинаять кылуы; җинаять кылган затның гаебен танып килүе; зыян күрүчегә медицина ярдәме күрсәтү һ.б. шундыйлар керә.

Шулай ук *җинаятьне авырайта торган* шартлар да билгеләнгән: җинаять рецидивы (кабатлануы), җинаятьнең авыр нәтиҗәләргә китерүе, төркем белән җинаять кылу, корал, шартлаткыч матдәләр куллану, форма киеменнән файдалану һ.б. Иректән мәхрүм итүнең чик срогы — 20 ел. Кеше берничә җинаять кылган очракта, һәр җинаять өчен җәза аерым-аерым билгеләнә. Карар чыгарганда җәза сроклары кушыла, гомуми срок 25 елдан да артырга тиеш түгел.

Беренче мәртәбә җинаять кылган зат гадәттә авыр кичерешләргә дучар була. Кеше нинди очракларда җинаять җаваплылыгыннан



азат ителергә мөмкин? Беренчедән, гаебен танып, китерелгән зарарны (ул артык зур булмаган очракта) түләгәндә; икенчедән, зыян күрүче белән уртак тел тапканда; өченчедән, җинаять кылынганнан соң билгеле бер вакыт узып киткәндә (артык авыр булмаган җинаять кылганнан соң — 2 ел, авыр җинаять кылганнан соң — 10 ел һәм аеруча авыр җинаятьтән соң 15 ел узгач).

Балигъ булмаган затларга төзәтү характерындагы мәҗбүри чаралар: кисәтү, махсус дәүләт органнары яисә ата-аналары күзәтчелегенә тапшыру; китерелгән зыянны каплау бурычын йөкләү, тәртибенә карата аерым таләпләр кую.

Балигъ булмаган зат җинаять кылган очракта мәҗбүри эш яисә эш белән төзәтү, кулга алу (16 яшьтән), 10 елдан да артык булмаган срокка ирегеннән мәхрүм итү билгеләнә. Штраф салынган очракта, ата-аналарның аны закон бозган балалары өчен түләве мәҗбүри түгел.

Кайчак кешеләр бөтен билгеләре буенча җинаять буларак бәяләнергә тиешле, әмма чынлыкта җинаять булмаган гамәлләр дә кылалар. ***Гамәлнең җинаять буларак каралмавы шартлары түбәндәгеләр:***

— ***үз-үзеңне яклау ихтыяҗы*** (әйтик, кеше һөҗүм итүчегә зарар китерү хисабына үз гомерен, сәламәтлеген куркыныч янаудан саклый);

— ***үтә зур ихтыяҗ*** (еш кына кешеләрне коткарган чакта экстремаль очракларда мөлкәткә зыян салына);

— ***җинаять кылган затны тоткарлаганда зыян китерү*** (җинаятьчене эзәрлекләгәндә башка затларның милкенә, сәламәтлегенә зыян салына һ.б.);

— ***физик яки психик мәҗбүр итү*** (әйтик, кул-аягы бәйләнгән каравылчы аның күз алдында башкарылган кибет басуга комачаулык итә алмый);

— ***нигезле хәтәрлек*** (медицина өчен гаять әһәмиятле аппаратны сынаганда зур гына җир мәйданына зарар китерелә, моны белгечләр алдан белә алмый);

— ***боерыкны яисә күрсәтмәне үтәү*** (фирма директоры боерыгын үтәү йөзеннән ялган документлар буенча товар сатып алучы хезмәткәрләр үзләренең җинаять кылуларын белмиләр).

Административ җаваплылык турында басым ясап әйтеп китәргә кирәк. Мондый җаваплылыкка ***административ хокук бозган*** затлар тартыла (вак хулиганлык, исерек килеш җәмәгать урыннарда булу, паспорт кагыйдәләрен бозу, чакыру алып та, хәрби комиссариатка килмәү, керемнәр турындагы декларация бирүдән баш тарту, юл йөрү кагыйдәләрен үтәмәү, хайваннарга карата шәфкатьсезлек күрсәтү, этләр һәм мәчеләр асрау кагыйдәләрен үтәмәү, транспортта билетсыз бару һ.б.). Юридик практикадан чыгып, аеруча таралыш алган ***административ тискәре гамәлләр*** арасыннан начар сүзләр белән сүгенү, кешеләргә бәйләнү, бинага керү яисә аннан чыгу юлларын каплап тору, капка-коймаларга, йорт диварларына сүгенү сүзләре язу, җәмәгать урыннарында белә торып, нигезсез коткы күтәрү, оятсыз җырлар җырлау һәм башка шундыйларны атарга кирәк.

Ил законнарында төп һәм өстәмә **административ җәза төрләре** каралган. Түбәндәге административ җәзалардан тыш, административ хокукны бозган өчен башка бернинди дә җәза бирелә алмый. Шулай итеп, административ җәзаларга түбәндәгеләр керә:

— ***кисәтү*** (мәсәлән, юл йөрү кагыйдәләрен үтәмәгән өчен. Язма рәвештә бирелсә, җәза буларак карала. Әгәр милиционер телдән генә кисәтү ясаса, хокук бозучыга бу мораль йогынты ясау була);

— ***административ штраф*** (хокук бозучы билгеле бер суммадагы акча түли);

— ***административ хокук бозу предметын зыянны каплау өчен тартып алу*** (хокук бозучыдан көчләп тискәре гамәл кылу коралы булган предметны тартып алалар, һәм аны сатып, акчасын элеккеге милек иясенә бирәләр);

— административ хокук бозу коралын ***конфискацияләү*** (предмет бушлай дәүләт милкенә бирелә);

— физик затка бирелгән ***махсус хокуктан мәхрүм итү*** (мәсәлән, хокук бозучыны транспорт белән идарә итү, ау белән шөгыльләнү, радиоэлектрон чаралардан файдалану хокукыннан мәхрүм итәләр һ.б.);

— ***административ кулга алу*** (физик эшләр башкару өчен 15 тәүлеккә иректән мәхрүм итү). Аны 14 яше тулмаган балалары булган яисә йөкле хатын-кызларга, I һәм II группа инвалидларга, шулай ук 18 яше тулмаган затларга карата кулланырга ярамый.

— ***Россия Федерациясеннән административ сөрү*** (чит ил кешеләренә, гражданлыгы булмаган затларга карата кулланыла);

— ***дисквалификация*** (кешене юридик затның башкарма идарә органында җитәкче вазыйфалар биләү, юридик зат белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеге хокукыннан мәхрүм итү. Мондый җәза судья тарафыннан билгеләнә).

Административ җәзага тарту аерым тәртип буенча башкарыла. Беренче этапта милиция, дәүләт инспекцияләре һәм башка шундый оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан эш кузгатыла, протокол төзелә. Хокук бозучыны мәҗбүриләп милиция бүлегенә китерергә мөмкиннәр. Милиция хезмәткәрләренә кешене тентергә, аның шәхси әйберләрен, документларын тикшерергә һәм башка шундый гамәлләргә хокук бирелгән.

Дисциплинар җаваплылык юридик җаваплылыкның өченче төре булып тора. Ул хезмәт кагыйдәләрен үтәмәгән, хезмәт дисциплинасын бозган өчен билгеләнә. РФ Хезмәт кодексында дисциплинар җәзаларның төрләре билгеләнә. Болар: кисәтү, шелтә белдерү һәм эштән азат итү. Эштән азат ителүдән тыш, башка дисциплинар җәзалар хезмәт кенәгәсендә теркәлми. Диციплинар җәзаны судка шикаять биреп тикшертергә мөмкин.

Мәктәп укучылары шулай ук дисциплинага буйсынырга: дәресләргә йөрергә, үзләре белем ала торган уку йортының Уста-

вын үтәргә тиешләр. Кагыйдәләрне санга сукмавы 14 яше тулган укучының мәктәптән куылуына китерергә мөмкин.

Гражданнар арасындагы хокукый мөнәсәбәтләрнең бозылуы нәтиҗәсендә **граждан-хокукый җаваплылыгы** барлыкка килә. Бу җаваплылык килгән зыянның тулысынча түләнүен күздә тота. Бик зур хәтәр чыганагы булып торучы автотранспорт иясе теләсә нинди шартларда бу транспорт китергән зыянны түли.

Граждан хокук бозулары төрле булырга мөмкин. Бер очракта фирма азык-төлек әйберләре белән тәэмин итү шартнамәсе таләпләрен бозган, икенче очракта — торак бинадан файдаланучы коммуналь хезмәтләр өчен түләмәгән, өченче очракта — буяучылар бригадасы йөкләмәләрен вакытында үтәмәгән. Хокук бозучы йә йөкләмәләрен үтәргә, йә шартнамәдә күрсәтелгәнчә штраф түләргә тиеш була.

Матди җаваплылык оешма хезмәткәре тарафыннан зарар китерелгәндә барлыкка килә. Ул тулы һәм чикләнгән булырга мөмкин. Чикләнгән матди җаваплылык хезмәткәрнең хезмәт хакына карата процентларда (1/3, 1/2 өлеше һ.б.) билгеләнә.

Төшенчәләр: *юридик җаваплылык, җинаять, җәза, административ җаваплылык, граждан-хокукый җаваплылыгы.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Кылынган гамәл нинди очракларда җинаятьчел түгел дип таныла?

2. Россиядә гамәлдә булган гаепсезлек презумпциясен ничек аңларга?

3. Хокук бозуларга нинди сәбәпләр этәргеч бирә? Җәмгыятьтә юридик җаваплылык нинди функцияләр үти?

4. Нинди җинаятьләр өчен җинаять җаваплылыгына зат 14 яшьтән тартылырга мөмкин? Сез ничек уйлыйсыз, бу нигә шулай?

***5.** Түбәндәге критерийларны кулланып, сезгә билгеле булган юридик җаваплылык төрләрен чагыштырыгыз:

а) кеше нинди гамәлләр өчен җаваплылыкка тартыла?

б) аның хокукый регламентациясе кайда билгеләнә?

в) кылынган гамәл өчен җәза чарасы турындагы мәсьәләне хәл итәргә кем вәкаләтле?

***6.** Нинди гамәлне җинаять дип атарга мөмкин? Сезгә танышларыгыздан яисә массакүләм матбугат чараларыннан мәгълүм булган җинаять турында сөйләгез. Гамәлне кылынган эш составы позициясеннән чыгып анализлагыз.

***7.** Законнарны белмәү ни өчен җаваплылыктан коткармый?

***8.** Законда нигә җәзаны авырайта һәм җиңеләйтә торган хәлләр каралган?

? Проблема. Үлем җәзасын кертү кирәкме әллә юкмы?

Практикум. Түбәндәге гамәлләрнең кайсысы нинди җавапылыкка тартылырга тиеш:

а) банк басу;

б) эшкә соңга калу;

в) җәмәгать транспортында билетсыз утырып бару;

г) яшереп корал саклау;

д) шәхси машинада барганда рөхсәт ителгән тизлекне арттыру;

е) үзара кыйнашу вакытында авыр тән җәрәхәтләре ясау;

ж) ялган паспорт ясау?

§ 4 (§ 25). Хосусый хокук

Римның күренекле юристы Ульпиан (170–228 еллар тирәсе) аерым шәхесләрнең мәнфәгатьләрен яклый торган нормаларның җәмгыять өчен гаять мөһимлеге турында сөйли торган була. Хосусый хокукны нәкъ менә шушы нормалар тәшкил итә дә инде. Хокукның Рим юристлары тарафыннан кертелгән *җәмгыяви* һәм *хосусый* төрләргә бүленеше бүген дә саклана. Борын заманнарда ук яклар үзара килешеп җәмгыяви хокук нормаларына үзгәреш кертә алмаганнар, хәзерге заман теориясендә аларны *императив*, ягъни мәҗбүри үтәлергә тиешле нормалар дип атау кабул ителгән. Мәсәлән, әгәр законда кешеләр юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозарга тиеш түгел дип билгеләнгән икән, ЮХИДИ хезмәткәренең һәм кагыйдә бозган машина йөртүченең бернинди килешүе дә әлеге конкрет хәл өчен бу күрсәтмәләрне үзгәртә дә, аларга өстәмә кертә дә алмый.

Әмма хәзер хуҗалык субъектлары арасында хокук өлкәсендә барлыкка килә торган эшкуарлык мөнәсәбәтләре аерым роль уйный. Мондый субъектларга шәхси эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар да, төрле оешмалар, кешеләр берләшмәләре дә керә.

Законда эшкуарлыкның төрле формалары аерып күрсәтелә. Шулар арасыннан аеруча киң таралыш алганнары буларак ***шәхси, партнерлык*** һәм ***корпоратив*** эшмәкәрлекләрне атарга була.

Беренче очракта граждан үз предприятиесен, фирмасын, әйтик, үз «Матбугат үзәген» ача. Ул брошюраларны тиражлау, китапларны басмага әзерләү, материалларны төрле телләргә тәрҗемә итү белән бәйле һәм башка шундый хезмәтләр башкарачак.

Эшкуарлык эшчәнлеге белән 16 яшьтән шөгыльләнергә мөмкин. Моның өчен жирле администрация органнарында теркәлү узарга, тиешле таныклык алырга кирәк. Эшчәнлекнең кайбер төрләре өчен лицензия алу шарт.

Шәхси эшкуар үз фирмасына, хезмәт контрактлары төзеп, хезмәткәрләр кабул итәргә мөмкин. Ул шулай ук закон нигезендә салымнар түләргә тиеш.

Юридик мәгънәсендә, бу — үз исеме, яшәү урыны булган, хокукка һәм хезмәткә сәләтле *физик зат*. Ул алыш-биреш

гамәлләрендә бары үз исемен куллана. Нинди дә булса әсәрләр бастырганда псевдонимнан (уйлап чыгарылган, әмма чит кеше исеме булмаган) файдалану мөмкинлеге бар.

Хокук мөнәсәбәтләрендә катнашучы субъектка (катнашучыга) бәяләмә биргәндә хокукка һәм гамәл кылуга (хезмәткә) сәләтлелек дигән төшенчәләр кулланыла. ***Хокукка сәләтлелек субъектның хокук һәм бурычларга ия булу сәләтендә чагылыш таба.*** Ул кеше тугач та барлыкка килә. Мәсәлән, хәтта өч яшьлек бала да үзенә мираска калган йорт милекчесе була ала. Йортка хокукы булып та, билгеле бер яшькә җитми торып, аның әлеге йортны үзенә кирәгенчә файдалану буенча эш йөртә алмавы аңлашыла. Бу очракта закон гражданның хокукларын чикләми, бәлки күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен, киресенчә аларны яклый гына.

Үз хокукларыннан тулысынча файдалану өчен кеше хезмәткә сәләтле булырга тиеш.

Гражданның хезмәткә сәләтлелеге, үз хокукларыннан файдалана һәм бурычларын үти алу буларак, берничә төрдә булырга мөмкин. Мәсәлән, кече яшьтәге (6 яшьтән 14 яшькәчә) балалар мөстәкыйль рәвештә вак көнкүреш алыш-биреш ясарга: дәфтәрләр, ручкалар, уенчыклар сатып алырга мөмкиннәр.

Балигъ булмаганнарның гамәл кылырга сәләтлелеге (14 яшьтән 18 яшькәчә) аларга мөстәкыйль рәвештә, ата-аналары (уллыкка алучылары, попечительләре) рөхсәтеннән башка үзләре эшләп тапкан акчаны, стипендияне тотарга, фәнни, әдәби әсәрләр, сәнгать әсәрләре, уйлап табулар авторы булырга һәм шулар белән бәйле туган хокуклардан файдаланырга (гонорарлар алырга һ.б) мөмкинлек бирә. Алар кредит учреждениеләренә акча сала һәм алардан файдалана, зур булмаган көнкүреш алыш-биреш гамәлләре кыла алалар. Барлык алыш-биреш гамәлләре өчен балигъ булмаган затларга милек җаваплылыгы йөкләнә. Әмма аларның хезмәт хакы яки милекләре булмаса, алар китергән зарарны ата-аналары түли. Нинди дә булса зур алыш-биреш өчен ата-аналарның язма рөхсәте кирәк. Аерым очракларда ата-аналар (яисә аларны алыштыручы затлар) ходатайствосы буенча суд балигъ булмаган затның үз хезмәт хакыннан яисә керемнәреннән мөстәкыйль файдалану хокукын чикләргә (тулысынча мәхрүм итәргә) мөмкин.

Эшкуарлык партнерлык яисә корпоратив берләшмә рәвешендә тормышка ашырылырга мөмкин. Берничә милекче, акчаларын бергә туплап, үзара килештерелгән план нигезендә эшли башлыйлар.

Шул рәвешчә, эшкуарлык өлкәсендә юридик затлар гамәл кыла. *Бу — аерым милеккә ия булган оешмалар, һәм алар мөстәкыйль рәвештә бурычлары өчен шушы милек белән җавап бирәләр. Алар судта дәгъвачы яисә җавап тотучы буларак катнашырга мөмкиннәр.*

Юридик затлар ике төргә: коммерциячелгә (аларның төп максаты табыш алу) һәм коммерциячел булмаганга бүленә.

Коммерциячел оешмаларның кайбер төрләре белән танышып китик. *Хуҗалык ширкәтләре*, әйтик, ике төргә бүленә: *тулы* һәм *ышаныч нигезенә корылган* ширкәт. Тулы ширкәттә эш алып баручыларның һәрберсе ширкәт исеменнән эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнәләр һәм аның йөкләмәләре өчен үзләренең барлык милке белән җавап тоталар.

Ышаныч нигезенә корылган ширкәтләрдә, ширкәт эшчәнлеге өчен үз милке белән тулысынча җаваплы булган затлардан тыш, үз акчаларын файдалануга бирүче һәм шул кертемнәре кысаларында җавап тотучы акча кертүчеләр дә була. Эшкуарлыкның бу төре

ышаныч нигезенә корылган ширкәт дип очраклы гына аталмаган, ни өчен дигәндә, билгеле бер эшчәнлек алып баруда турыдан-туры катнашучыларга акча бирүчеләр тулысынча ышаныч белдерәләр.

Эшкуарлык *хуҗалык җәмгыяте* рәвешендә дә булырга мөмкин. Ул *җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә* («ЖЧЖ») һәм *акционерлык җәмгыятенә* («АЖ») бүленә.

«ЖЧЖ» — учредительләре үзара өлешләргә бүлеп билгеле бер капитал туплаган җәмгыять. Җәмгыятьтә катнашучыларга тулаем акчаның үзләре керткән өлешенә кагылышлы гына зыян килү куркынычы яный, алар бөтен җәмгыятьнең бурычлары өчен үз шәхси милекләре белән җавап тотмыйлар.

Акционерлык җәмгыятендә устав капиталы билгеле бер сандагы акцияләргә бүленә, җәмгыятьтә катнашучылар аның йөкләмәләре өчен җавап тотмыйлар һәм аларга бары үз акцияләре бәясе кысаларында гына зыян килү куркынычы яный. Үз акциясен саткан очракта, катнашучы (акционер) җәмгыятьтән чыга ала. *Ачык* акционерлык җәмгыятьләре әгъзалары үз акцияләрен кемгә теләсә — шуңа, ә ябыкларында бары шушы җәмгыять акционерларына гына сата ала.

Пай кертемнәрен берләштерү юлы белән *җитештерү кооперативы* төзелә. Табыш биредә хезмәткә карап бүленә, катнашучыларының җаваплылыгы исә үзләре керткән пай кертеменә карата билгеле бер нисбәттә билгеләнә.

Болардан тыш, безнең ил икътисадында әле тагын *унитар предприятиеләр* дә эшчәнлек алып бара, аларга дәүләт хуҗа. Болар: төрле дәүләт структуралары, җирле хакимият органнары һ.б.

Әгәр учредительләр (гражданнар, оешмалар) эшкуарлык җәмгыяте төзергә уйласалар, *учредительлек шартнамәсе*, *устав* эшләү шарт. Аларда предприятиенең атамасы, юридик адресы, эшчәнлегенә идарә итү, катнашучыларының хокуклары һәм бурычлары, табыш алу шартлары һәм башкалар күрсәтелә.

Документларны гариза белән бергә дәүләт органнарына теркәтү өчен бирергә кирәк. Шәхси эшкуарлар үзләре яшәгән урында — район, поселок һәм башка шундый торак пунктлар администрациясендә, ә юридик затлар махсус Теркәү палаталарында теркәлә.

Әгәр эшкуарлык җәмгыяте теркәлмичә эшләсә, тыелган эшчәнлек алып барса яисә закон бозса, законда суд карары нигезендә аны ябу мөмкинлеге каралган.

Россия гражданнарының нинди хезмәт хокуклары бар? Хезмәт мөнәсәбәтләре закон актлары нигезендә җайга салына. Шуларның иң әһәмиятлесе — **РФ Хезмәт кодексы,** ул гражданнарның хезмәт хокукларын һәм бурычларын билгели. Милекчелекнең төрле рәвешләрендәге предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре барлык боерыкларын һәм инструкцияләрен Кодекска нигезләнеп чыгаралар.

Дәүләтебез тарихында хезмәтне бурыч дип игълан итү чоры да булды («Кем эшләми — шул ашамый» — бу шигарь 1918 ел Конституциясенең хокукый нормасына әверелде), гәрчә хезмәт тәрбиясенә өстенлек бирү саклана да, балалар хезмәтеннән файдалануны тыю идеясе пропагандаланды. Балаларның хезмәте бары уку белән бәйләп кенә каралды. *Хәзерге законнарда 16 яше тулмаган затларны эшкә алу тыела*, укудан бушаган арада ата-аналар рөхсәте белән 14 яше тулган үсмер эшкә урнаша ала. Балигъ булмаган затлар өчен дәүләт тарафыннан кайбер ташламалар каралган: аларның сәламәтлегенә зыян китерерлек авыр һәм зарарлы эш шартлары, ял көннәрендә һәм төнлә эшләү катгый рәвештә тыела.

Мәктәпне тәмамлаган яшь кеше алдында аның өчен яңа дөньяга юллар ачыла. Әмма Конституциядә һәр кеше өчен каралган хезмәт хокукы дәүләт һәркемне ул яраткан һәм теләгән эш белән тәэмин итә дигәнне аңлатмый. Теге яки бу һөнәргә ихтыяҗ хезмәт базарының үзенә бәйле.

Ләкин эшләргә теләмәгән кешеләр дә бар. ***Безнең илдә хезмәт һәр кешенең ирекле һәм ихтыяри эше буларак таныла.*** Мәҗбүри хезмәт рөхсәт ителми.

Эшләргә теләге булып та, билгеле бер эше булмаган хезмәткә сәләтле зат эшсез кеше дип санала. Халыкны эш белән тәэмин итү буенча махсус үзәкләр, яшьләр өчен федераль программалар, буш хезмәт урыннары ярминкәләре, хезмәт биржалары — кешенең эш эзләүдә беренче ярдәмчеләре.

Хезмәт киңәгәсе хезмәт эшчәнлегенә турындагы төп документ булып тора. Анда хезмәт турындагы мәгълүмат, кызыксындыру ча-

ралары һәм бүләкләүләр турындагы белешмәләр теркәлә. (Хезмәт кенәгәләре беренче булып 1919 елда Мәскәүдә һәм Петроградта барлыкка килә.) ***Хезмәткәр белән эш бирүченең мөнәсәбәтләре теркәлгән документ — хезмәт шартнамәсе.*** Аның нигезендә хезмәткәр белгечлеге (вазыйфасы) буенча билгеле бер эш башкарырга һәм эш урынындагы эчке тәртип кагыйдәләрен үтәргә, ә эш бирүче аңа хезмәт хакы түләргә һәм тиешле хезмәт шартлары булдырырга тиеш. Кайбер төр хезмәт шартнамәләренә өстәмә махсус шартлар кертелергә мөмкин. Мәсәлән, берәр фирмага бухгалтер булып урнашучы хезмәткәр үз өстенә коммерция серен саклау бурычын ала, ә эш бирүче аны торак белән тәэмин итә һәм аның транспортта эш урынына килү һәм аннан китү өчен сарыф ителгән көндәлек чыгымнарын түли.

Теләсә нинди шартнамә язма рәвештә билгеле бер вакытка (5 елга кадәр) яисә вакытын чикләмичә төзелә. Предприятие (оешма) җитәкчесе эшкә алу турында боерык чыгара. Кайбер очракларда *сынау чоры* билгеләнә (өч яисә алты айга кадәр). Бу вакытта эшкә алынган кеше коллективның тулы хокуклы әгъзасы булып тора, үзенә йөкләнгән вазыйфаларны үти һәм хезмәт хакы ала.

Вакытын чикләмичә контракт төзелсә дә, бу әле эш мөнәсәбәтләренең даими дәвам итәчәген аңлатмый. Яклар үзара килешеп, аларны теләсә кайсы вакытта өзәргә дә мөмкиннәр. Һәр

хезмәткәр контрактны үз теләге белән өзә ала, аңа бу турыда ике атна алдан администрациягә хәбәр итәргә генә кирәк. Әгәр эш бирүче шартнамәне әлеге ике атнадан да иртәрәк өзәргә риза икән, хезмәт нормаларында моңа карата бернинди дә катгый тыюлар юк.

Кайбер очракларда эш бирүче үзе, хезмәткәр ризалык бирмәсә дә, шартнамәнең гамәлен туктатырга мөмкин. Мондый хокукый нормалар хезмәт дисциплинасының үтәлүенә ярдәм итәләр.

Хезмәткәрнең эш калдыруы, эш урынына салмыш хәлдә килүе, милек урлавы, үз вазыйфаларына салкын каравы аркасында сыйфатсыз продукция җитештерелү, үзе билгән вазыйфаларны үти алмавы — хезмәткәр ризалыгыннан башка хезмәт контрактын өзгәндә администрация шушыларга таянып эш итә.

Хезмәт шартнамәсе предприятие ябылган яисә штат кыскартылган очракта туктатыла.

Авыруы сәбәпле хезмәткәр озак вакыт эшкә чыга алмаса (рәттән дүрт айдан артык), бу хәл оешма эшчәнлегендә кыенлыклар китереп чыгарганлыктан, эш бирүче аның белән хезмәт мөнәсәбәтләрен өзәргә мөмкин. Мондый сәбәп белән эштән җибәрү башка юл булмаганда гына кулланыла. Эштән җибәрелгән кеше авыруын таныклаучы документ буенча (больничный лист) акча алуын дәвам итә. Әгәр хезмәткәр эш урынында җәрәхәт яисә һөнәри чир алса, аның хезмәт урынына озак чыкмавы эштән җибәрүгә сәбәп була алмый.

Авырган чорында яисә ялы вакытында хезмәткәрне эштән җибәрүне тыя торган кагыйдәләр бар.

Законда эш вакытының катгый чикләре билгеләнгән.

Эш атнасы 40 сәгатьтән тора. 16 яшьтән 18 яшькәчә үсмерләр, шулай ук укудан буш вакытларында эшләүче 14 яшьтән 16 яшькәчә укучылар өчен кыска эш вакыты (беренче очракта — атнага 36 сәгатьтән дә артыграк булмаган, икенче очракта — 24 сәгатькә кадәр) каралган. Авыр һәм зарарлы шартларда эшләүче кешеләргә; югары акыл һәм нервлар киеренкелеге таләп итүче хезмәт башкаручыларга; авыл җирендә эшләүче хатын-кызларга кыска эш сәгате билгеләнгән.

Кешенең ялга хокукы Россия Федерациясе Конституциясендә теркәлгән.

Хосусый хокук нормалары никах-гаилә мөнәсәбәтләрен җайга сала.

Яшь кешеләрнең никахлашу яшенә җитүе — гаилә кору өчен мөһим шартларның берсе. XV-XVII гасырларда Россиядә никахлашу ирләргә — 15 яшьтән, хатын-кызларга — 12 яшьтән, XX гасырда — 18 яшьтән рөхсәт ителгән; кияү белән кәләшнең никахлашу өчен яше, шулай ук алар арасында яшь аермасы хокукый яктан чикләнмәгән. Фәкать йөклелек, бала туу кебек очраклар килеп чыкканда гына җирле үзидарә органнары яшь кешеләргә 16 яшьтән никахлашырга ризалык бирәләр. Ата-ананың каршы килүе бернинди дә юридик көчкә ия булмый. 16 яшькә җитмәгән затка никахлашырга рөхсәт бирү мәсьәләсен Федерация субъектларына үзләренә хәл итү хокукы бирелгән.

Россиядә *күпхатынлылык тыелган.* Ислам дөньясының кайбер илләрендә ул рөхсәт ителгән.

Уллыкка (кызлыкка) алучы белән уллыкка (кызлыкка) алынучының, кан-кардәшләрнең никахлашуы тыелган. Цивилизацияле илләрдә мондый тыю мораль-этик күзаллаулардан чыгап аңлатыла, әмма физиологик сәбәпләрнең дә мөһим булуын онытмаска кирәк: кан катыштыру аркасында авыру балалар туарга мөмкин.

Никахлашу мәҗбүриләүгә корыла алмый, ул ир белән хатынның үзара килешүенә генә нигезләнә.

Яшь гаилә нинди хокукларга ия була? Ир белән хатын бер-берсенә терәк булырга тиеш. Аларның берсе (гадәттә хатын) сабыйларын тәрбияләүче буларак эшләмәскә дә мөмкин. Законда гаиләнең кереме булмаган, эшләмәүче һәм эшли алмаган, матди ярдәмгә мохтаҗ әгъзаларын яклау каралган.

Россия җирлегендә беренче буларак бала тудыруны арттыру өчен бөтенләй яңа чара кертелде. Әмма бу чараны башкалары белән бәйләнештә карарга кирәк. Ана капиталы турындагы закон проекты демографик вазгыятьне яхшыртуга юнәлдерелгән.

Икенче баласын тудырган анага 300 мең сумга (2009 ел) сертификат бирелә, бу суммадан салым алынмый.

Ир белән хатынның мөлкәти хокуклары беренче нәүбәттә аларның уртак милкенә кагыла. *Мөлкәтле булу һәм аның белән эш итүнең законлы һәм шартнамәле төрләре була.* Законда гаилә корып яшәгән

чорда сатып алынган мөлкәтләре ир һәм хатынның уртак милке булуы каралган (мәсәлән, туйдан соң сатып алынган телевизор яисә кер юу машинасы). Әгәр бергә яшәгән чорда, әйтик, ир үз исеменә яздыртып машина яисә дача сатып алган икән, аның хатынының да бу мөлкәткә тулы хокукы була. Әгәр уртак мөлкәт мәҗбүри рәвештә бүленә икән, ир белән хатын тигез өлешләргә ия булалар. Ир яисә хатынның шәхси әйберләре (зиннәтле әйберләрдән гайре), никахлашканчыга кадәр ия булган яисә аларның берсенә бүләк ителгән, шулай ук мираска калдырылган мөлкәт бүленми, иясендә кала.

Ир белән хатын мөлкәтенең шартнамәле режимы *никах контрактына* нигезләнә. Гаилә коручыларның шундый контракт төзү мөмкинлеге бар. Анда ир һәм хатынның уртак мөлкәтләренә, бер-берсенең матди кеременә ия булу шартлары карала. Әмма законда гаять мөһим бер принцип бар: никах шартнамәсендә ирнең яисә хатынның кайсысын булса да түбәнсетә, аның граждан буларак ия булган аерылгысыз хокуклары бозылуга китерә торган шартлар булмаска тиеш. Киресенчә булганда, шартнамә гамәлгә яраксыз дип таныла. Никах шартнамәсен ир белән хатын икесе дә риза булган очракта теләсә кайсы вакытта өзәргә мөмкин. Әгәр балигъ булмаган балалары юк икән һәм ир белән хатын аерылышырга икесе дә ризалык белдерәләр икән, аларны ЗАГСка биргән гаризаларына нигезләнеп аералар. Әгәр я ир, я хатын аерылышуга каршы икән яисә аларның балалары бар икән, бу мәсьәлә судта хәл ителә. Хатыны йөкле булганда һәм баласы туганнан соң бер ел узмыйча торып, ир аерылышу турында эш кузгата алмый.

Россия БМОның Бала хокуклары турындагы конвенциясендә катнаша. Бу документта кечкенә кешенең гаиләдә яшәүгә һәм тәрбияләнүгә табигый хокукы яклана. Үз-үзенә ризык табу, дәвалану яшенә җитмәгәнлектән, бала ата-ана кайгыртуына хокуклы.

Төшенчәләр: *хосусый хокук, хокукка сәләтлелек, хезмәткә сәләтлелек, юридик зат, хезмәт турындагы законнар кодексы.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Граждан әйләнешендә катнашучылар буларак физик затларга юридик характеристика бирегез.

2. Хезмәт өлкәсендәге хокукый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләренә аңлатма бирегез. Хезмәт контрактын төзегәндә нәрсәләрне исәпкә алырга кирәк?

3. Ир белән хатынның мөлкәт мөнәсәбәтләрен җайга салуның шартнамәле режимы законлысыннан нәрсә белән аерыла?

4. РФ Хезмәт кодексында балигъ булмаганнар хезмәтенең нинди үзенчәлекләре күрсәтелгән?

***5.** Эшкуарлык белән шөгыльләнергә теләүче танышыгыз сезгә киңәш сорап мөрәҗәгать итте ди. Үзегезнең белемнәрегезгә таянып, мондый эшчәнлекнең кайбер юридик үзенчәлекләренә аңлатма бирегез.

***6.** Эшкуарлыкка, гражданлыкка, гаиләгә һәм өлешчә хезмәткә кагылышлы юридик нормалар ни өчен хосусый хокукка кертеләләр?

? Проблема. Хезмәткә сәләтле булмаган затларга хосусый хокук нормаларының кагылышы бармы?

✍ Практикум. Хезмәт яисә никах шартнамәсе төзегез һәм аларга нинди пунктларны кертергә һәм ни өчен кертергә кирәклекне аңлатып бирегез.

2 (8) бүлек

Җәмгыятьнең социаль системасы



§ 5 (§ 26). Социаль стратификация

Социаль стратификациянең социаль катламнарга бүленеш икәнлеге 8–9 классалар өчен җәмгыять белеме курсыннан сезгә мәгълүм инде. Фәндә, җәмгыятьнең төзелешен Җир шары төзелешенә охшатып, социаль катламнарны (стратларны) шулай ук вертикаль урнаштыру бар. Керемнәр баскычы нигез итеп алына: иң түбәндә — фәкыйрьләр, уртада — халыкның хәлле төркеме, иң югарыда байлар урнаша.

Эре иҗтимагый катламнарны (стратларны) шулай ук класслар дип тә атыйлар. Алар ваграк бүлекчәләрдән (катламнарны яисә стратларны нәкъ менә шулар тәшкил итә дә инде) тора. Байлар сыйныфы *югары* (бик байлар, миллиардерлар) һәм *түбән* (байлар, миллионерлар) катламнарга бүленә. Урта сыйныф *өч* катламнан, ә түбән, яки ярлы класс — *ике* катламнан тора. Соңгысының иң түбән катламын әле тагын *андерсыйныф* яки «тормыш төбе» дип тә атыйлар.

Гомумән алганда, ***социаль-икътисади статус,*** ягъни кешенең җәмгыятьтәге урыны ***аның керемнәре, хакимияткә ия булу-булмавы, абруе һәм белем дәрәҗәсе белән билгеләнә.*** Бу очракта статус бүленешнең гомуми күрсәткече булып тора. *Кешегә билгеләп куелган статус бик катгый урнаштырылган бүленеш системасын, ягъни ябык җәмгыятьне характерлый.* Мондый җәмгыятьтә бер катламнан икенчесенә күчү бөтенләй мөмкин түгел диярлек. Боларга коллыкны һәм касталы җәмгыятьне кертәләр. *Кешенең билгеле бер статуска ирешү мөмкинлегеге бүленешнең хәрәкәтчән систе-*

масына, ягъни ачык җәмгыятькә хас. Бу очракта кешеләр социаль баскыч буйлап иркен хәрәкәт итә ала. Мондый системага *капиталистик җәмгыятьне (базар мөнәсәбәтләренә корылган җәмгыятьне)* кертәләр. Һәм, ниһаять, үзенә хас социаль катлаулар төзелеше белән феодаль җәмгыятьне арадаш төргә, ягъни *чагыштырмача ябык системага* кертү дөрес булыр. Биредә күчешләр юридик яктан тыелган, әмма чынлыкта алар еш кына булгалый. Бүленешнең тарихи төрләре түбәндәгеләр:

коллык касталар катлаулар	ябык җәмгыять
сыйныфлар	ачык җәмгыять

Бүленеш (стратификация), ягъни керемнәрнең, хакимияткә ия булуның, абруй һәм белем дәрәҗәсенең тигезсезлеге кешелек җәмгыятенең иң тәүге адымнарыннан ук барлыкка килгән. Ярал-гы рәвешендә ул инде гади (борынгы) җәмгыятьтә үк булган. Иң тәүге дәүләтчелек — көнчыгыш деспотиясендә катламнарга катгый бүленеш урнаштырыла, ә Европа җәмгыяте үсеш алган, әхлакый кануннар йомшара барган саен бүленеш тә катгыйлыгын җуя бара. Катлаулар (сословиеләр) строенда касталар һәм коллык җәмгыятьләре белән чагыштырганда ирек күбрәк була, ә сыйнфый җәмгыять тагын да либеральләшә.

Коллык — тарихта беренче социаль бүленеш системасы. Коллык бик борынгы заманнарда ук Мисырда, Вавилонда, Кытайда, Грециядә һәм Римда барлыкка килгән һәм кайбер регионнарда әле хәзергә кадәр сакланып калган. АКШта әле XIX гасырда да коллык гамәлдә була.

КОЛЛЫК — кешеләрне тулы хокуксызлык һәм иң югары дәрәҗәдәге тигезсезлек чигенә китереп җиткерелгән бәйлелеккә төшерүнең икътисади, социаль һәм юридик төре.

Коллык тарихи үсеш кичерде. Гади төр, яисә патриархаль коллык белән коллыкның җитлеккән төре яки классик коллык арасында

шактый аерма бар. Беренче очракта кол гаиләнең аз хокуклы әгъзасы була: хуҗалар белән бер үк йортта яши, җәмәгать тормышында катнаша, ирекле кешегә өйләнә яисә кияүгә чыга, хуҗасының милкеннән мирас ала. Аны үтергән өчен җәза бирелми. Җитлеккәнлек чорында исә колны ахыргача кабалага төшерәләр: ул хуҗалардан аерым яши, гаилә төзи алмый, җәмәгать тормышына аны катнаштырмыйлар. Аны үтерергә рөхсәт ителә. Колның милке булмый, ул үзе хуҗасының милке («телле хезмәт коралы») булып санала.

Коллыктагы кебек үк, касталы җәмгыять өчен дә ябыклык һәм катгый бүленеш хас. Ул колбиләүчелек җәмгыяте кебек үк борынгы түгел һәм аның таралышы да кимрәк. Барлык илләрдә, әлбәттә, төрлесендә төрле дәрәҗәдә, коллык булган, ә менә касталар бары Һиндстан һәм өлешчә Африка өчен генә хас. Һиндстан — касталы җәмгыятьнең классик үрнәге. Ул яңа эраның башында, колбиләүчелек җәмгыяте җимерелгәч барлыкка килә.

КАСТА — кеше аңа фәкать тумышына гына карап кертелә торган социаль төркем (страта).

Исән чагында кеше бер кастадан икенчесенә күчә алмый. Моның өчен аңа яңадан туарга кирәк. Кешеләрнең касталарга бүленүе индуизм диненнән килә (касталарның аз таралышы менә аңлашыла хәзер). Аның кануннары кеше бердән артык гомер кичерә дип өйрәтә. Яшәлгән гомерендәге тәртибе нинди булуга карап, һәр кеше тиешле кастага эләгә. Әгәр ул начар булган икән, яңадан туганнан соң ул — түбән кастага, яхшы булса, югарысына эләгергә тиеш.

Һиндстанда барлыгы 4 төп каста бар: *брахманнар* (дин әһелләре), *кшатрийлар* (гаскәриләр), *вайшилар* (сәүдәгәрләр), *шудралар* (эшчеләр һәм крестьяннар). Тагын әле 5 меңгә якын эрелеваклы каста һәм касталарга бәйле төркемнәр бар. *Кагылгысызлар* (читләштерелгәннәр) аерым торалар — алар касталарның берсенә дә кермиләр һәм җәмгыятьнең иң түбән баскычын тәшкил итәләр. Сәнәгать үскән саен касталар сыйныфларга алышына бара. Һиндстан шәһәрләрендә сыйныфлар өстенлеге урнаша килә, ә ил халкының уннан җиде өлеше яшәгән авылларда касталарга бүленеш саклана.

Сыйныфларга кадәр җәмгыять катлауларга (сословиеләргә) бүленгән була. IV гасырдан XIV гасыргача Европаның феодаль җәмгыятьләрендә шундый бүленеш яшәгән.

КАТЛАУ — гореф-гадәтләргә яисә юридик законга таянып беркетелгән һәм нәсел буенча тапшырыла торган хокукларга һәм бурычларга ия булган социаль төркем.

Берничә стратадан торган катлау системасы өчен кешеләрнең тормышта тоткан урыны һәм өстенлекләргә ия булу дәрәҗәсе тигезсезлегендә чагылыш тапкан иерархия хас. Җәмгыятьнең катлауларга бүлеп оештырылуына классик мисал буларак XIV гасыр ахыры XV гасыр башында Европа илләрен күрсәтергә мөмкин. Биредә җәмгыять ике *югары катлауга: дворяннарга һәм руханиларга һәм өстенлексез өченче катлауга: һөнәрчеләргә, сәүдәгәрләргә һәм крестьяннарга* бүленә. X–XIII гасырларда төп катлау өчәү була. Болар: руханилар, дворяннар һәм крестьяннар. Россиядә XVIII гасырның икенче яртысыннан *дворяннар, руханилар, сәүдәгәрләр, крестьяннар* һәм *мещаннар* (урта шәһәр катлавы) катлауларына бүленеш барлыкка килә. Катлауларга бүленеш кешеләрнең милкендә җир булу-булмауга нигезләнә.

Төрле катлауларга керүче кешеләрнең хокуклары һәм бурычлары юридик закон нигезендә билгеләнә һәм дини канун аларны изге дип игълан итә. Катлау әгъзасы булу хокукы нәсел буенча күчә. Катлаулар арасындагы киртәләр шактый катгый булганга, социаль хәрәкәтчәнлек катлаулар арасында баруга караганда, ешрак катлауның үз эчендә бара. Һәр катлау бик күп катламнардан, ранглардан, дәрәҗәләрдән, һөнәрләрдән, чиннардан тора. Әйтик, дәүләт хезмәтенә бары дворяннар гына алынган. Аксөякләр (аристократлар) хәрби катлау (рыцарьлар) булып саналган.

Иҗтимагый иерархиядә никадәр югарырак урын тотса, катлауның статусы шуның кадәр югарырак булган. Касталардагыдан аермалы буларак, төрле катлау кешеләре арасында никахлашу рөхсәт ителгән, аерым бер кешенең икенче катлауга күчүе дә тыелмаган. Гади кеше, мәсәлән, хакимлек итүченең рөхсәтен сатып алып, рыцарь булып китә алган. Сәүдәгәрләр акча түләп дворянлык титуллары алганнар. Мондый хәл искелек калдыгы буларак өлешчә хәзерге Англиядә әле дә күзәтелә.

Социаль символларга һәм тамгаларга, ягъни чиннарга, титулларга, исемнәргә, мундирларга, орденнарга ия булу — катлаулар өчен хас сыйфат. Гәрчә киемнәре, бизәнү әйберләре, үз-үзләрен тотудагы норма һәм кагыйдәләре, мөгамәлә ритуаллары белән аерылып

торсалар да, сыйныфларның һәм касталарның дәүләт тарафыннан бирелгән аерымлык билгеләре булмый. Феодаль җәмгыятьтә дәүләт аерымлык билгеләрен төп катлау — дворяннарга бирә торган була.

Чин — һәрбер дәүләт хезмәткәренә (хәрби, штаттагы һәм сарайда хезмәт итүче) бирелә торган ранг. Петр I заманына кадәр «чин» дигәндә, кеше биләгән теләсә нинди вазыйфаны, аның җәмгыятьтәге урынын, мактаулы исемен күздә тотканнар. 1722 елда Петр чиннарны катгый системага сала. Ул система «Ранглар турындагы табель» атамасы белән билгеле. Дәүләт хезмәтенең һәр төре 14 рангка, яки класска бүленә. Класс хезмәт вазыйфасының рангын билгели һәм класслы чин дип аталып йөртелә.

Хәрби чиннар өч зур төркемгә бүленгән: генерал чиннары (1 нчедән 5 нче класска кадәр), штаб-офицер чиннары (6 нчыдан 8 нчегә кадәр, мәсәлән, полковник) һәм обер-офицер чиннары (9 нчыдан 14 нчегә кадәр; ротмистр, поручик).

Граждан хезмәте (статская служба) түбәнрәк торган һәм азрак өстенлекләр биргән. Әйтик, нәселле дворянлык бары 8 нче класс әгъзасы (колежский асессор) булуга ирешкәч кенә бирелгән. 1856 елда чиннар бирүдә кешенең нинди катлауга керүенә игътибар итми башлыйлар, карьера ясау тизлеге моннан соң белемгә һәм хезмәттәге уңышларга бәйле була.

Мактаулы исемнәр барлык чиннар, шулай ук дәүләт хезмәткәре булмаган затлар, өчен ***аерымлык билгесе*** булып торган, әйтик, мактаулы опекун шундыйлардан.

> **ТИТУЛЛАР** — аларга ия булган кешеләрнең хезмәттәге хәленең һәм катлавының, нәсел-нәсәбенең сүз белән аталышы. Бу билгеләмә законда теркәлә һәм кыскача кешенең хокукый статусын белдерә.

XIX гасырда Россиядә гомуми, хосусый һәм нәсел титуллары була. Өстенрәкләргә мактаулырак гомуми титул бирелә. Әйтик, 1 нче һәм 2 нче класс чиннарына — «Ваше высокопревосходительство», 3 нче һәм 4 нче класснықыларга — «Ваше превосходительство» («Галиҗәнап») дип мөрәҗәгать иткәннәр. Хосусый титул белән исемнәр, чиннар һәм вазыйфалар билгеләнгән. Аларны өстен (гомуми титулдан соң) һәм түбән (вазыйфасын һәм чинын гына атап)



чиннарга мөрәҗәгать иткәндә бердәй кулланганнар. Нәсел титуллары кешенең тумышын күрсәткән — светлейший князь («Ваша светлость»), князь, граф («Ваше сиятельство»). Әгәр түрәнең нәсел титулы булса, аңа мөрәҗәгать иткәндә бары шуны гына кулланганнар.

Дәүләт хезмәтенә бары урындагы һәм йомышлы дворяннарны гына алганнар. Аларның һәрберсе нәселдән нәселгә күчкән: дворянлык исеме гаилә башлыгының хатынына, балаларына һәм ират ягыннан баручы нәселгә бирелгән. Дворянлык статусы гадәттә шәҗәрә, нәсел гербы, ата-бабаларның рәсемнәре, риваять, титуллар һәм орденнар рәвешен алган. Шул рәвешчә акрынлап кешеләр аңына буыннар дәвамчанлыгы, үз нәселең өчен горурлык һәм аңа тап төшермәскә омтылу хисләре сеңдерелә барган. Аларның җәмгысы «дворянлык намусы»н тәшкил иткән, әйләнә-тирәдәгеләрнең тапсыз исемгә хөрмәт һәм ышаныч белдерүе соңгысының мөһим өлеше буларак каралган. Тумышы белән дворянның затлылыгы аның нәселенең Ватан алдындагы казанышлары белән билгеләнгән.

Колбиләүчелек, касталы һәм катлауларга бүленгән феодаль җәмгыятьләрдә кешенең нинди социаль катлауга керүе рәсми-хокукый яисә дини нормалар белән теркәлгән. ***Сыйнфый җәмгыятьтә*** *башкачарак: шәхеснең социаль структурадагы урыны бернинди рәсми кәгазьләрдә беркетелми.* Һәр кеше сәләтенә, белеме һәм табышына карап, бер сыйныфтан икенчесенә күчә ала. Кайбер илләрдә өч сыйныф һәм аларның берничә катлавы аерым йөртелә.

Югары — өстен сыйныф байлыкларын буыннан-буынга туплап килгән «кан буенча аксөякләр» керә. Алар үзенчәлекле тормыш рәвеше алып баралар.

Түбән — югары сыйныф башлыча «яңа байлар»дан тора. Аларның сәнәгатьтә, эшкуарлыкта, сәясәттә югары вазыйфалар биләүче куәтле нәсел кланы юк. Мәсәлән, уннарча миллион керем алучы, әмма нәселендә «кан буенча аксөякләр» булмаган профессиональ баскетболчы яисә эстрада җырчысы.

Югары — урта сыйныф вак буржуазиядән һәм күренекле адвокатлар, мәшһүр табиблар, актерлар һәм телевидение комментаторлары кебек югары хезмәт хакы ала торган белгечләрдән тора. Аларның тормыш рәвеше югары катлауныкына якын булса да, дөньяның иң кыйммәтле курортларында зиннәтле вилла яисә сирәк сәнгать әсәрләре коллекциясен сатып алырга акчалары әлегә җитеп бетми.

Урта — урта сыйныф югары үсеш алган индустриаль җәмгыятьнең иң күпсанлы катламын тәшкил итә. Аңа яхшы хезмәт хакы ала торган барлык хезмәткәрләр, хезмәтләренә уртача түләнә торган белгечләр, җыеп әйткәндә, интеллигентлар, шул исәптән югары уку йортлары, мәктәп укытучылары, табиблар, урта буын менеджерлары керә. Болар — мәгълүмати җәмгыятьтә һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә төп көч.

Түбән — урта сыйныфка иң түбән баскычтагы хезмәткәрләр һәм квалификацияле белгечләр керә. Алар башкарган эш физик хезмәткә караганда, күбрәк акыл хезмәтенә тартым була. Аерымлыклары — шактый лаеклы тормыш рәвеше.

Югары — түбән сыйныф массакүләм җитештерү өлкәсендә, җирле завод-фабрикаларда эшләүче уртача һәм түбән квалификацияле эшчеләрдән тора. Алар чагыштырмача җитеш тормышта яшиләр, әмма үз-үзләрен тотышы ягыннан югары һәм урта класслардан шактый аерылып торалар. Аерымлыклары: түбән белем (гадәттә тулы яисә тулы булмаган урта, махсус урта белем), пассив ял итү рәвеше (телевизор карау), примитив күңел ачулар, еш кына спиртлы эчемлекләр, сүгенү сүзләре куллану.

Түбән — түбән сыйныфны подвалларда, чарлакларда, җимерек йортларда һәм яшәү өчен яраксыз башка урыннарда көн күрүчеләр тәшкил итә. Алар бөтенләй белемсез яисә бары башлангыч белемле, күбрәк очраклы эш башкарып, шуның өчен алган акча хисабына көн күрәләр, хәер сорашалар, үтә чыккан хәерчелек һәм даими мыскыллаулар аркасында кимлек комплексы кичерәләр. Аларны «тормыш төбе», яисә андерсыйныф дип атау кабул ителгән. Аңа дәвалап бул-

мый торган эчкечеләр, иректә тормышын көйли алмаган элеккеге тоткыннар, бомжлар һ.б. керә.

Җәмгыятьтә **урта сыйныф** аерым, социаль һәм сәяси тотрыклылыкны тәэмин итү ролен уйный. Югары үсешле илләрдә ул халыкның күпчелеген — 60 тан алып 80 процентка кадәр өлешен тәшкил итә. Күчеш чоры кичерә дип саналган Россия җәмгыятендә урта классның өлеше алай ук югары түгел. Төрле бәяләмәләргә караганда, ул халыкның 12 дән 25 процентка кадәр өлешен тәшкил итә. Сәнәгать һәм икътисад үсә барган саен урта классның халыкның гомуми санында өлеше арта барачак.

Төшенчәләр: *социаль бүленеш (стратификация), коллык, касталар, катлаулар, сыйныфлар, ябык җәмгыять, ачык җәмгыять.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Мисалларны күбрәк Россия җирлегеннән китереп, катлауларга бүленгән җәмгыятькә хас сыйфатларны атагыз.

2. Сыйнфый системаның асылы нидән гыйбарәт?

3. Җәмгыятьтә урта сыйныф нинди роль уйный? Ни өчен аның гомуми халык санындагы өлеше Россиядә АКШтагыдан һәм Көнбатыш Европадагыннан кимрәк?

4. Үзегез теләгән теләсә нинди ике социаль сыйныфның (яисә ике катламның) яшәү рәвешен, керемнәрен, торак шартларын, сатып алу мөмкинлекләрен тасвирлап бирегез.

***5.** Газеталарда кайбер илләрдә әле хәзер дә коллыкның бетерелмәве турында язалар. Коллар тормышыннан реаль мисаллар китерелә һәм аларның нинди шарталарда асралуы тасвирлана. Сезнең фикерегезчә, антик чордагы һәм хәзерге чордагы коллык арасында нинди уртаклыклар һәм нинди аерымлыклар бар?

***6.** Сезнеңчә ничек: хәзерге Россиядә ни өчен дворян титулларын һәм исемнәрен кире кайтаралар икән? Сезгә бу турыда ниләр мәгълүм?

? Проблема. Хәзерге Россиянең икътисади һәм социаль үсеше социаль бүленешкә ничегрәк тәэсир итә?

✍ **Практикум 1.**. Һәрбер социаль сыйныфның үз элитасы булырга охшый.

1. Байларда ул 0,5 процентын тәшкил итә һәм үтә байлар төркеме дип атала.

2. Эшчеләр сыйныфында бу — эшчеләр аристократиясе дип аталган төркем. Гадәттә ул үз сыйныфларының гомуми санының 10 процентын тәшкил итә.

3. Түбән сыйныфның да үз «элитасы» була — бу андерсыйныф (хәерчеләр), алар 2 — 7 процентны тәшкил итәләр.

Урта сыйныф элитасы бармы? Җавабыгызны дәлилләгез.

✍ **Практикум 2.** Социаль статусның ике төре бар: бирелгән һәм ирешелгән. Кешенең туганда ук ия булган (***тумыштан статус***), тора-бара җәмгыять яисә төркем тарафыннан һичшиксез танылган статусы **бирелгән** статус дип атала.

Аңа кешенең җенесе, милләте һәм расасы керә. Афроамерикалы — тумыштан статус дигәндә, бу очракта тән төсен һәм организмның шуның белән бәйле физиологик үзенчәлекләрен үзгәртү мөмкин түгеллеге күздә тотыла. Әмма АКШтагы, КАРдагы һәм Кубадагы афроамерикалыларның социаль статусы төрлечә. Күпчелек илләрдәге кебек, Кубада, мәсәлән, афроамерикалы ул — абсолют күпчелекне тәшкил итүче төп халык вәкиле, ул башкалар белән тигез хокукларга ия. Кубадагы кебек үк, КАРда да афроамерикалылар халыкның күпчелеген тәшкил итә, әмма апартеид чорында алар сәяси һәм социаль дискриминациягә дучар ителәләр.

АКШта афроамерикалылар — халыкның азчылыгы, әмма билгеле бер тарихи чордагы хокукый вазгыять КАРдагы вазгыятькә якын була.

Ә хәзер түбәндәге күнегүләрне эшләгез.

1. Түбәндәге статуслар «бирелгән» статуска керәме:

Император.

Католиклар чиркәве башлыгы.

Сенатор.

Президент.

Каената.

Хатынының ире.

Украиналы.

Принц.

Герцог.

Бояр улы.

Опричник.

Вельможа?

2. Үзегезнең статуслар җыелмагызны ачыклагыз: статусларыгызның кайсылары — бирелгәнгә, кайсылары ирешелгәнгә керә? Сезнең ата-анагызның, туганнарыгызның һәм дусларыгызның статуслары ниндирәк?

3. Үзегезнең, әти-әниегезнең, шулай ук 23 таныш-белешегезнең төп статусын билгеләгез.

4. Кайбер статуслар бик әһәмиятле булулары аркасында, шәхеснең статуслар җыелмасы нинди булуга карамастан, төп статуска әвереләләр. Әйтик, дөнья чемпионы, Нобель премиясе лауреаты. Тагын шундый берничә мисал китерегез.

5. Үзегезнең яки танышларыгызның катнаш статусларын атагыз.

6. Өлкән бала — социаль статус. Яраткан бала — шәхесара статус. Ни өчен шулай? Аңлатып бирегез.

§ 6 (§ 27). Социаль хәрәкәтчәнлек (мобильлек)

Белүегезчә, ***социаль статус — төркемнең яисә җәмгыятьнең социаль структурасындагы билгеле бер позиция һәм ул башка позицияләр белән хокук һәм бурычлар системасы аша бәйләнештә була.***

Һәр кешенең үзенә генә хас, ягъни барлык детальләрен тулысынча кабатлап булмый торган статуслар җыелмасы була. Ул, физик киңлектә бер матдәне тәшкил итүче күпсанлы нокталар җыелмасы кебек үк, кешенең социаль киңлектәге тоткан урынын, ягъни шәхеснең җәмгыятьтәге позициясен төгәл билгели.

Бер статусны икенчесенә алыштыру, гадәттә кешенең бер социаль төркемнән башкасына күчүен аңлата. Әйтик, үсмерлектән егетлеккә, католиклыктан православиегә, мәктәп укучысыннан студентлыкка күчү һ.б. Кешеләр — һәрвакыт хәрәкәттә, ә җәмгыять

үсештә була. ***Кешеләрнең җәмгыятьтәге социаль күчешләре җыелмасы, ягъни статуслары үзгәрүе, социаль хәрәкәтчәнлек дип атала.*** Бу тема кешелекне күптәннән кызыксындыра. Кешенең көтмәгәндә күтәрелеп китүе яисә түбәнгә тәгәрәве **сюжеты** халык әкиятләрендә еш очрый: зирәк ярлы егет кинәт кенә баеп китә, ярлы принц корольлек тәхетенә утыра, ә эшсөяр Көлбикә принцка кияүгә чыга һәм үзенең җәмгыятьтәге статусын, абруен күтәрүгә ирешә.

Әмма кешелек тарихы хосусый язмышлардан гына тормый шул, аны иң беренче нәүбәттә зур социаль төркемнәр хәрәкәте тәшкил итә. Җир аристократиясенә алмашка финанс буржуазиясе килә, түбән квалификацияле һөнәр ияләре заманча җитештерү өлкәсеннән «ак якалылар» вәкилләре — инженерлар, программистлар, роботлар кулланыла торган комплекслар операторлары тарафыннан кысрыклап чыгарыла. Сугышлар һәм инкыйлаблар нәтиҗәсендә җәмгыятьнең социаль структурасы үзгәреш кичерә, түбәндәгеләр югары күтәрелә, югарыдагылар, киресенчә, түбән тәгәри. Россия җәмгыятендә мондый үзгәрешләр 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң килеп чыкты. Мондый үзгәрешләр бүген дә дәвам итә: партия элитасына алмашка бизнес-элита килә.

Социаль хәрәкәтчәнлекнең ике төп төре бар: **вертикаль** һәм **горизонталь.** Вертикаль хәрәкәтчәнлек бер катламнан (катлаудан, сыйныфтан) икенчесенә күчүне аңлата. Хәрәкәтнең юнәлешенә бәйле рәвештә югарыга хәрәкәт итү (социаль күтәрелеш) һәм түбәнгә таба хәрәкәт итү (социаль баскычтан түбән төшү) була. Югарырак вазыйфага билгеләнү — югарыга хәрәкәт итүгә, ә эштән азат ителү, түбәнрәк вазыйфага күчерелү — түбәнгә хәрәкәт итүгә мисал. **Горизонталь хәрәкәтчәнлек** шәхеснең бер социаль төркемнән шул ук яссылыкта урнашкан икенче төркемгә күчүен аңлата. Әйтик, кешенең православиедән католиклыкка чыгуы, бер гражданлыктан икенчесенә, бер гаиләдән (әти-әнисенекеннән) башкасына (үзе төзегәнгә) күчүе, һөнәрен алыштыруы шуңа мисал була. Мондый хәрәкәт вакытында кешенең социаль хәлендә вертикаль юнәлештә сизелерлек үзгәрешләр килеп чыкмый.

Элеккеге статусын саклаган хәлдә, кешенең бер урыннан икенчесенә күченүе — *географик хәрәкәтчәнлек* — горизонталь хәрәкәтнең бер төре булып тора. Әйтик, халыкара һәм төбәкара туризм, кешенең шәһәрдән авылга яисә, киресенчә, авылдан

шәһәргә күченүе, бер предприятиедән икенчесенә күчүе географик хәрәкәтчәнлеккә мисал була ала. Әгәр урын алмаштыруга статус алышынуы да өстәлсә, географик хәрәкәтчәнлек *миграциягә* әйләнә. Әгәр авыл кешесе шәһәргә туганнарының хәлен белергә килгән икән, бу географик хәрәкәтчәнлек була. Ә инде ул шәһәргә даими яшәр өчен күченсә һәм эшкә урнашса, бу инде миграция була. Кеше бу очракта һөнәрен үзгәртә.

Моннан тыш, социаль хәрәкәтчәнлек *төркемле* дә булырга мөмкин, бу вакытта шәхес социаль баскыч буенча үз төркеме (катлавы, сыйныфы) белән я өскә менә, я аска төшә. ***Хосусый социаль хәрәкәтчәнлек*** тә була, бу очракта шәхес социаль баскыч буйлап хәрәкәтен башкаларга бәйсез рәвештә башкара. Төркемле хәрәкәтчәнлекнең сәбәпләре түбәндәгеләр: социаль революцияләр, чит ил интервенциясе, һөҗүмнәр, дәүләтара һәм гражданнар сугышлары, хәрби борылышлар, сәяси режимнарның алышынуы, иске конституциянең яңага алыштырылуы һ.б. ***Хосусый хәрәкәтчәнлек*** факторларына түбәндәгеләр керә: *гаиләнең социаль статусы, шәхеснең белем дәрәҗәсе, милләте, физик һәм акыл сәләте, тышкы кыяфәте, нинди тәрбия алуы, яшәү урыны, файда исәбенә корылган никахы.*

Хәрәкәтчән шәхесләр социаль баскыч буйлап хәрәкәт итүләрен бер сыйныф вәкиле буларак башлыйлар, башкасыныкы буларак тәмамлыйлар. Алар бер-берсеннән аерылып торучы мәдәниятләр һәм тормыш рәвешләре арасында чын мәгънәсендә икегә аерылырга мәҗбүр булалар, башка сыйныф стандартлары күзлегеннән чыгып караганда үз-үзләрен ничек тотарга, ничек киенергә, сөйләшергә кирәклеген белмичә аптырыйлар. Еш кына яңа шартларга җайлашу кешенең күңел тирәнлегенә үтеп керә алмый, өске кабык кына булып кала. Мольерның дворяннар арасына эләккән мещан турындагы кыйссасында шундый вакыйга бәян ителә. (Бер сыйныфтан, катлаудан икенчесенә күчкәндә кешенең манералары тирәнтен үзгәреш кичермәвен сурәтләүче башка әдәби персонажларны атагыз.)

70 еллык тарихында совет җәмгыяте, АКШ белән беррәттән, дөньядагы иң хәрәкәтчән җәмгыять иде. Халыкның барлык катламнары өчен дә түләүсез белем алуга юл ачылу һәркемгә үсеш мөмкинлеге бирде. Аз вакыт эчендә җәмгыятьнең барлык катламнарыннан җәмгыять элитасы оешты.

Совет җәмгыяте белем алуда һәм социаль хәрәкәтчәнлектә генә түгел, индустриаль үсеш өлкәсендә дә тиз алга барды. СССР озак ел-

лар индустриаль алгарыш темплары буенча беренчелекне бирмәде. Шушы заманча индустриаль җәмгыять күрсәткечләре СССРны дөньяның алдынгы илләре сафына чыгарды (бу турыда көнбатыш социологлары язды).

Кешеләргә өскә күтәрелү мөмкинлеге бирә торган юллар һәм механизмнар вертикаль хәрәкәтчәнлек каналлары дип атала. П.Сорокин аларга аеруча тулы тасвирлама бирә. Вертикаль хәрәкәтчәнлек теләсә кайсы (хәтта борынгы) җәмгыять өчен дә хас булганлыктан, катлаулар арасында төрле «аралыклар», «лифтлар», «мембраналар» була, алар буйлап шәхесләр өскә яисә аска хәрәкәт итәләр. Иң күп танылган каналлар — армия, дин тоту, мәктәп, гаилә, милек.

Канал сыйфатында армия бары сугыш чорында гына гамәлдә була. Командирларның һәлак булуы аларның урынына түбәнрәк чиннарның алынуына китерә. Сугыш вакытында солдатлар үз сәләте һәм батырлыгы хисабына үсүгә ирешәләр. Югарырак звание алгач, алар кулларындагы хакимиятне тагын да югарырак үсү өчен файдаланалар. Римның туксан ике императоры арасыннан утыз алтысы бу дәрәҗәгә түбән чиннардан башлап ирешүе мәгълүм. Византиянең алтмыш биш императорыннан уникесе армиядә карьера ясау нәтиҗәсендә тәхеткә утырган. Наполеон Бонапарт һәм аның даирәсе, маршаллары, генераллары һәм Европада ул тәхеткә утырткан корольләр — гади халыктан чыккан кешеләр. О. Кромвель, У.С. Грант, Дж. Вашингтон һәм күп кенә гаскәр башлыклары армиядәге уңышлары аркасында иң югары дәрәҗәләргә ирешкәннәр.

Мәктәп. Белем һәм тәрбия бирү институтлары, төрләренә карамастан, гомер-гомергә социаль әйләнешнең гаять әһәмиятле каналы булып тора. Демократик илләрдә җәмгыятьнең барлык әгъзаларына мәктәптә уку мөмкинлеге бирелә. Күп кенә илләрдә колледжларга һәм университетларга керү өчен конкурс зур булу — белем вертикаль хәрәкәтчәнлекнең иң тиз һәм иң ансат каналы дигәнне аңлата. Мондый җәмгыятьтә «социаль лифт» иң түбәнге катламнан башлап, бөтен «этажлар» аша уза һәм иң югарыга менеп житә дигән сүз. Борынгы Кытай «озын лифт»ка уңышлы мисал булып тора. Конфуций чорында мәктәпләрдә бөтен сыйныф балалары да укый алган. Һәр өч ел саен имтиханнар уздырылган. Иң яхшы укучы балалар, аларның гаилә статусы нинди булуга игътибар итмәстән, сайлап алынганнар һәм югары мәктәпләргә, ә аннан соң инде университетларга күчерелгәннәр, шуннан алар югары дәүләт вазыйфаларына билгеләп куелганнар.

Милек, тупланган байлык һәм акча сыйфатында, социаль үсеш өчен аеруча үтемле һәм гади ысул булып була. XV–XVIII гасырларда Европа җәмгыятендә акча хакимлеге урнаша. Югары дәрәҗәгә акчасы булганнар гына ирешә ала. Затлы нәселгә игътибар бөтенләй бетә диярлек. Борынгы Греция һәм Рим тарихының соңгы чорларында да нәкъ шундый ук хәл була. П. Сорокин бары кайбер шөгыль һәм һөнәрләрнең генә байлык тупларга мөмкинлек бирүен билгели. Аның хисаплауларына караганда, баеп китү очракларының 29 процентын фабрика хуҗасы (ягъни житештерү өлкәсендә эшләү), 21 процентын банк һәм биржа хуҗасы, ә 12 процентын сәүдәгәр булып эшләү тәшкил иткән. Артист, рәссам, уйлап табучы, дәүләт эшлеклесе, шахтер һәм башка шундыйрак һөнәрләр байлыкка ирешү мөмкинлеге бирми.

П. Сорокин. «Сикергәк»ләр һәм монархлар

Җәмгыятьләр вертикаль хәрәкәтчәнлекнең җиңел баруы ягыннан бер-берсеннән аерылалар. Сыйнфый җәмгыятьтә катламнар арасындагы бүлентекләр гаять юка, аларда менү һәм төшү өчен «ярыклар» һәм «лифтлар» күбрәк. Касталы җәмгыятьтә — киресенчә. АКШта халыкның күпчелек өлеше аз дигәндә үз гомеренә бер тапкыр һөнәрен алыштыра. Һиндстанда исә эшләүче халыкның күпчелегенә һөнәри статус аталарыннан гомерлек мирас буларак кала.

1925 елгы күрсәткечләргә караганда, АКШның сәнәгать һәм финанс өлкәсендә өстенлек итүче байлары арасыннан 38 процентны узган буында, ә унтугыз проценты хәзерге буында үсеш баскычын ярлылыктан башлаган. Мультимиллиардерларның өчтән бере үз карьерасын башлаганда урта хәлле булган. АКШның 29 президентыннан ундүрте, яки 48 проценты, ярлы яисә урта хәлле гаиләдән чыккан.

Хәрәкәтчәнлектәге аерманы илләр буенча гына түгел, чорлар буенча да билгеләп була. Иң түбән социаль баскычтан күтәрелгән «сикергәк»ләрнең монархлар һәм иң югары дәрәҗәдәге администраторлар санынннан проценты түбәндәгечә: Көнбатыш Рим империясе — 45,6 %, Россия — 5,5 %, Көнчыгыш Рим империясе — 27,7 %, Франция — 3,9 %, Америка Кушма Штатлары — 48,3 %, Англия — 5,0 %, Франция һәм Германия президентлары — 23,1 %. Республиканың соңгы гасырыннан б.э. III гасырына кадәрге чорда Рим гаять хәрәкәтчән җәмгыять була. Вертикаль агымнар җәмгыять конусының иң түбән өлешеннән (коллардан) иң югары өлешенә кадәр (императорны да кертеп) күтәрелгән.

Акча, талау, көчләү, алдау, мәхәббәт интригалары, хәрби батырлык һәм хезмәте аша кеше, затлы нәселдән булмаса да, житәкче урыннарга кадәр күтәрелә алган. Бер-ике буын алышынган арада колларның аксөяккә әйләнү очраклары да булган. Цицерон чорында яшәгән иң бай кешеләр арасында без кайчак колларның һәм ирек бирелгән кешеләрнең исемнәрен дә очратабыз (Тримальхион, Палладий, Деметрий). Әмма империянең баштагы чорында ук вертикаль буенча иркен хәрәкәт итүгә шактый киртәләр барлыкка килә.

Европада, Россиядән гайре, түбән катламнардан монарх дәрәҗәсенә кадәр күтәрелүчеләрнең саны электә күбрәк булган. Рим католик папаларының бик ярлы сыйныфлардан чыгучылары 19,4 процентны, урта сыйныфлардан — 18,8 процентны, байлардан — 61,8 процентны тәшкил иткән.

Чыганак: *Сорокин П.* Человек. Цивилизация. Общество. М., 1991. 377–390 б.

Социаль статуслары төрле булган яшь кешеләр бергә тормыш корсалар, **гаилә** һәм **никахлашу** вертикаль әйләнеш каналына әверелгән. Европа җәмгыятендә ярлы, әмма титуллы партнерның

бай, әмма аксөяк нәселеннән булмаган партнер белән никахлашуы киң таралган була. Нәтиҗәдә һәр ике як, үзенә кирәкне алып, социаль баскыч буйлап югарырак күтәрелгән. Хәрәкәтчәнлекнең түбәнгә таба баруы Антик чор өчен хас булган. Рим законнары буенча колга кияүгә чыккан хатын-кыз, әйтик, үзе дә колга әйләнгән һәм ирекле граждан статусыннан мәхрүм ителгән. Гаилә социаль сайланышның, социаль статусны билгеләүнең һәм аның нәселдән нәселгә күчүенең төп механизмына әверелгән. Аксөякләр гаиләсендә туу гына үзеннән-үзе яхшы нәсел һәм лаеклы белем гарантияли алмаган. Ата-аналар балаларына яхшы тәрбия бирергә тырышканнар, бу исә аристократлар өчен мәҗбүри булган. Ярлы гаиләләрдә ата-аналар балаларына тиешле белем һәм тәрбия бирә алмаганнар. Идарәчелек элитасы шулай барлыкка килгән. Гаилә җәмгыять әгъзаларының катлауларга бүленеше институтларының берсенә әверелгән.

Төшенчәләр: *социаль хәрәкәтчәнлек, социаль статус, вертикаль хәрәкәтчәнлек, горизонталь хәрәкәтчәнлек, вертикаль хәрәкәтчәнлек каналлары.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Сезгә социологик анализ уздыру сәләтегезне тикшереп карарга туры килер. Тикшерену объекты итеп әти-әниегезне, бабай-әбиегезне, абый-апаларыгызны һәм, ниһаять, үзегезне алыгыз. Гаиләгездәге һәрбер кешенең мөмкин кадәр җентекле статус портретын сурәтләп бирегез.

2. Кайбер статуслар, башкаларының нинди булуына карамастан, иң мөһим буларак бәяләнәләр. Олимпия чемпионы, Нобель премиясе лауреаты кебек статуслар шундыйлардан. Тагын шундый 3–4 мисал китерегез.

3. Әти-әниләрегездән, өлкән туганнарыгыздан аларның социаль хәрәкәтчәнлеге турында сорашыгыз: кайсы елларда аның траекториясе (үсеше һәм түбәнгә тәгәрәве) ниндирәк булган, югарыга үрләр өчен алар нинди каналлардан файдаланганнар?

4. Социаль хәрәкәтчәнлекнең кайсы каналын сез үзегез өчен иң отышлысы дип саныйсыз? Җавабыгызны дәлилләгез.

***5.** Элек Россия империясендә булган һәм 1917 ел инкыйлабыннан соң юкка чыккан социаль (дини, һөнәри, демографик һ.б.)

статуслар исемлеген төзегез. Аларның юкка чыгу сәбәпләрен аңлатыгыз.

***6.** Югары хосусый хәрәкәтчәнлек җәмгыятьнең нинди үсеш дәрәҗәсен күрсәтүе турында уйлагыз. Ә югары төркем хәрәкәтчәнлеге?

***7.** Төрле чорларда Көлбикә турындагы экиятнең төрле вариантлары ни өчен популяр булуы турындагы фаразларыгызны әйтегез.

? Проблема. Әлеге сыйныфларның кайсысына — ярлы сыйныфкамы яисә бай сыйныфкамы — керү җиңелрәк, ә кайсысыннан чыгу җиңелрәк?

✍ Практикум 1. 1991 елда Америкада һәм Советлар Союзында өлкән сыйныф укучыларына бер үк сорауны бирәләр: «Сез әтиәниегездән яхшырак яшәсегезгә ышанасызмы?»

Җаваплар түбәндәгечә була:

	Америка балалары	Совет балалары
ӘЙЕ	79.7 %	78 %
ЮК	20,3 %	22 %

Бүген хәлләр ничегрәк? Өлкән сыйныфтагы танышларыгыз арасында сораштыру уздырыгыз. Нәтиҗәләрне язып алыгыз.

✍ Практикум 2. Мәшһүр рус тарихчыларыннан берәү «Дворяннар Мәскәве»нең «Сәүдәгәрләр Мәскәве»нә әверелүен түбәндәгечә сурәтли: «Капитал үсеш алган саен сәүдәгәрләрнең яңа буыны үсә барды. Болар мәдәниятле, чит ил гувернерлары кул астында тәрбияләнгәннәр, чит илләрдә белем алганнар, чит телләр беләләр һәм яшәү рәвешләре белән эре алпавытлардан бик аз аерылалар. Бу аерма бары тик алпавытларның мондый шартларда элек-электән тәрбияләнүендә, ә өстен сәүдәгәрләрнең мондый шартларны үз тирәсендә булдыруында гына иде».

«Совет Мәскәве»нең «Капиталистик Мәскәү»гә әверелүе ничегрәк бара?

§ 7 (§ 28). Гаилә һәм никах

Үз гомере дәвамында кеше бик күп төрле төркемнәргә кушыла, әмма шул төркемнәр арасыннан бары тик гаиләдән генә ул беркайчан да аерылмый. Гаилә, балалар — шәхес үсешенең иң әһәмиятле өлешләре. Вертикаль хәрәкәтчәнлек каналы буларак, ул балаларның социаль хәлен һәм статусын билгели. Хәзерге җәмгыятьтә ул берничә функция башкара. Җәмгыятькә тотрыклылык һәм һәр киләсе буында халык санын киметмәү сәләтен бирүче фундаменталь институтларның берсе, шуның белән бер үк вакытта җәмгыятьнең иң кече, иң бердәм һәм иң нык ячейкасы булып тора.

> **ГАИЛӘ** — никахка һәм кан буенча туганлыкка нигезләнгән кечкенә төркем. Аның әгъзалары уртак көнкүреш, үзара ярдәмләшү, әхлакый һәм хокукый җаваплылык белән бәйләнгән була.

Озак вакыт яшәүче гаилә һәр буын саен, дәвамчанлыкны бозмыйча, бүленә һәм тернәкләнә бара.

Никахка кадәр кешеләрнең үз-үзләрен тотышы. Яшь кешеләр (кайчак мәктәптә укыганда ук) танышалар һәм гашыйк булалар, дуслашып йөриләр, бер-берсен яхшырак белергә омтылалар. Безнең заманда гаилә гадәттә 20–25 яшьләрдә (сирәк кенә мәктәпне тәмамлагач ук) корылганга, егет-кызларга бер-берсен белер өчен вакыт җитәрлек була. Мәктәпне бетергәч тә өйләнешкән гаиләләрдә соңрак яшь ир яисә хатын кайчак башкаларга игътибар итә башлый. Бу әхлакый бозыклык нәтиҗәсе түгел, моңа әлеге парның егетлек яисә кызлык чоры кыска булу сәбәпче. Аларга башка җенес вәкилләре белән аралашырга вакыт җитмәгән.

Кайчак беренче күрүдән гашыйк булып өйләнәләр (кияүгә чыгалар). Дөрес, мондый очраклар бик сирәк. Алар җентекле исәпкә алынмасалар да, мондый мәхәббәткә нигезләнеп корылган никахлар гомуми никахлар санының 1–3 процентын гына тәшкил итәләр дип санарга мөмкин. Кеше беренче караштан гашыйк булу белән беррәттән, гомерлеккә дә яратса — менә иң яхшы вариант шушы була.

Гаилә — парлы кешеләр бергәләп бара торган юлның башы түгел, ә уртасы ул.



Егет һәм кызның яисә ир һәм хатынның танышуы түбәндәге юллар белән бара:

- арадашчыларсыз, мөстәкыйль рәвештә;
- формаль арадашчы аша (никах агентлыклары, танышлык клублары, газет-журналлардагы белдерүләр);
- формаль булмаган арадашчылар аша (ата-аналар, танышлар, дуслар, яучылар).

Егет белән кызның никахка кадәр үз-үзләрен тотышында **беренче тапкыр күрешү** гаять мөһим.

Өлкән сыйныф укучыларыннан һәм студентлардан сораштырулар егетләрнең дә, кызларның да беренче күрешүне нигездә бертөрлерәк күзаллавын күрсәтте. Егет кызга күрешергә тәкъдим ясый, ә кыз, әлеге тәкъдимне ныклап уйлап, иптәш кызы белән киңәшеп, ризалыгын бирә. Ризалык алынгач, егет кайда һәм ничек очрашу турында уйлый башлый: урамда гына йөрергәме, кафега, киного, концертка яисә дискотекага барыргамы һ.б. Шушыннан соң егет тә кыз да булачак очрашу турында ата-аналарына хәбәр итәләр. Аларның киемсалым сайлап, күрешү урынын, программасын тәгаенләп күп вакыты уза. Чыгар алдыннан кыз тышкы кыяфәтен кат-кат карый һәм, бераз соңга калырга тырышып, күрешү урынына юнәлә. Юлда икесе дә ни турындарак сөйләшергә мөмкин икәнен уйлап баралар. Егет чәчәк бәйләме, тартмалы конфет сатып ала. Күрешеп исәнләшкәннән соң ул кызга бер-берсенә «син» дип эндәшергә тәкъдим ясый. Кыз ри-

залаша. Бергәләп бүгенге кичне кая уздыру турында киңәшәләр. Кич буе егет кызны һәрвакыт игътибар үзәгендә тота (транспорттан чыкканда кул бирә, аны ишек ачып машинага утырта, һәрчак алга уздыра, утырганда урындыгын артка алып тора, биергә чакыра, өс киемен киертә һ.б., яхшы тәэсир калдырырга тели). Ә кыз исә мөмкин булган кадәр назакатьлерәк булырга тырыша. Кызны өенә озатканда егет аңа хәерле кич тели, киләсе очрашуны түземсезлек белән көтәчәге турында әйтә.

Беренче күрешүдән соң никахка кадәрге мөнәсәбәтләрнең романтиклык чоры — **йөрү** башлана. Егет сөйгәненә игътибарлы була, үзен яраттырыр өчен шактый көч сарыф итә.

Йөрү чорын сынау чоры белән чагыштырырга мөмкин. Бу вакытта барысы да күз уңында була: хуҗалык эшләренә егет яисә кызның кулы ятамы, акчаны әрәм-шәрәм итмиме, шулай да артыгын кысмыр түгелме, гамәли һәм теоретик фәннәр өлкәсендә белеме ни дәрәҗәдә, үз-үзен тотышы ничек? Бу чорда яшьләр бер-берсен өйрәнү белән бергә, тәрбиялиләр дә. Гадәттә бу чорны «яраклашу» чоры дип атыйлар: яшьләр бер-берсенә юл куярга, хисләрен йөгәнләргә, сүзгә килсәләр, татулашырга, бер-берсенә илтифат күрсәтергә өйрәнәләр.

Киләсе адым — **яучылау**. Йола буенча булачак кияү кызның ата-анасыннан никахка ризалыкларын сорый. Бу эшне ул я үзе башкарып чыга, я яучылар җибәрә (кияүнең ата-анасы, туганнары). Билгеләнгән көнне кияү йола буенча кызның өенә килә. Бу очракта гадәттә егет ике чәчәк бәйләме хәстәрли: берсе — булачак кәләшнең әнисенә, икенчесе — кызның үзенә бүләк ителә. Русларда, мәсәлән, кияү кәләшнең ата-аналарына хисләрен ачып сала һәм кызның «кулын сорый». Әгәр алар риза булсалар, кәләшнең әтисе кызының уң кулын кияүнең учына сала. Яучылаганнан соң яшьләр ярәшүләрен игълан итү турында килешәләр һәм аның вакытын билгелиләр.

Ярәшү — никахлашачак яшьләрне кияү белән кәләш дип игълан итү йоласы. Хәзерге вакытта ул гадәттә никахны теркәтү өчен загска гариза биргән көнне игълан ителә. Элегрәк ярәшү вакытында ата-аналар балалары никахына ризалыклары турында ахыргы тапкыр белдергәннәр һәм аның шартлары турында килешкәннәр. Ярәшкәннән соң өйләнешүдән баш тартырга ярамаган. Әгәр шундый хәл була калса, ярәшүне бозган як «зыянны капларга» — «хурлык өчен түләргә» тиеш була.

НИКАХЛАШКАНЧЫ ЯШЬЛӘРНЕҢ ҮЗ-ҮЗЛӘРЕН ТОТЫШЫ ЭТАПЛАРЫ

Вакыт элегрәк кабул ителгән нормаларга төзәтмәләр кертә. Яучылау һәм ярәшү йоласына, ата-ана ризалыгына хәзер артык әһәмият бирелмәскә дә мөмкин. Ата-аналарга никахлашкач кына бу турыда хәбәр итү очраклары да бар.

Никах — ир белән хатынның бер-берсенә, балаларына, туганнарына һәм тулаем җәмгыятькә карата хокукларын һәм бурычларын билгеләүче рәсми күрсәтмәләр җыелмасы ул. Башкача әйтсәк, никах — контракт ул. Аны төзүдә өч як — ир, хатын һәм дәүләт катнаша. Анда бары бер дата — никах килешүе төзелгән көн генә күрсәтелә, ә контракт гамәленең тәмамлану вакыты куелмый. Шул рәвешчә, никахның вакыты гомерлек дип карала.

Никахлы ата-ана дөньяга китергән балалар законлы тудырылган дип санала. Чөнки җәмгыятьтә гаиләнең һәр ике әгъзасына ана һәм ата рольләре бирелгән, үз балаларын тәрбияләү, аларны яклау һәм алар турында кайгырту бурычы йөкләнгән. Никах махсус церемонияләр, йолалар һәм гадәтләрдән тора: ярәшү, балдаклар кидертү, кияү һәм кәләшнең символик киртә аша атлап чыгуы, «баллы ай». Моннан тыш, никах инде традициягә әверелгән кайбер кагыйдәләрне күздә тота: әйтик, тугрылык, бер-береңә гомерлек терәк булу. Ниһаять, никах аңа кагылышлы законнарга нык бәйләнгән: никахны теркәү, житди сәбәпләр булганда, аерылышу хокукына ия булу, алдау ачыкланса, никахны фиктив дип тану хокукы, никахлашучыларның кан-кардәшләр булмавы.

Шулай итеп, *никах — ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салу институты булса, гаилә инсти-*

туты, моннан тыш, әле балалар һәм ата-аналар арасындагы мөнәсәбәтләрне дә җайга сала. Балалар туганнан соң ир белән хатынның бергәлеге тулы мәгънәсендә гаиләгә әверелә, биредә яңа социаль рольләр (ата-ана роле) һәм яңа мөнәсәбәтләр (буыннар арасында, тәрбияви, хуҗалык һ.б.) барлыкка килә.

Яңа җәмгыятьтә закон нигезендә рәсмиләштерелмәгән, бары мәхәббәткә һәм татулыкка гына нигезләнгән граждан никахы (аны концессуаль никах дип тә атыйлар, латинча consensus — татулык, бердәмлек сүзеннән) таралыш ала.

Хәзерге гаилә гадәттә ата-анадан һәм балалардан тора. Аны **нуклеар** гаилә (латинча nucleus — төш) дип атыйлар, чөнки буыннар дәвамчанлыгы өчен җаваплы гаиләнең нигезен ата-ана һәм аларның балалары тәшкил итә. Алар теләсә кайсы гаиләнең биологик, социаль һәм икътисади үзәген тәшкил итәләр. Башка барлык туганнар — әби, бабай, ана-атаның абыйлары, апалары һ.б. — гаиләнең перифериясе була. Әгәр алар барысы да бергә яшәсәләр, бу **киңәйгән** гаилә дип атала. Киңәйгән гаилә мәгънәсен конкретлаштырганда «күпбуынлы» сүзе кулланыла. Ул гаиләнең нуклеар гаиләгә агалар, туталар, тудыкалар (кузен, кузина) кушылу аркасында түгел, бәлки 3–4 буын кан-кардәшләр хисабына киңәюен аныклый.

Гаилә киң туганлык системасының бер буынын гына тәшкил итә. ***Туганлык*** — ата-бабаларның гомумилеге, уллыкка алу яисә никах җепләре белән бәйләнгән кешеләр берлеге. Ир белән хатын никахлашканда ике тугандаш ыруг — ирнең туганнары һәм хатынның туганнары — бергә кушыла. Хатын өчен үз туганнары кан-кардәш булса, иренең туганнары закон нигезендә кардәш була. Һәм киресенчә. Закон нигезендәге туганлык никахлашканнан соң барлыкка килгән кардәшләргә мөнәсәбәтле була. ***Туганлыкның өч баскычын билгелиләр: иң якын, туганнан туган һәм өч туган кардәшләр.*** Бергә алар «нәсел шәҗәрәсен» тәшкил итәләр, теоретик яктан караганда аның 200 гә якын тармагы булырга мөмкин. Әйтик, бертуганның улы яисә кызы, килен — болар тармаклар. Һәр тармакта берничә кеше булырга мөмкин. Кардәшлек тармаклары системасы *туганлык структурасын* тәшкил итә.

Нуклеар гаилә билгеле бер эволюция кичерә. Традицион җәмгыятьтә аңа *бер карьералы* модель хас. Бу атаның иҗтимагый



Никах, гаилә, туганлык

җитештерү өлкәсендә эшләп, акча табуын һәм гаиләне матди тәэмин итүен, ә ананың йорт хуҗалыгы белән шөгыльләнүен, өйне тәртиптә тотуын, балаларның укуын һәм тәртибен күзәтеп торуын аңлата. Хәзерге җәмгыятьтә нуклеар гаилә өчен *ике карьералы* модель хас. Аның буенча ата да, ана да эшлиләр, һәм йорт эшләрен бергәләп башкаралар. Мондый гаиләләрне ***ике керемле*** һәм ***ике туендыручылы*** гаилә дип тә атыйлар.

Җитештерү өлкәсендә эшләү хатын-кызны йорт эшләреннән азат итми. Аңа икеләтә авырлык төшә. Бу авырлыкны ир (балалар үскәч, кайбер йорт эшләре аларга да йөкләнергә мөмкин) җиңеләйтә ала. Менә ни өчен галимнәр хуҗалык эшләрен тигез бүлү — хатынның йорттан тыш эшләве өчен гадел түләү дип әйтәләр.

Төшенчәләр: *гаилә, никах, нуклеар гаилә, киңәйгән гаилә.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Әлеге ике төшенчә ни белән аерыла: социаль институт буларак гаилә һәм кече төркем буларак гаилә?

2. Яшьләрнең никахлашканчыга кадәрге үз-үзен тотышы этапларын тасвирлагыз.

3. Сезнең гаиләгездә ата-аналарның һәм балаларның бурычлары ничегрәк бүленгән?

***4.** Гаиләдәге рольләр структурасында лидер — гаилә башлыгы аерым урын тота. Бу рольдә хатын да, ир дә була ала. Сезнең гаиләгездә кем лидер — әтиегезме, әллә әниегезме? Проблеманы анализлагыз.

***5.** Никахлашып тору һәм бергә яшәү — икесе бер үк нәрсә түгел. Ни өчен? Граждан никахы нәрсә ул?

***6.** Ир һәм хатынның үз бурычларын үтәве түбәндәге рәвешләрдә булырга мөмкин:

а) Ир һәм хатын бары үз бурычларын гына үтиләр.

б) Ир үз бурычларын үтәми, ә хатын үти.

в) Ир үз бурычларын үти, ә хатын — юк.

г) Ир хатын бурычларын, хатын ир бурычларын үти. Әлеге очракларның һәрберсенең нәтиҗәсе нинди булачак — ызгыш, аерылышу, конфликт, гармония? Вазгыятьне анализлагыз.

? Проблема. Нык һәм бәхетле гаилә кору өчен иң беренче нәүбәттә ни кирәк?

✍ **Практикум 1.** Гаилә яисә нәсел шәҗәрәсе бер кешенең ким дигәндә ике пар бабасына һәм әбисенә барып тоташа торган һәм ике парның түбәнгә юнәлешле бәйләнеш буенча туганнарын, шулай ук аларның җәмәгатьләрен үз эченә алган барлык туганнары төркемен сурәтли. Үз нәсел шәҗәрәгезнең түбәнгә, югарыга һәм ян-якка бәйләнешләрен сурәтләп бирегез. Бу бәйләнешләргә билгеләмә бирегез.

✍ **Практикум 2.** Ике кеше сөйләшә.

Беренчесе:

«Күпчелек алга киткән җәмгыятьләрдә аерылышулар саны 30 процент тирәсе була. Һәм бу Россия өчен генә хас нәрсә түгел. Элегрәк барлык илләрдә дә гаиләләр ныграк иде. Кешелек никах кризисы чорына аяк басмадымы икән? Якын киләчәктә аңа нәтиҗәлерәк алмаш табылырга да мөмкиндер бәлки», — дигән фикер әйтә.

Икенчесе түбәндәгечә җавап бирә:

«Никах һәм бизнес — гаять зур тәвәккәллек таләп итүче эшләр ул.

Яңа төзелгән 100 предприятиенең ел саен 80–90 проценты таркала. 100 яшь гаиләнең ел саен 30 проценттан кимрәге аерылыша. Бизнестагы югалтулар дәрәҗәсе 3 тапкыр артык булуга карамастан, берәү дә бу институт кризисы турында сүз алып бармый. Әлеге ике институтны чагыштырып карасак, никахның нигезе бизнесныкына караганда ныклырак булуын һәм аның бернинди дә кризис кичермәвен әйтү дөрес булыр».

Әлеге фикерләрне чагыштырыгыз. Сез аларның кайсысы белән килешәсез? Үзегезнең җавабыгызны дәлилләгез. Әгәр мөмкин булса, статистикага һәм фактларга таянып эш итегез.

✍ **Практикум 3.** Кече төркемнәр өчен бирем: бөтен яктан килгән (идеаль) гаилә моделен төзеп күрсәтегез (эш, бурычларның бүленеше, ял, балалар тәрбияләү).

3 (9) бүлек

Кешеләрнең җәмгыятьтәге бәйләнеше

§ 8 (§ 29). Социаль үзара мөнәсәбәт

Көндәлек тормышта үзебез сизмичә дә без социаль үзара мөнәсәбәтнең гаять гади гамәлләрен башкарабыз. Очрашкач, кул кысышабыз, бер-беребезне сәламлибез, автобуска кергәндә хатын-кызны, балаларны һәм өлкәннәрне алга уздырабыз. Болар барысы да — *социаль үзара мөнәсәбәт* яки *социаль тәртип элементлары.*

Әмма безнең һәр башкарганыбыз социаль үзара мөнәсәбәткә керми. Әгәр автомобиль кешене бәрдерсә, бу — гап-гади юл һәлакәте була. Әмма машина йөртүче һәм җәяүле, *ике зур социаль төркем вәкилләре* буларак, һәркайсы үзен хаклы дип санап, үз мәнфәгатьләрен яклый икән, бу хәл инде социаль үзара мөнәсәбәткә әверелә.

Машина йөртүче, юлларның автомобильләр өчен салынган булуын һәм җәяүленең кая-теләсә, шул урында юл аркылы чыгарга хокукы булмавын тәкърарлый. Җәяүле исә шәһәрнең машиналар өчен түгел, кешеләр өчен төзелгәнлегенә ышанган. Бу очракта машина йөртүче белән җәяүле үзләренең социаль статусларын билгелиләр. Аларның һәрберсе үзенең *хокуклары һәм бурычлары җыелмасына* ия була. Машина йөртүче һәм җәяүле ролен үтәгәндә, ике кеше симпатиягә яисә антипатиягә нигезләнгән шәхси мөнәсәбәтләрен ачыкламыйлар, алар социаль үзара *мөнәсәбәтләргә* керәләр, үз-үзләрен җәмгыятьтә билгеләнгән социаль статуска ия шәхесләр буларак тоталар.

Аларның әңгәмәсе *эчтәлеген социаль символлар* һәм *төшенчәләр* тәшкил итә: шәһәр юлларының билгеләнеше, машиналар йөри торган юллар аркылы чыгу кагыйдәләре, кеше яки автомобиль өстенлеге

һ.б. (Курсив белән бирелгән төшенчәләр социаль бәйләнеш атрибутлары булып тора.) Социаль эш-хәрәкәт кебек үк, социаль үзара мөнәсәбәт тә һәркайда очрый.

Димәк, социаль үзара мөнәсәбәтне социаль эш-хәрәкәтләр дип аталган аерым актлар тәшкил итә һәм аңа статуслар (хокуклар һәм бурычлар җыелмасы), рольләр, социаль мөнәсәбәтләр, символлар һәм төшенчәләр керә.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ ТӘРТИБЕ — шәхеснең башка кешеләр күз алдында кылына торган эш-хәрәкәтләре җыелмасы. Ул хосусый һәм күмәк булырга мөмкин.

Шәрехләү өчен мисал

1994 елның 12 сентябрендә Киров өлкәсендәге ипи кибетләре янында бик озын чиратлар тезелә: кешеләр күпләп икмәк-күмәч әйберләре һәм он ала. Сәбәбе: өлкәне икмәк белән тәэмин итү бурычы йөкләнгән акционерлык җәмгыяте, өлкә бюджетыннан акча күчерелмәвен сылтау итеп, киләсе елга контракт төземәгән. Җирле матбугатта АҖ эшендәге җитешсезлекләр тәнкыйтьләнгән мәкаләләр дөнья күрә, шулай итеп, килеп чыгачак дефицит турында халыкка мәгълүм була. Гомуми дефицит заманынының ачы тәҗрибәсендә тәрбияләнгән кешеләргә шул җитә кала.

Югарыда тасвир ителгән очрак кешеләр төркеменең үз-үзен тотышына мисал булып тора. Аны гаять мөһим тормыш ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен кирәкле азык-төлек белән тәэмин ителүдә кыенлыклар туу мөмкинлегенә карата реакция рәвешендәге кешенең ***социаль үз-үзен тотышы*** дип атарга да була. Моннан чыгып, **ихтыяҗ, мотивлаштыру, көтелгәннәр** — кешеләрнең җәмгыятьтә үз-үзен тотышының төп элементлары дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Кешенең эшчәнлеген һәм үз-үзен тотышын чагыштырсак, алар арасындагы аерманы күрү бик җиңел. ***Эшчәнлек анык максатларга һәм планлы эш-гамәлләргә корыла. Ул тышкы кызыксындыру булып торучы билгеле бер түләү, әйтик, эш хакы, гонорар, югарырак вазыйфага билгеләнү хакына башкарыла.***

Кешенең үз-үзен тотышының төп, билгеләүче элемент буларак максаты булмый. Гадәттә бу очракта бернинди дә максат күздә тотылмый. Шулай да кешенең үз-үзен тотышында ниятләр, көтелгәннәр, ихтыяҗ һәм мотивлар бар. Эчке этәргеч булып торучы стимуллардан аермалы буларак, *мотивлар тышкы этәргечләргә* керә.

Үз-үзеңне тоту берәмлеге — **гамәл (поступок).** Ул аңлы рәвештә кылына дип саналса да, гамәл максатлы һәм ниятле булмый. Намуслы кешенең гамәле табигый, шуңа да ул үлчәп, фикерләп эшләнми. Мондый кеше башкача гамәл кыла алмый — бары шул гына. Ул башкаларга үз намуслылыгын күрсәтим дип эш итми. Шушы күзлектән караганда, гамәлнең максаты да юк дигән сүз. Гамәл, гадәттә, берьюлы ике нәрсәне максат итеп куя: беренчесе — үз мораль принципларыңнан тайпылмау; икенчесе — гамәлгә бәя бирүче кешеләрдә уңай караш булдыру. Кемнең дә булса, үз гомерен куркыныч астына куеп, суга батучы кешене коткаруы — әлеге ике максатны да күздә тота. Үз карашын яклап, гомуми фикергә каршы чыгуы — беренчесен генә күздә тотып башкарыла.

Бер-берсе белән яхшы таныш булган һәм өзлексез элемтәдәге кешеләрдән торган коллективта яисә кечкенә төркемнәрдә кешенең үз-үзен тотышы таныш булмаган төркемдәге үз-үзен тотышыннан бик күпкә аерыла. Аерымлык түбәндәге кагыйдәне үтәүгә нигезләнә: үзеңә нинди мөнәсәбәттә булуларын теләсәң, син дә кешеләргә карата шундый мөнәсәбәттә бул. Урамда узып барышлый гына очраган таныш түгел кеше белән мөнәсәбәттә бик үк илтифат сакламасаң да була, әмма хезмәттәшеңә карата болай эшләп булмый. Танышлары арасында кешеләр үзләрен яхшы яктан күрсәтергә телиләр. Күпчелек очракта кешеләр алар турында шәфкатьле, зыялы, игътибарлы, илтифатлы дигән фикер тусын өчен тырышалар һәм үзләре дә башкалардан шуны ук таләп итәләр. Әгәр дә үзләре шундый булмасалар, алар башкалардан шуны ук таләп итә алмасларын яхшы беләләр.

Эш-хәрәкәт, гамәлләр — кешенең үз-үзен тотышы һәм эшчәнлеге шулардан оеша. ***Кешенең эшчәнлеге һәм үз-үзен тотышы — шәхес активлыгының ике ягы.***

Кешенең эшчәнлекле ирекле булганда гына гамәл кылу мөмкинлеге була. Әгәр ата-анагыз сезне аларга бөтен серләрегезне сөйләргә мәҗбүр итәләр һәм сез хәтта үзегез өчен иң күңелсез вакыйгалар



турында да аларга сөйлисез икән, бу әле гамәл булмый. ***Кешенең ирекле башкарган эшләре генә гамәл була.***

Сайлау иреге кешегә һәр адым саен, хәтта кибеткә барганда, бер чокыр чәй эчкәндә дә кирәк. Аңа кеше эшчәнлегенең иң югары даирәләрендә, аеруча иҗатта ихтыяҗ зур. Әгәр рәссам, актер, галим кемнеңдер күрсәтүе буенча иҗат итә икән, ул бернинди дә шедевр тудыра алмаячак. Бөтендөнья тарихын кешелекнең сәнәгый югары үсешле җәмгыятькә таба хәрәкәте буларак караганда, без хәзерге чорда фәнни белемнәрнең, мәгълүмат һәм акыл хезмәтенең, шулай ук ял һәм иҗатның роле үсүе турында сүз алып бардык. Галимнәр постиндустриаль җәмгыятькә алмашка эштән бушану җәмгыяте килә дип саныйлар һәм бик мөһим бер детальгә игътибар юнәлтәләр: гамәл кылу иреге хәзерге чорда элеккегә караганда чагыштыргысыз зур булырга тиеш.

Әгәр статистиканы җентекләп анализласак, хәзерге җәмгыятьтә акыл хезмәтенең артуын һәм кешеләрнең гомере озаюын күрербез. Әлеге ике күренешнең бәйләнеше очраклы микән? Түбәндәге өзектә шул турыда сөйләнә.

Е. Шапошникова, В. Шапошников
Иҗат һәм озын гомерлелек

Авторлар энциклопедик сүзлекләрдән, шулай ук каберлекләрдән 3300 кеше (сәнгать кешеләре, галимнәр, сәясәтчеләр, дин әһелләре) турындагы ике мең

мәгълүматны анализлаганнар. Мәрхүмнәр санының аларның яшенә бәйлелеге графигы төзелгән. Кешенең балигълык чорында үсеше җиде, сирәгрәк сигез еллык периодлы эчке биологик ритмга буйсындырылган булуы ачыклана. Шушындый циклларның һәрберсендә иҗади үсеш яшәү тонусының кимүе белән алышына. Кешеләр гадәттә сәламәтлекләре какшаган чорда үләләр. Бу еллар түбәндәгеләр: 1, 7, 14, 21, 28, 35, 42, 49, 56, 63, 70, 77, 84, 91. Сәламәтлек какшау халәте уртача бер ел дәвам итә, кеше картая барган саен, бу чор озая. Яшәү егәре 25–30 яшьләрдә аеруча югары була. Иҗади хезмәт белән шөгыльләнүчеләрнең тормышында циклларга бүленеш бигрәк тә ачык чагыла. Шагыйрьләр, гадәттә, бер үк вакытта — 36 — 37 яисә 42-43 яшьләрендә вафат булалар.

Чыганак: Знание — сила. 1990. № 3. 56 бит.

Гамәл дигәндә, без үзебез дә сизмәстән, башка кешеләр күрсен дип кылынган эш-хәрәкәтне күздә тотабыз. Шәхес тарафыннан башка кешеләр игътибар итсен, дип яки андый максат куймыйча гына гамәл кылынырга мөмкин. Башка кешеләргә атап башкарылган, җавап реакциясе тудырган гамәл *социаль үзара мөнәсәбәт* дип атала.

ҮЗАРА МӨНӘСӘБӘТ — ике яисә берничә затның берберсенә кагылышлы эш-хәрәкәт кылуы.

Фәндә үзара мөнәсәбәтнең *берләшү (кооперация), көндәшлек (конкурентлык) һәм низаг (конфликт)* дигән *өч төп формасы* бар дип кабул ителгән. Әлеге очракта үзара мөнәсәбәт партнерларга, дефицит (сирәк) ресурсларны тигез бүлешеп, үз максатларын һәм аларга ирешү чараларын килештерүгә ярдәм итә торган ысул булып тора.

БЕРЛӘШҮ — берничә шәхеснең (төркемнәрнең) уртак бурычны хәл итүдәге хезмәттәшлеге.

Авыр бүрәнәне күтәреп күчерү берләшүгә иң гади мисал була ала. Ул берләштерелгән көчнең аерым шәхес көченнән өстенлеге аерым-ачык аңлашылганда кулланыла. Берләшү хезмәт бүленешен күздә тота.

КӨНДӘШЛЕК — шәхеснең яисә төркемнең дефицит кыйммәтләр (уңайлыклар) өчен көрәшүе.

Болар акча, милек, абруй, популярлык, хакимият булырга мөмкин. Чикле булулары сәбәпле, һәммә кешегә тигез бүлеп бирелә алмаганлыктан, алар дефицитка әвереләләр. Аерым затлар катнашканга күрә түгел, бәлки тартышучы якларның (төркемнәрнең, партияләрнең) үзләренә өстенлекне башкалар хисабына мөмкин булганча күбрәк яулап алырга тырышуы аркасында көндәшлек шәхси көрәш рәвеше дип таныла. Шәхесләр аерым-аерым зуррак уңышларга ирешә алачакларын аңласалар, көндәшлек көчәеп кенә китә. Уен кагыйдәләре кешеләр тарафыннан билгеләгәнлектән, көндәшлек социаль үзара мөнәсәбәт буларак таныла.

Низаг берләшүдә дә, көндәшлектә дә туарга мөмкин. Дефицит кыйммәтләр өчен көрәшкән вакытта көндәшләр бер-берсенә комачаулык итәргә яисә бер-берсеннән бөтенләй котылырга омтылганда, ярышу бәрелешкә әверелә. Көчләре бертигез булган яклар, әйтик, сәнәгый үсешле илләр, хакимлек, абруй, сату-алу базарлары, ресурслар өчен тыныч юллар белән көрәшәләр икән, бу көндәшлек була. Ә тыныч юл белән булмаганда, кораллы низаг — сугыш килеп чыга.

Инде әйтеп үтелгәнчә, социаль үзара мөнәсәбәт күпләгән аерым социаль (массакүләм) гамәлләрдән тора. Алар начар оештырылган (коткы) яисә җитәрлек әзерлекле (демонстрацияләр, революцияләр, сугышлар) булырга мөмкинләр. Күп кенә нәрсә вазгыятьнең дөрес аңлану-аңланмавына, үз артларыннан башкаларны ияртергә сәләтле оештыручылар һәм башлап йөрүчеләр булу-булмауга бәйләнгән.

Социаль үзара мөнәсәбәтнең коткы кебек төрендә оештыручылар һәм алдан төзелгән план булмый.

КОТКЫ (паника) — кешеләрнең куркыныч белән йөзгә-йөз очрашканда үзара килешенмәгән гамәлләр кылуында чагылыш тапкан гомум үз-үзләрен тотышы.

Коткыга бирелгән кешеләр еш кына бер-берсенә комачау итәләр, җәрәхәтләр ясыйлар. Коткы корабның һәлакәте, янгын, җир тетрәү, су басу, сугыш хәрәкәтләре башлану кебек экстремаль шартларда барлыкка килә. Шәхес, аңа мәгълүм һәм үзенең кулыннан килә торган, гадәти

Элегрәк галимнәр теләсә нинди низагны үтә тискәре күренеш, юлында очраган һәр нәрсәне җимерә торган деструктив фактор буларак бәялиләр иде.

Бүген исә бүтәнрәк караш өстенлек итә: низаг – нормаль күренеш, алай гына да түгел, ул әле еш кына каршы якларның фикер-карашларын ачыкларга, психологик киеренкелекне йомшартырга ярдәм итеп, конструктив роль дә башкара.

шартларда үтемле чараларның бу очракта яраксыз булуын күреп, чыгарыннан чыга. Фикерләү сәләтен һәм ихтыяр көчен тышаулаучы курку хисе хасил була. Тирә-юньдәгеләрнең дә шундый ук халәт кичерүен күргәч, кешенең куркуы тагын да арта. Бер коткылы гамәл — икенчесен, икенчесе өченчесен китереп чыгара һәм шулай дәвам итә. Коткы халык күп җыелган җирдә барлыкка килә. Менә бер мисал.

1999 елның 30 маенда Минск шәһәрендә сыра бәйрәменнән соң көчле җил күтәрелә, яңгыр ява башлый. Сыра эчүдән каны кайнарланган меңләгән яшь кеше метрога керү урынына килеп тыгыла. Котычкыч кысрыклык барлыкка килә. 50 дән артык кеше, күпчелектә 14 тән алып 18 яшькәчә кызлар һәм халык ташкынын туктатырга омтылып караган өч милиция хезмәткәре һәлак була. 10 минуттан барысы да тәмамлана, ә ил шуннан соң өч көн буена матәм тота. Фаҗиганең шаһитлары сырадан каннары кайнаган меңләгән яшь кешенең берни дә аңламый торган «көтүгә» әйләнүе турында сөйлиләр. Төркемгә килеп эләккәч, зыялы гына кешеләр үзләре дә аңламастан ни өчен үтерүчеләргә әйләнәләр?

Төшенчәләр: *кешенең үз-үзен тотышы, гамәл, үзара мөнәсәбәт, берләшү, көндәшлек, коткы.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Сез кешеләрнең социаль эш-хәрәкәте һәм үзара мөнәсәбәте турында ниләр белдегез? Эш-хәрәкәт һәм гамәл ни белән аерыла? Үз биографиягездән сездә а) горурлык, б) оят хисе уята торган берәр гамәлне исегезгә төшерегез.

2. Үзара мөнәсәбәтнең нинди өч формасы белән таныштыгыз?

3. Сезгә стихия шартларында күмәк гамәлләргә, мәсәлән коткыга тарырга туры килгәне юкмы? Аларның барышы һәм табигате турында сөйләгез.

***4.** Низагны көндәшлекнең аерым бер рәвеше дип карап буламы? Аларның охшашлыгы һәм аерымлыгы нидә?

***5.** Гамәл ни өчен хәрәкәт итү ирекле булганда гына кылына ала? Концлагерьлардагы сәяси тоткыннар гамәл кылмаганнар мени? Җавабыгызны дәлилләгез.

***6.** «Үзеңә нинди мөнәсәбәттә булуларын теләсәң, син дә кешеләргә карата шундый мөнәсәбәттә бул!» — дигән гыйбарәне сез ничек аңлыйсыз?

? Проблема. Яшьләрнең иҗтимагый үз-үзләрен тотуларына хас сыйфатларны атый аласызмы? Әгәр алсагыз, аларның ни белән бәйле икәнен ачып бирегез.

✍ Практикум. Сез ничек уйлыйсыз, түбәндәге гамәлләрне социаль үзара мөнәсәбәткә кертеп буламы яисә юкмы?

Бер кеше икенчесеннән тәмәке кабызырга сорый.

Бер кеше икенчесеннән вакыт сорый.

Яңгыр ява башлагач, бар кеше дә зонтларын ача.

Машина узып киткәндә җәяүлеләрне пычрак белән коендырды.

Алган әйберләрегез өчен сез сатучыга акча түләдегез.

§ 9 (§ 30). Низаг һәм каршылык хәрәкәте

«Каршылык хәрәкәте» термины илебез фәнендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында 1990 елларның икенче яртысында актив кулланыла башлады. Ул тискәре процессларны — социаль киеренкелекнең көчәюен, халыкның иҗтимагый тормыш шартлары начараюын, үз хәленнән ризасызлыгын — чагылдырып кына калмый, бәлки кешеләрнең сәяси активлыгы арту һәм актив гражданлык позициясе формалашу кебек уңай күренешләрне дә гәүдәләндерә.

Күп еллар дәвамында андый хәлләр булмаган (булса да, алар турында ачыктан-ачык сөйләнмәгән) безнең илебездә каршылык хәрәкәтенең кинәт көчәеп китүе яшь демократиянең аерылгысыз юлдашы булды һәм аның килеп чыгасы турында галимнәр алдан ук хәбәр иткәннәр иде инде.

Социаль киеренкелек һәм иҗтимагый төркемнәр арасындагы низаг — каршылык хәрәкәтенең ике чыганагы.

Социаль киеренкелек дигәндә, халыкның яшерен агрессия һәм ниятләрен ачыктан-ачык белдерергә әзерлеге рәвешендә чагылыш табучы үз хәленнән үтә ризасызлыгын аңларга кирәк. Социаль киеренкелекнең нигезен социаль канәгатьсезлек, кешеләрнең үз мәнфәгатьләре, социаль уңайлыклары һәм өстенлекләре чикләнү тойгысы ята. Шул ук вакытта якларның берсендә үз көченә артык ышану феномены барлыкка килә. Ул үзен күбрәккә сәләтле һәм ия булганыннан артыгракка хаклы дип саный. Мондый халәтнең *юлдашы — фрустрация* (лат. frustratio— алдау, уңышсызлык) хисе низагны китереп чыгаручы төп көч булып тора. Социаль низаг турында сез 8–9 сыйныфлар өчен җәмгыять белеме курсыннан беләсез инде. Кыскача гына төп нигезләмәләрне искә төшереп китик һәм проблеманы төрле яклап тикшерик.

> **НИЗАГ** — көндәш ике якның (кешеләр яисә социаль төркемнәр) һәр икесе өчен дә зур кыйммәткә ия булган нәрсәләргә ия булу хакында бәхәсләшүе, бәрелешүе.

Яшәү урыны, акча, торак, хакимият һ.б. бәхәсләшү предметы булырга мөмкин. Низагта катнашучылар низаг субъектлары була. Низаг предметы — низаг тудырган мәсьәләләр яисә төрле байлык-уңайлыклар. Низаг сәбәбе һәм этәргече аның предметы белән бер үк нәрсә түгел. Юк кына бер вакыйга низагка этәргеч булырга мөмкин. Низаг төрле рәвешләргә керә һәм төрлечә таралыш ала. Өйдә — дусларның, туганнарның яисә урамда, транспортта — бөтенләй таныш булмаган кешеләрнең низаглашуы аеруча киң таралган. Бу — **шәхесләр арасындагы низаг.** Сүзгә килешү, аерылышу, забастовка кебек житдирәк рәвешләре дә була. Бунт, фетнә — каршылык күрсәтүнең стихияле рәвеше. Болар революция, сугыш, хакимият алышыну белән тәмамланырга мөмкин. Безгә этник төркемнәр (америкалылар



Икътисади низагның асылы — кешеләрнең дефицит байлык-уңайлыкларны, атап әйткәндә, эш хакын бүлешү уңаеннан мәнфәгатьләре каршылыкка кергән ике төркеменең бәрелешүе. Милекче өчен ул үз табышының күпмедер өлешен бүлеп бирү дигәнне аңлата, шуңа да ул аны гаять киметергә тели. Хезмәткәр өчен эш хакы бердәнбер яшәү чыганагы булып тора, шуңа да ул аны чиксез күтәрергә омтыла. Менеджер — милекче мәнфәгатьләрен якларга тиешле яңа хезмәткәр, ул низаглашучы арасында кала һәм аларны татулаштырырга тырыша.

һәм индеецлар), төрле буын вәкилләре (аталар һәм балалар), законга буйсынып яшәүче кешеләр һәм җинаятьчеләр (бурлык, криминаль мәдәният кыйммәтләре һәм өстенлекле мәдәният нормалары) арасындагы низаглар мәгълүм.

Низагның таралышы турында сүз алып барганда, анда катнашучыларның саны һәм нәтиҗәләрнең җитдилеге күз алдында тотыла. *Низагның хәл ителүе* — бу низагнын хәл ителмәслек каршылык фазасыннан үзара файдалы хезмәттәшлек фазасына күчүе. ***Низагны хәл итүнең*** түбәндәге ысуллары бар: ***компромисс, сөйләшүләр, арадашчылык, арбитраж, көч куллану, хакимияткә, законга таянып эш итү.***

Миллэтара, этник низагларны хэл итү — иң четереклесе булып тора. Һәрберсенең тарихи вакыйгаларга һәм фактларга нигезләнгән үз дөреслеге булганга, миллэтара низагларның күпчелегендә дошманлашкан якларның һәммәсе өчен дә объектив гадел карар кабул итү мөмкин түгел. Алар хакында без сүз алып барган һәм түбәндәгеләр сәбәпләре булу мөмкинлеген ачыклаган идек инде: а) башка милләтләр һәм хакимият тарафыннан үз этносына карата гаделсез мөнәсәбәт күрсәтелүен тою; б) дефицитлы иҗтимагый байлык-уңайлыкларны (хакимият, акча, территория, өстенлекләр һ.б.) бүлешкәндә әлеге этнос мәнфәгатьләренең чикләнүе; в) хакимият тарафыннан этносларның берсе дискриминацияләнү һәм шуны хуплау; г) гадәти аңның көнкүреш хорафатлары һәм стереотиплары, шулай ук шәхесне расачыл һәм милли нигезгә таянып кимсетү.

Низагны төрле яклап һәм дөрес аңлау өчен аның каршылыктан нәрсә белән аерылуын ачыкларга кирәк.

КАРШЫЛЫК — якларның мөһим сәяси, икътисади, этник мәнфәгатьләренең асылда бөтенләй туры килмәве, ярашмавы.

Теләсә кайсы низагның нигезендә каршылык ята һәм ул социаль киеренкелектә — кешеләрнең үз хәленнән ризасызлыгында һәм аны үзгәртергә әзер торуында чагылыш таба. Әмма каршылык ачыктан-ачык бәрелешкә әверелмичә, шул каршылык буларак ягъни низаг рәвешен алмыйча да калырга мөмкин.

Икътисади низагның нигезен милекче һәм яллы эшче арасындагы хәл ителмәстәй каршылык (бу очракта аны *антагонистик* дип атыйлар) тәшкил итә. Эшкә урнашкан (ялланган) чакта без үзебез дә сизмәстән иртәме-соңмы ачыктан-ачык низаг буларак чагылыш табачак каршылыкка керәбез. Эш хакыбызны тоткарлыйлар, яисә аны, инфляция үсүгә карамастан, арттырмыйлар яки киресенчә киметәләр — менә сезгә низагка этәргеч.

Милекче эш хакы түләргә тиеш. Әмма ул икътисади яктан үз милкеннән мөмкин булганча күбрәк табыш алырга кызыксынган. Теориядә ул ресурслардан бушлай гына файдаланып, салымнар һәм эш хакы түләмичә генә яшәр иде. Әмма бу мөмкин хәл түгел, ул түләргә тиеш.

Хезмәткәр өчен исә эш хакы киресенчә бердәнбер яшәү чыганагы булып тора. Сыйныфлар арасындагы көрәш гасырлар дәвамында шушы мантыйкка буйсына. Эшче милекчедән азмы-күпме лаеклы хезмәт һәм тормыш шартларын, яхшы эш хакын, гражданлык хокукларын, социаль иминиятләштерүне һ.б. йолкып ала диярлек.

Мондый каршылык икътисади мәнфәгатьләрнең бәрелешүе кебек низаг китереп чыгаручы сәбәпләр юкка чыкмыйча торып бетмәячәк. Менеджер низагны вакытлыча җайларга, кемнәрнедер ризалатырга, нидер вәгъдә итәргә, гади хезмәткәрләрне компания идарәсенә һәм керемнәрне бүлешүгә тартырга, уңай психологик атмосфера булдырырга, катгый булмаган эш графигы, демократик җитәкчелек стиле тәкъдим итәргә мөмкин. Әмма ул төп каршылыкны хәл итә алмый. Милекчегә һәм хезмәткәрләргә мондый арадашчы кирәк, чөнки, башкача булганда, аларның хезмәттәшлеге яу кырына әверелер иде.

Низаг яисә икътисади файданы (социаль байлык-уңайлыкларны) бүлешү өчен көрәш *төркемнең басым ясавында* чагылыш таба. Ул баш күтәрүләр, сәяси таләпләр кую яисә иҗтимагый фикерне үзләре ягына аудару рәвешләрен алырга мөмкин.

Парламент лоббие (кара: 10 сыйныф, § 21 «Сәяси тормыш субъектлары») басым ясау төркеменә типик мисал булып тора. Ташкүмернең (чималның) дефицитлыгы һәм һөнәри структурада үзенчәлекле урын тотулары аркасында хөкүмәткә басым ясаучы баш күтәргән шахтерлар турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Шахтерлар әлеге авыр эштә үзләрен алыштыручылар табылмаячагын яхшы беләләр. Әгәр теге яисә бу һөнәри төркемне (ул баш күтәргән очракта) икенче берсе эш урынында алмаштыра ала икән, ул басым төркеме булмый.

Массакүләм ризасызлык — низагның башлангыч ноктасы, ә төркем негативлыгы — аның нәтиҗәсе. Тегесе дә, монысы да социаль протест, ягъни массаларның үз хәленнән ризасызлыгы рәвешендә чагылыш табарга мөмкин.

Протест кешеләрнең үз-үзләрен низаглы тотышының актив рәвеше булып тора һәм шәхси, коллектив, оешкан, стихияле, ачык, яшерен, туры һәм читләтелгән төрләргә бүленә.

Протест акцияләренә мисаллар

1. Мартин Лютер Кинг җитәкчелегендәге 350000 нән күбрәк кеше 1967 елның 15 апрелендә **Нью-Йорк шәһәрендә Вьетнамдагы сугышка каршы протест демонстрациясендә** катнаша.

2. Сиу кабиләсенең берничә йөз кораллы индеецлары — Америка индеецларының **гражданлык хокуклары** өчен хәрәкәте әгъзалары — 1973 елда Пайн-Ридж резервациясендәге (Көньяк Дакота штаты) Вундед-Ни поселогын яулап алалар. Алар шул рәвешчә Америка хөкүмәтенең индеецларга карата булган мөнәсәбәтенә каршы протест белдерәләр. Протест 1890 елда сиу индеецларының хөкүмәт гаскәрләре белән соңгы бәрелеше булган җирдә оештырыла. Ул бәрелеш вакытында 200 гаскәри, хатын-кызлар һәм балалар һәлак булган.

3. 1971 елда нигезләнгән **«Гринпис»** оешмасы үз эшчәнлеген китларны аулауга каршы протест акцияләреннән башлап җибәрә. 80 нче елларда ул атом-төш коралын сынауларга чик куюны яклап бик актив чыгыш ясый. Оклендта батырылган судно экипажы Франциянең атом-төш коралын сынауларына протест йөзеннән кеше яшәми торган Муруроа атоллына китәргә ният иткән була.

4. Һиндстан азатлыгы өчен көрәшүче Мохандас Ганди үз тарафдарлары белән 1930 елның 12 мартында, Британия хакимлегенә протест йөзеннән, «тоз походы» оештыра. Әлеге акциягә, ярлы крестьяннар мәнфәгатьләренә зыян китереп, тозга салым кертү этәргеч бирә. Бик күп халык алдында Ганди диңгез ярында суны киптереп тоз табу церемониясен башкара. Бу өр-яңа **буйсынмау кампаниясен** башлауга сигнал була. 26 гыйнварда Ганди ачыктан-ачык тоз салымын бетерү, сугыш чыгымнарын киметү, протекционистлык пошлиналары кертү, рупияне девальвацияләү, хәрби тоткыннарны азат итү кебек таләпләр белдерә.

Үзеңнең ризасызлыгыңны пассив рәвештә белдерү ысулы — *каршылык* күрсәтүдән аермалы буларак, протест — үз мәнфәгатьләреңне яклауның актив рәвеше ул. Оешкан протест рәвешләре түбәндәгеләр:

- **ачык пассив протест** (боерыкларны үтәмәү, буйсынмау, эшкә чыкмау);

- **яшерен пассив протест** (каршылык күрсәтергә котырту, заговор, листовкалар ябыштыру, эшкә «салкынлык күрсәтү»);

- **ачык актив протест** (митинглар, демонстрацияләр, забастовкалар, стачкалар);

- **яшерен актив протест һәм каршылык күрсәтү** (террористлык көрәше, легаль булмаган сәяси партия төзү, хәрби юл белән хакимиятне алмаштыру өчен әзерлек).

Демонстрация ачык актив протестның бер төре булып тора. Ул нинди дә булса максатларны яклап яисә нәрсәгә дә булса каршы вакытлыча һәм яхшы оештырылган күмәк чыгыш рәвешендә була. Алдан ук газеталарга реклама бирү, хакимиятнең рәсми ризалыгын алу, транспарантлар ясау, рольләр бүлешү, хәрәкәт маршрутын һәм ораторларны сайлап алу планлаштырыла һәм әзерләнә. Демонстрацияләр җәмгыятьтә ныклы үзгәрешләр китереп чыгарырга мөмкин. Сул көчләр тарафыннан әзерләнгән массакүләм демонстрацияләр Россиядә ике революция — Февраль һәм Октябрь революцияләрен (1917) китереп чыгарды. 80 нче еллар урталарындагы үзгәртеп кору СССРның төрле шәһәрләрендә демонстрацияләр дулкынын күтәрде. Аларда халыкның гомуми саныннан 1 проценты гына катнашса да, сул көчләр демонстрацияләре (бер демонстрациядә 200 дән алып 700 мең кешегә кадәр катнашкан) бик нәтиҗәле булып чыкты: Совет державасы таркалды, КПСС тарих сәхнәсеннән төште, социалистик стройны капиталистик строй алмаштырды, халыкара социалистик система таркалды.

90 нчы еллар ахырында, 2000 елда һәм 2001 ел башында Россия каршылык хәрәкәте эчендә калган иде. Хезмәт шартларының начараюы, эш хакының үтә түбәнлеге (кайчак ул яшәү минимумы кадәр дә булмый) шахтерларны, табибларны, укытучыларны һәм башка һөнәр вәкилләрен көрәшкә күтәрде.

Протест хәрәкәтләре **социаль хәрәкәт** дип аталган күренешләрнең киңрәк классына керә. Алар социаль үзгәрешләрне яклап яисә аларга каршы тупланган гаять күпсанлы кешеләрне үз эченә ала, һәм зур төркемнәрнең иң оешкан һәм массачыл рәвеше булып торалар. Социаль революцияләр һәм дини реформацияләр — шуларның иң ачык мисаллары.

Күпчелек кешеләр хәрәкәтләргә турыдан-туры кушылып китми. Алар социаль хәрәкәткә җитәкчелек итүче нинди дә булса формаль оешмаларда катнашмасалар да, хәрәкәтнең программасына

телэктэшлек һәм хуплау белдереп, үз өлешләрен кертәләр. Тынычлык фонды кебек формаль оешмалар хәрәкәтнең абстракт максатларын һәм идеалларын велосипедларда узышу, имзалар җыю, митинглар һәм манифестацияләр, презентацияләрне финанслау, матбугатта реклама оештыру кебек конкрет гамәлләргә эвереләдерәләр.

Социаль хәрәкәт күп еллар һәм хәтта дистә еллар буена сузылырга мөмкин. АКШта коллыкны бетерү өчен көрәш (аболиционизм) XVIII гасырның ахырында башланып, XX гасыр ахырында гына тәмамлана. Шушы вакыт эчендә катнашучылар, хәрәкәтнең үз эчендәге максатлар, көрәш тактикасы һәм ысуллары үзгәреш кичерә. Кайбер хәрәкәтләрнең, әйтик, граждан хокуклары өчен хәрәкәтнең һәм ***феминизмның***, төрле шәһәрләрдә, хәтта төрле илләрдә таралып урнашкан күпсанлы эш төркемнәре була. Аларны координацияләү халыкара масштабта башкарыла. Күп кенә сәяси партияләрнең тарихы иҗтимагый хәрәкәттән башланып киткән. Максатларына карап, ***социаль хәрәкәтләр дүрт төргә бүленә.***

Реформаторлык хәрәкәтләре гамәлдәге системаны акрынлап һәм прогрессив үзгәртү өчен көрәшәләр.

Мисалга 80 нче еллар ахырында формалашкан, ул чакта хакимлек итүче коммунистик режимга оппозициядәге «Демократик Россия» хәрәкәтен китереп була. 1991 елда әлеге хәрәкәт тәкъдим иткән кандидат Б.Н. Ельцин Россия Президенты итеп сайлана. Хакимият өчен көрәштә «Демократик Россия» матбугатта, радио һәм телевидениедә чыгышлар ясады, митинглар һәм демонстрацияләр оештырды, парламентка басым ясады.

Экологик һәм феминистлык хәрәкәтләрен, Балтыйк буендагы «халык фронтларын» да реформаторлык хәрәкәтенә кертергә була. Алар җәмгыятьне киң колачлы яисә өлешчә үзгәртеп коруны хуплыйлар.

Чигенеш (регрессив) **хәрәкәтләре** иске тәртипләргә кайтуны (өлешчә яки тулысынча) яклыйлар. Гадәттә мондый хәрәкәтләрне элек хакимлек иткән сәяси көчләр оештыра. 1991 елга кадәр коммунистлар хакимлек итте, ә «август революциясе»ннән соң, оппозициягә китеп, алар җәмгыятьне социализмга кайтару өчен чигенеш хәрәкәте башладылар.

Утопик хәрәкәтләр үзләренә ихластан ияручеләр төркеме өчен идеаль җәмгыять төзү өчен көрәшәләр. Урта гасыр коммуналары, яшелләр хәрәкәте, «Лонга май» хәрәкәте, кришнаитлар хәрәкәте һ.б. утопик хәрәкәткә керә. Соңрак утопик социализм теоретигы буларак танылган эшмәкәр ***Роберт Оуэн*** (1771–1858) АКШта һәм Англиядә шәхси милектән, класслардан һәм эксплуатациядән азат булган

коммунистик тәҗрибә колонияләренә («Яңа Гармония») нигез сала. Аның бу эше уңышсызлыкка очрый һәм тиздән утопик хәрәкәт юкка чыга.

Революцион хәрәкәтләр гамәлдәге стройны, аның кыйммәтләрен һәм институтларын тамырдан үзгәртүне күздә тота. Гадәти булмаган максатлар экстраординар чаралар куллануны таләп итә. Гәрчә көч куллану барлык революцион хәрәкәтләр өчен хас булмаса да, террорчылык тактикасын (тотыклар алу, банк басу, сәяси лидерларны үтерү, халык тупланган урыннарда шартлатулар оештыру) революционерлар еш кулланалар.

Төшенчәләр: *низаг, каршылык, протест хәрәкәте, социаль хәрәкәт.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Низагка киңәйтелгән билгеләмә бирегез. Аның субъектына характеристика бирегез, объектын, сәбәпләрен, этәргечләрен һәм хәл итү алымнарын күрсәтегез. Үз тормышыгыздан низагларны хәл итүгә мисаллар китерегез.

2. Низагларны классификацияләгез.

3. Протест хәрәкәте нәрсә ул? Ул нинди рәвешләргә керергә мөмкин? Тормыштан берәр мисал китерә аласызмы?

4. Социаль хәрәкәт типларына характеристика бирегез һәм массачыл демонстрациягә ике-өч мисал китерегез.

***5.** Хәзерге Россиядә нинди низагларны аеруча актуаль дип санныйсыз?

***6.** Шундый модель тәкъдим ителә: төркемнәрнең байлык һәм файда өчен ярышуы аркасында туган низаг һәм җиңү. Түбәндә тасвирланган хәлләрнең кайсысы әлеге модельгә туры килә, ә кайсылары туры килми:

— милләтләрнең территория өчен көрәшүе;
— баскетбол матчы;
— сыйныфлар көрәше;
— гражданнар сугышы;
— этник низаг;

— сатучының сатып алучы белән бәрелешүе;

— төп башына утыртылган өлешчеләрнең үз акчаларын кайтаруны таләп итеп демонстрация уздыруы;

— дуэль.

Үзегезнең карашыгызны дәлилләгез.

***7.** «Үз-үзең белән низагка керү» дигән гыйбарәнең нәрсә аңлатуы турында фикер йөртегез.

***8.** Кешелек үсеше баскычларын анализлагыз һәм революцияләрсез генә үсеш мөмкинме яисә юкмы икәнен фаразлагыз.

? Проблема. Хәзерге Россиянең үсеше низагларны һәм социаль хәрәкәтләрне киметергә яисә, киресенчә, арттырырга нигез бирәме?

✍ **Практикум.** Тәкъдим ителгән таблицада сезгә уң һәм сул баганалардагы юлларны туры китерергә кирәк.

Таблица

Оешкан протест рәвешләре	
ачык пассив протест	митинглар, демонстрацияләр, забастовкалар, стачкалар
яшерен пассив протест	террорчылык көрәше, легаль булмаган сәяси партия төзү, хәрби юл белән хакимиятне алыштыруга әзерлек
ачык актив протест	боерыкларны үтәмәү, буйсынмау, эшкә чыкмау
яшерен пассив протест	каршылык күрсәтергә котырту, заговор, листовкалар ябыштыру, эшкә салкын караш

§ 10 (§31). Социаль контроль

Социальләштерү — мәдәни нормаларга өйрәтү һәм социаль рольләрне үзләштерү процессы. Ул иң беренче нәүбәттә шәхескә кагыла, әмма һәрчак әйләнә-тирәдәге кешеләрнең җентекле күзәтүе астында уза. Алар балаларны өйрәтү белән генә чикләнмичә, үзләштерелгән тәртип кагыйдәләренең дөреслеген контрольдә тоталар. Әгәр контроль аерым кеше тарафыннан башкарылса, ул шәхси характерда була, әгәр тулаем бер коллектив — гаилә, дуслар төркеме, учреждение яисә социаль институтлар — тарафыннан башкарылса ул җәмгыяви характер ала һәм *социаль контроль* дип атала.

Социаль контроль җәмгыятьтә тәртип саклауның аерым бер механизмы булып тора һәм аны ике төп элемент — нормалар һәм санкцияләр тәшкил итә.

НОРМАЛАР — җәмгыятьтә үз-үзеңне дөрес тоту күрсәтмәләре.

САНКЦИЯЛӘР — кешеләрне социаль нормалар бозмауга этәрүче кызыксындыру яисә җәза бирү чаралары.

Җәмгыятьтә югары бәяләнгән һәм аның тарафыннан сакланган барлык теге яисә бу нәрсә күрсәтмәгә әверелә. Кеше гомере һәм абруе, өлкәннәргә ихтирам, коллектив символлар (мәсәлән, байрак, герб, гимн), дини йолалар, дәүләт кануннары һәм башкалар җәмгыятьне берләштерү чаралары булып тора. ***Социаль күрсәтмәләр** — шәхескә яисә төркемгә ни дә булса кылуны тыю яисә рөхсәт итү. Алар төрле рәвештә булалар (телдән яисә язма, формаль яисә формаль булмаган).*

Социаль контроль урамдагы милиционер функциясен үти. Ул «урам аркылы чыгу кагыйдәләрен» бозучыларга «штраф сала». Әгәр социаль контроль булмаса, кешеләр ни теләсәләр — шуны һәм ничек теләсәләр шулай гамәл кылырлар иде. Котылгысыз рәвештә низаглар һәм шуның нәтиҗәсе буларак хаос килеп чыгар иде. Парламентта социаль контроль консерватор функциясен үти: ашыкмаска тәкъдим итә, гореф-гадәтләрне хөрмәт итү таләбен куя, җитәрлек сыгалмаган яңалыкларга каршы чыга. Ул — җәмгыятьтәге тотрыклылык нигезе. Аның булмавы яисә какшавы тәртипсезлекләргә, болгавырлыкка һәм иҗтимагый ызгышларга китерә.

Барлык социаль нормаларны аларны үтәү мәҗбүрилегенә бәйле рәвештә ***классификацияләргә*** мөмкин. Кайбер нормаларны үтәмәгән өчен шәхес ***хупламау, кырын карау*** кебек җиңел җәзага тартылырга мөмкин. Башка кайбер нормаларны бозуы аркасында исә кеше ***илдән сөрелү, гомерлек төрмә*** кебек бик кырыс санкцияләргә дә дучар ителә ала. Әгәр нормаларны җәзаның кырыслыгы белән бәйле рәвештә урнаштырсак, алар мондыйрак тәртиптә булыр: ***гореф-гадәтләр, шәхеснең үз-үзен тоту рәвеше (манералар), этикет, традицияләр, төркемдәге гадәтләр, холык, законнар, тыю (табу).*** Тыюларны һәм юридик законнарны (мәсәлән, кеше үтерү, динне мыскыллау, дәүләт сере саналган мәгълүматларны фаш итү) бозган өчен иң кырыс җәза бирелә. Төркемдәге, хосусан *гаиләдәге*, гадәтләрнең кайбер төрләрен санга сукмаган өчен (әйтик, гаилә әгъзалары ут сүндерүдән һәм ишекләрне ябып йөрүдән баш тарталар) иң җиңел җәза каралган.

Нормалар кешеләрне берләштерәләр, аларны коллектив итеп оештыралар. Бу хәл ничегрәк бара? Беренчедән, нормалар бер затның икенчесенә яисә башка затларга карата бурычлары да булып тора әле. Эшкә яңа гына алынган кешеләргә башлыклар белән хезмәттәшләренә караганда ешрак аралашуны тыеп, кече төркем үз әгъзаларына билгеле бер бурычлар йөкли һәм аларның башлыклар һәм хезмәттәшләре белән билгеле бер мөнәсәбәтләрен билгели. Димәк, нормалар төркемдәге, җәмгыятьтәге ***социаль мөнәсәбәтләр челтәрен*** булдыралар. Икенчедән, билгеле бер норманы үтәүче кешедән әйләнә-тирәдәгеләр төрлечә аңлатуга урын калдырмый торган гамәл көтәләр. Җәяүлеләрнең бер ишесе урамның уң ягыннан, ә аларның каршысына килүче икенче бер ишесе сул ягыннан бара икән, тәртипкә салынган, оешкан үзара хезмәттәшлек, әгәр инде кагыйдәләрне бозучылар булса, бәрелешләр һәм тәртипсезлекләр барлыкка килә. Нормаларны бизнеста аеруча ачыграк күрергә була. Әгәр партнерлар язылган һәм язылмаган кагыйдәләрне, нормаларны, законнарны үтәмәсәләр, бизнес алып бару гомумән дә мөмкин булмый. ***Нормалар*** *социаль үзара хезмәттәшлек системасын булдыралар. Аңа мотивлар, максатлар, эш-хәрәкәт субъектларының юнәлеше, эш-хәрәкәт үзе, өметләр, бәяләмәләр һәм чаралар керә.*

Шул рәвешчә нормалар, нинди сыйфатта булуларына карап, билгеле бер функция үтиләр: шәхеснең *үз-үзен тоту стандартлары* (бурычлар, кагыйдәләр) яки *үз-үзен тотудан көтелгәннәр* (башка кешеләр реакциясе). Гаилә әгъзаларының абруен һәм намусын саклау — һәр ир кешенең бурычы. Биредә норма шәхеснең тиешле үз-үзен тоту стандарты буларак күзаллана. Бу стандартка гаилә әгъзаларының көткәннәре, үзләренең намус һәм абруе сакланачагына өмете тәңгәл килә. Кавказ халыкларында бу норма аеруча югары бәяләнә, һәм аны санга сукмаган өчен бик каты җәза бирелә. Көньяк Европада яшәүчеләр турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Италия мафиясе гаилә намусын саклау нормасы буларак барлыкка килә, бары тик соңрак кына аның функцияләре үзгәрә. Үз-үзеңне тотуның кабул ителгән нормаларыннан тайпылучыларга бөтен җәмгыять җәза биргән.

Кешеләр ни өчен нормаларны үтәргә тырышалар, ә җәмгыять моны кырыс күзәтчелектә тота? *Нормалар — җәмгыятьтәге кыйммәтләр сакчысы ул.* Гаилә намусы һәм абруе — борын заманнардан бирле кешелек җәмгыяте тарихында иң әһәмиятле хәзинә дип таныла. Гаилә — җәмгыятьнең төп ячейкасы, һәм аның турында кайгырту — ир-атның (хәзерге җәмгыятьтә — хатын-кызның да) социаль статусын күтәрә торган гаять мөһим бурычы. Гаиләсе турында кайгыртуы аша ир-ат үзенең көч-куәтен, батырлыгын, шәфкатьлелеген һәм әйләнә-тирәдәгеләр тарафыннан югары бәяләнә торган башка сыйфатларын ачык күрсәтә. Аның социаль статусы күтәрелә. Үз гаиләсен яклый алмаучыларны, киресенчә, җәмгыятьтә санга сукмыйлар, аның статусы түбән тәгәри. Гаиләне яклау — аның иминлеге өчен ифрат мөһим шарт, шушы гаять әһәмиятле функцияне башкаруы традицион җәмгыятьтә ир-атны гаилә башлыгы итә. Кем беренче — ирме, хатынмы? Мондый бәхәсләр бөтенләй урынсыз булып кала. Нәтиҗәдә, гаилә иҗтимагый һәм психологик яктан бербөтен булып оеша. Ир-ат үзенең беренчелек функцияләрен башкара алмаган хәзерге җәмгыятьтә, традицион җәмгыятьтәге белән чагыштырганда, гаиләләр күпкә тотрыксызрак. Үз-үзеңне тотуның иж гади нормалары да төркем һәм җәмгыять тарафыннан бик югары бәяләнә.

Норма һәм кыйммәтләр (ценности) арасындагы аерма түбәндәгедән гыйбарәт: *нормалар — үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, кыйммәт* — яхшылык һәм явызлык, хак һәм нахак, тиешле һәм тиешсез һ.б. турындагы *абстракт төшенчәләр.*

Санкцияләрне 4 төргә бүләләр: уңай һәм тискәре, формаль һәм формаль булмаган. Алар 4 төрдәге бәйләнеш хасил итәләр һәм боларны мантыйкый дүртпочмак рәвешендә сурәтләргә мөмкин.

Формаль уңай санкцияләр (Ф+) — рәсми оешмалар (хөкүмәт, учреждениеләр, иҗат берлекләре) тарафыннан ачыктан-ачык хуплау: хөкүмәт бүләкләре, дәүләт премияләре һәм стипендияләре, фәнни дәрәҗәләр һәм мактаулы исемнәр, һәйкәл кую, мактау кәгазьләре тапшыру, югары вазыйфаларга сайлап кую һ.б.

Формаль булмаган уңай санкцияләр (Н+) — рәсми оешмалар катнашыннан башка гына халык тарафыннан хуплану: мактау, комплиментлар, сүзсез генә тану, дустанә мөнәсәбәт күрсәтү, алкышлар, дан, дәрәҗә, күңелгә ятышлы сүзләр, лидерлык һәм экспертлык сыйфатларын тану, елмаю.

Формаль тискәре санкцияләр (Ф-) — юридик законнар, хөкүмәт указлары, административ инструкцияләр, күрсәтмәләр, боерыклар нигезендә каралган җәзалар: граждан хокукларыннан мәхрүм итү, төрмәгә ябу, кулга алу, эштән куу, штраф, премияне кисү, милекне конфискацияләү, түбәнрәк вазыйфага билгеләү, урыныннан алу һ.б.

Формаль булмаган тискәре санкцияләр (Н-) — рәсми инстанцияләргә кагылмый торган җәзалар: шелтәләү, кисәтү ясау, мәсхәрәләп көлү, хурлау, кимсетү, чәнечкеле шаярту, мыскыллы кушамат тагу, санга сукмау, кул бирүдән яисә мөнәсәбәтләрне дәвам итүдән баш тарту, гайбәт тарату, яла ягу, тискәре бәяләмә, шикаять, памфлет яисә фельетон чыгару, фаш итүче мәкалә, анонимка.

Социаль санкцияләр кайбер очракларда чит кешеләрнең катнашуын таләп итә, кайбер очракларда таләп итми. Эштән җибәрү учреждениенең кадрлар бүлеге аша рәсмиләштерелә һәм алдан ук боерык яисә карар чыгаруны күздә тота. Карар чыгару белән тәмамалана торган суд эшен караудан соң гына җинаятьчене төрмәгә ябып була. Административ җаваплылыкка тарту, әйтик, транспортта билетсыз барган өчен, рәсми зат — контролер, ә кайчакта милиционер катнашында гына башкарыла. Фәнни дәрәҗә алу өчен фәнни диссертация яклау, оппонентлар чыгышы һәм гыйльми совет хупламы кирәк.

Төркемдәге гадәтләрне санга сукмаучыларга карата санкцияләр азрак кеше катнашуны таләп итә, шулай да кеше аларны бервакытта да үз-үзенә каршы кулланмый. ***Әгәр кеше үзенә каршы үзе санкцияләр куллана һәм бу аның үзенә юнәлтелә икән, мондый контроль төрен үз-үзеңә контроль дип санарга кирәк.*** Мондый контрольне эле тагын ***эчке контроль*** дип тә атыйлар: үз-үзен тотышын шәхес гомум кабул ителгән нормаларга туры китереп җайга салырга тырыша. Социальләшү процессында нормалар бик тотрыклы булалар, алардан тайпылса, кеше уңайсызлык хисе кичерә, үзен гаепле саный. Үз-үзен тиешенчә тоту нормаларына каршы килеп, берәү иң якын дустының хатынына гыйшык тота, тормышта зуррак уңышларга ирешкәннәрдән көнләшә. Мондый очракларда вөҗдан газабы турында сүз алып бару урынлы. ***Вөҗдан — эчке контроль чагылышы ул.***

Рациональ күрсәтмәләр буларак, гомум кабул ителгән нормалар аң өлкәсенә карыйлар; аңга нигезләнмәгән уй-фикерләр өлкәсе табигый импульслардан тора. Үз-үзеңне контрольдә тоту табигый хисләрне йөгәнләү дигән сүз, ул *ихтыяр көченә* нигезләнә. Импульсив тәртип, үз теләкләреңне йөгәнли белмәү балалар өчен хас. Шуңа күрә импульсив тәртипне **инфантилизм** дип атыйлар. Рациональ нормаларга, йөкләмәләргә, ихтыяр көченә туры килә торган тәртип,



киресенчә, *җитлеккәнлек* күрсәткече дип санала. Социаль контроль 70 процент очракта үз-үзеңне контрольдә тоту хисабына башкарыла.

Җәмгыять әгъзаларының үз-үзен контрольдә тотуы югарырак булган саен, бу җәмгыятьтә тышкы контрольнең кирәге шуның кадәр азрак була. Һәм киресенчә, үз-үзеңә контроль түбәнрәк булган саен, тышкы контроль шуның кадәр көчлерәк булырга тиеш. Әмма гражданнар никадәр катырак контрольдә, вакчыл күзәтчелектә тотылса, аларның үзаңы үсеше, ихтыяр чагылышы шуның кадәр ныграк тоткарлана, эчке ихтыяр көче тоныклана. Шул рәвешчә, җәмгыять йомык әйләнә буенча хәрәкәт итүгә дучар ителә. Кешелек тарихында моңа мисаллар шактый күп. Еш кына катгый контрольне гражданнарга файдага дип күрсәтергә тырышалар, ягъни, шул рәвешчә җәмгыятьтә тәртип урнаштырырга мөмкин, имеш. Әмма мәҗбүри контрольгә күнеккән гражданнар эчке контрольне үстерүгә игътибар бирмиләр. Алар акрынлап үз өсләренә җаваплылык алырга һәм рациональ нормаларга нигезләнеп гамәл кылырга сәләтләрен җуя баралар. Алар мәҗбүри нормаларның акылга нигезләнгән булуына шик белдерәләр, һәм яшерен генә бу нормаларга теләсә нинди каршылык күрсәтүне акыл нигезенә корырга керешәләр. Әйтик, нормаларга буйсыну түгел, бәлки аларга каршылык күрсәтү акылга нигезләнгән дип саналганга, социаль тәртип нигезләренә куркыныч тудырган декабристларны — революционерларны, патша үтерүчеләрне Россия җәмгыятендә аклыйлар.

Үз-үзеңне контрольдә тотудан аермалы буларак, ***тышкы контроль — гомуми кабул ителгән үз-үзеңне тоту нормалары һәм законнары үтәлүен гарантияләүче институтлар һәм механизмнар җыелмасы ул.*** Аның *формаль* һәм *формаль булмаган* төрләре була. Беренчесе туганнар, дуслар, коллегалар, танышлар, гореф-гадәтләр яки массакүләм мәгълүмат чаралары аша чагылыш тапкан иҗтимагый фикер тарафыннан хуплануга яисә гаепләнүгә нигезләнә.

Традицион авыл җәмәгате үз әгъзалары тормыш-көнкүрешенең барлык якларын контрольдә тоткан: кәләш сайлау, бәхәс һәм низагларны хәл итү юллары, яңа туган сабыйларга исем сайлау һ.б. Болар — язылмаган кагыйдәләр. Күпчелек очракта җәмгыятьнең аксакаллары тарафыннан белдерелә торган иҗтимагый фикер контрольдә тотучы булып торган. Социаль контрольнең бердәм системасында диннең дә үз урыны булган. Традицион бәйрәмнәр һәм йолалар (әйтик, никахлашу, сабый туу, ярәшү һ.б.) белән бәйле ритуаллар һәм церемонияләрне катгый үтәү социаль нормаларга хөрмәт хисе тәрбияләгән, аларның кирәклегенә тирән ышаныч тудырган.

Әгәр традицион җәмгыятьтә социаль контроль язылмаган кагыйдәләргә нигезләнсә, хәзерге җәмгыятьтә исә аның нигезен язылган нормалар: инструкцияләр, указлар, боерыклар, законнар тәшкил итә. Формаль контроль судлар, мәгариф, армия, җитештерү, массакүләм мәгълүмат чаралары, сәяси партияләр, хөкүмәт тарафыннан тормышка ашырыла. Мәктәп — имтихан билгеләре, хөкүмәт — салым салу системасы һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү, дәүләт — полиция, яшерен хезмәт, радио, телевидение каналлары һәм матбугат органнары аша контрольлек итә.

Җентекле (вакчыл) контроль, бу очракта җитәкче һәр гамәлгә тыкшына, дөресли, кисәтү ясый һ.б., *күзәтчелек* дип атала. Күзәтчелек җәмгыятьнең барлык катламнарында да бар. Әгәр ул дәүләт тарафыннан башкарылса, бөтен илне колачлый торган гаять зур система рәвешен алып, махсуслаштырылган иҗтимагый *институтка* әверелә. Мондый системага җинаятьчеләрне эзләү бюролары, детектив агентлыклары, полиция участоклары, төрмә сакчылары, конвой гаскәрләре, судлар, цензура керә. Социаль контрольнең тагын бер төре — иҗтимагый фикер. Аның турында без соңрак сүз алып барырбыз.

Төшенчәләр: *нормалар, санкцияләр, үз-үзеңә контроль, тышкы контроль.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Сезгә билгеле булган барлык социаль нормалар төрләрен язып алыгыз һәм һәр төр каршына аларны бозган өчен нинди җәза каралганлыгын билгеләгез.

2. Социаль нормалар нинди функцияләр үти?

3. Күзәтчелекнең контрольдән аермасын күрсәтегез. Конкрет мисаллар китерегез.

4. Санкцияләр төрләрен классификацияләгез.

***5.** Бизнеста эшлекле үзара мөнәсәбәтләр моделен уйда төзегез һәм түбәндәгеләргә тасвирлама бирегез: 1) партнерлар нинди максатларны күздә тоталар, 2) аларның мәнфәгатьләре һәм мотивлары нинди, 3) эш йөртүдә турыдан-туры һәм читтән торып катнашучылар кемнәр, 4) гамәлнең үзенең технологиясе нинди, 5) эшлекле операцияләр нинди нормалар белән җайга салына һәм аларны бозган өчен нинди җәза каралган? Текстиль фабрикасына чит ил җиһазларының зур партиясен китерүне мисалга китерегез.

*** 6.** Өй эше, медицина белешмәсе, паспорт, транспортта бару билеты, китапханә, фәнни дәрәҗә, парламент утырышы, телефон, компьютер, телевизор, кием, реклама — болар иҗтимагый контроль чаралары була аламы?

? **Проблема.** Без бүтәннәрне бик теләп әйләнә-тирә мохитне чүпләмәскә, электр утын бушка яндырмаска, акча сарыф итмәскә өндибез, контроль булмаганда үзебез дә кыла торган гамәлләрне башкалар кылса, аларны шелтәлибез. Ни өчен тышкы контроль кешегә эчке контрольгә караганда җиңелрәк бирелә?

Практикум 1. Түбәндәге санкцияләрнең төрләрен билгеләгез: Нобель бүләге, суд аклавы, матбугатта басылган ачык хат, офицер дәрәҗәсе бирелү, парламентка сайлану, Яңа ел открыткасы, квартал премиясе, дөнья чемпионы исеме, җитлеккәнлек аттестаты.

✍ **Практикум 2.** Түбәндәге исемлектән мәгънәсе ягыннан «социаль контроль» төшенчәсе белән бәйле терминнарны гына сайлап алыгыз:

урам, мобильлек, бию, тамыр, авыру, санкцияләр, җинаятьчелек, карабинер, волокита, ришвәт, бюрократлык, хәерчелек, норма, ат абзары, институт, байлык, мәдәният, баллон, төрмә, габаритлар, милиционер, штраф, пионер, кәбестә, акча, хакимият, җаваплылык, иерархия, дару, стратификация, шифоньер, җәза, статус, хатын-кыз, роль, абруй, керем, иреклелек, хокуклар, пирамида, тигезсезлек.

§ 11 (§ 32). Тайпылышлы һәм хокукка каршы тәртип

Җәмгыять гомер-гомергә кешеләрнең үз-үзен тотышында *ярамаган якларны* булдырмаска тырыша. Генийлар һәм явызлар, бик ялкаулар һәм гаять хезмәт сөючәннәр, хәерчеләр һәм байлар бердәй дәрәҗәдә диярлек җәмгыятьтә кабул ителми. Уртачалыктан уңай якка да, тискәре якка да кискен тайпылыш җәмгыятьтәге тотрыклылыкка яный, ә ул исә һәрчак бар нәрсәдән дә мөһимрәк дип санала.

Кешенең тайпылышлы тәртибе девиантлык дип атала. Ул язылган һәм язылмаган нормаларга туры килми торган теләсә нинди эш-гамәлне аңлата. Кайбер җәмгыятьләрдә, җитди тәртип бозулар турында әйтеп тә тормастан, гореф-гадәтләрдән аз гына тайпылу да бик кырыс җәзага тартылган. Бар нәрсә дә контрольдә тотылган; җиткән чәч йөртү, киенү рәвеше, үз-үзеңне тоту манерасы. Б.э. кадәр V гасырда Борынгы Спарта хакимнәре һәм XX гасырда совет партия органнары шулайрак гамәл кыла. 60–70 елларда мәктәп укытучылары «озын чәчлеләр»гә каршы көрәш алып барды, хәрбиләр үрнәгендә балаларга бердәй мәктәп киеме кидерүне алга сөрде, үз-үзләрен «дөрес тотмаган»нарның ата-аналар җыелышларында тетмәсен тетте.

Девиацияләргә каршы көрәш еш кына хисләр, фикерләр, гамәлләр төрлелегенә каршы көрәшүгә кайтып калды. Гадәттә бу бернинди нәтиҗәсез тәмамлана: күпмедер вакыт узуга гомуми тәртиптән тайпылыш тагын да көчәеп яңадан калкып чыга иде.

Күп кенә җәмгыятьләрдә девиантлыкны контрольдә тотуда *симметрия сакланмый*: начар якка тайпылыш гаепләнә, ә яхшы якка тайпылыш — хуплана. Тайпылышның уңай яисә тискәре булуына карап, девиацияләрнең барлык төрләрен билгеле бер яссылыкта урнаштырырга була. Аның бер полюсында үз-үзләрен тотышлары җәмгыятьтә *максималь хупланмауга* дучар булган затлар төркеме: революционерлар, террорчылар, үз илен яратмаучылар, сәяси эмигрантлар, сатлыкҗаннар, динсезләр (атеистлар), җинаятьчеләр, вәхшиләр, циниклар, сукбайлар. Икенче полюсында исә үз-үзләрен тотышында тайпылышлар *максималь хуплаучылар* төркеме: милли каһарманнар, мәшһүр артистлар, спортчылар, галимнәр, язучылар, рәссамнәр, музыкантлар, сәяси лидерлар, миссионерлар, хезмәт алдынгылары, сәламәт һәм матур кешеләр.

Әгәр хисаплап карасак, нормаль үсештәге җәмгыятьләрдә һәм гадәти шартларда һәр төркемгә халыкның гомуми санынннан 10–15 проценты туры килә. Киресенчә, ил халкының 70 процентын «тотрыклы урталыктагылар» — бик аз тайпылышлы кешеләр тәшкил итә.

Гәрчә күпчелек кешеләрнең үз-үзен тотышы законнарга каршы килмәсә дә, аларны тулысынча закон нигезендә яшәүчеләр, ягъни социаль конформистлар дип тә атап булмый. Мәсәлән, Нью-Йорк халкының 99 проценты сораштырулар вакытында эшкә соңга калу, тыелган урында урам аркылы чыгу, тәмәке тарту кебек вак шуклыклар турында әйтеп тә тормастан инде, бер яисә берничә тапкыр законга каршы гамәл: кибеттә караклык, салым инспекторын яисә посттагы полицейскийны алдау һ.б. шундыйларны кылулары турында әйткәннәр. Вакыйгаларның бик аз өлеше генә исәпкә алынганлыктан, конкрет җәмгыятьтә девиантлыкны тулысынча тасвирлап бирү гаять кыен.

Шулай итеп, ***кешенең җәмгыять тарафыннан гаепләнә торган үз-үзен тотышы девиантлык*** дип атала. Аңа гамәлләрнең билетсыз транспортта барудан алып кеше үтерүгә кадәр булган гаять киң даирәсе керә. Киң мәгънәсендә ***девиант — теләсә кайсы юлдан язган яисә нормадан тайпылган кеше ул***. Мәсьәләгә мондый караш тайпылышның рәвешләре һәм таралышы турында сүз алып баруга этәрә. *Девиантлыкның төрләре* яисә *рәвешләре* — җинаять кылу, эчкечелек, наркоманлык, фәхешлек, гомосексуализм, комарлы уеннар, психик авырулар, үз-үзенә кул салу.

Тар мәгънәсендә девиантлык дигәндә җинаять җаваплылыгына тартылмый торган, башкача әйткәндә, хокукка каршы булмаган тайпылышлар күздә тотыла. **Хокукка каршы** гамәлләр җыелмасын, яки җинаятьләрне, социологиядә аерым атама белән **деликвентлык** (сүзгә сүз — *җинаятьчел*) дип йөртәләр. Төшенчәнең киң һәм тар мәгънәләре социологиядә бердәй кулланыла.

Социаль контрольнең тайпылышларга каршы көрәш институтларының иң әһәмиятлесе — ***җәмәгатьчелек фикере — халыкның күпчелеге яисә бер өлеше тарафыннан хупланыла торган дөрес карашлар, бәяләмәләр, фикерләүләр җыелмасы***. Ул житештерү коллективына, зур булмаган поселок халкына, социаль сыйныфка, этник төркемгә һәм гомумән җәмгыятькә хас була. Иҗтимагый фикернең тәэсире, мөгаен, иң көчлесе дер. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң тәмәке тарту модага керә. Фатирда яисә офиста тәмәке тарту гадәти күренеш буларак кабул ителә. Әмма 1957 елда табиблар моның организмга тискәре йогынты ясавын исбатлыйлар. Җәмәгатьчелек фикере бик кискен рәвештә үзгәрә: матбугатта сәламәт яшәү рәвешен хуплауга юнәлтелгән кампания колач җәя. Хәзер тәмәкечеләр гомуми гаепләүгә дучар ителәләр. Зарарлы гадәте кешенең иҗтимагый дәрәҗәсенә һәм абруена зыян китерергә мөмкин. Мәсәлән, АКШта тәмәке тартучыларны кайбер эшләргә алмыйлар. Аларга каршы бөтен җәмгыять көрәш алып бара.

Социология җәмәгатьчелек фикерен бик җентекләп өйрәнә. Аны ике юл белән: гади гражданнар арасында сораштырулар уздырып, соңыннан статистика күрсәткечләрен берләштереп, *җәмәгатьчелек фикере лидерлары* арасында сораштырулар алып барып тикшерәләр.

Иҗтимагый нормаларны бозу җитди һәм җитди булмаган, аңлы рәвештә кылынган яисә аңлы рәвештә кылынмаган булырга мөмкин. Аңлы яисә аңсыз рәвештә кылынуларына карамастан, хокукка каршы гамәл дип бәяләнгән барлык җитди хокук бозуларны ***делинквент*** (җинаятьчел) ***тәртип*** итеп карыйлар. Эчкечелек һәм наркомания — девиантлыкка типик мисал. Эчкече һәм наркоман — авыру кеше булу белән бергә, девиант та әле, чөнки ул үзенең социаль ролен тиешенчә үтәргә сәләтсез. Кешенең үз-үзенә кул салуы, ягъни үз ирекe белән һәм алдан уйлап үз гомерен чикләве — шулай ук девиация. Әмма кеше башка бер кешене үтерсә — бу инде җинаять.

Мошенниклык, караклык, ялган документлар әзерләү, ришвәт, сәнәгать шпионажы, вандаллык, урлау, ватып кереп урлау, автомобильләр куып китү, янгын чыгару, фәхешлек һәм хокукка каршы булган гамәлләрнең башка төрләре җинаять була.

Девиантлык, билгеле бер төркемнең мәдәни нормаларына гына кагылганлыктан, *шартлы* төшенчә булып тора. Әмма делинквентлык *ил законнарына карата абсолют* була. Түбән катлау вәкилләре урамда үзләренең кеше талавын акча табуның нормаль бер юлы яисә социаль хаклык урнаштыру ысулы дип тә санарга мөмкиннәр. Әмма бу тайпылыш түгел, җинаять булып тора, чөнки кеше талауны җинаять буларак билгеләүче абсолют норма — юридик закон бар.

Җинаятьләр ешрак була торган шәһәр районнарын — *криминоген* районнар дип, ә девиант һәм делинквент гамәлләр кылу мөмкинлеге башкаларга караганда зуррак булган төркемнәрне *куркыныч* (риск) *төркемнәре* дип атыйлар. Хосусан, боларга яшьләр керә. Мондый тартылуга биологик һәм иҗтимагый җитлеккәнлекләр, шулай ук үсмернең үз-үзенә куйган таләпләре белән аңа җәмгыять куйган таләпләр арасындагы аерма этәргеч бирә. Формалашып килүче организмның физиологик үзенчәлекләре аркасында үсмер бик югары активлык күрсәтә, әмма иҗтимагый яктан житлегеп житмәве нәтиҗәсендә ул, гадәттә, үз-үзен контрольдә тотуга әзер булмый. Ул үз гамәлләренең барлык нәтиҗәләрен алдан күреп эш итәргә сәләтсез була, шәхес ирекe һәм бәйсезлеге дигән төшенчәләрне ялгыш аңлый. Социология белгечләре кешенең, тайпылышлы, девиант тәртип белән ешрак очрашкан һәм яше ягыннан кечерәк булган саен, мондый тәртип үрнәкләрен күбрәк сеңдерә баруын исбатладылар.

Төшенчәләр: *девиант тәртип, делинквент тәртип, куркыныч төркеме.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Девиант һәм делинквент тәртип арасында нинди аерма бар? Сезгә мондыйларга тап булырга туры килгәне юкмы?

2. Көнкүрештә сезнең тирәдәге кешеләрнең үз-үзләрен тотышын анализлагыз һәм үзегез девиант дип санаган гамәлләрен күрсәтегез.

3. Үсмерләр җинаятьчелеге нәрсә ул? Ул оешкан җинаятьчелектән ни белән аерыла?

*4. Россия тарихында тышкы контроль аеруча көчле һәм эчке контроль аеруча зәгыйфь булган чорларны билгеләгез. Тышкы диктатураның нәтиҗәләрен, ысулларын һәм рәвешләрен тасвирлагыз: алар девиант һәм делинквент тәртипкә нинди йогынты ясаганнар?

*5. Кайчак, җинаятьчелекне бетерү өчен Россиягә «каты кул» кирәк, дигән фикерләр ишетергә туры килә. Сез бу турыда ни уйлыйсыз?

? Проблема. Кайбер кешеләр ни өчен җинаятьче булып китәләр һәм закон бозалар — моңа кагылышлы төрле карашлар бармы? Бу турыда үз фикерегезне белдерегез.

✍ Практикум. Галимнәр хокукка каршы гамәл кылу белән Мин-концепция арасында бик тыгыз бәйләнеш барлыгын ачыклаганнар. Хокук бозучы үсмерләрнең үз-үзләрен бәяләве законнарны бозмаучы үсмерләрнекеннән түбәнрәк. Хокукка каршы чыгу аша яшь хокук бозучылар адекват булмаган Мин-концепцияләрен компенсациялиләр булса кирәк, дигән аңлатма яши. Үз-үзләрен түбән бәяләүләре аркасында, үзләренә карата үзләренең үк нәфрәт хисен киметү өчен, алар девиант тәртип үрнәкләренә ияреп китәләр. Мондый үсмерләрнең үз-үзен тотышы үз-үзләре турындагы түбән фикергә туры килгәндә, аларның үзләренә карата нәфрәт хисе кими төшә. Үз-үзләренә карата хөрмәт хисен тергезү өчен, алар девиант төркемнәргә кушылалар, биредә җәмгыятьнең башка өлешендә тапмаган хуплау табалар.

Сез күп карашларның бары берсе белән генә таныштыгыз. Әмма башка фикерләр дә бар. Шуларның берсен сезгә аңлатып бирергә кирәк булачак. Шул ук вакытта махсус әдәбияттан файдалану мәҗбүри түгел, үз тормыш тәҗрибәгезгә таянырга гына кирәк. Сезгә үз-үзен тотышы тайпылышлы булган кешеләр очраганы бардыр. Сез ничек уйлыйсыз, алар ни өчен үз-үзләрен шулай тотты һәм үз гамәлләрен ничек аңлатты икән?

4 (10) бүлек

Мәдәният һәм рухи хәят



§ 12 (§ 33). Мәдәниятнең этик нигезе

Җәмгыятьнең рухи даирәсен кеше эшчәнлегенең сарайлар һәм гыйбадәт йортлары төзүдән алып фәнни теорияләр булдыру һәм дини ритуаллар үтәүгә кадәр булган барлык өлкәләре тәшкил итә. Мәдәният (культура — лат. cultura — тәрбияләү, мәгариф, җәмгыятьне үстерү, олылау) рухи даирәнең нигезен тәшкил итә. ***Мәдәният дигәндә, җәмгыятьнең, кешенең иҗади көчләре һәм сәләтләренең кешеләр хәяты һәм эшчәнлеге төрләрендә һәм рәвешләрендә, аларның үзара мөнәсәбәтләрендә, шулай ук алар тарафыннан булдырыла торган матди һәм рухи хәзинәләрдә чагылыш тапкан билгеле бер тарихи үсеш дәрәҗәсен күздә тотарга кирәк.*** «Мәдәният» төшенчәсе билгеле бер тарихи чорларны (антик мәдәният), тәгаен җәмгыятьләрне, халыкларны һәм милләтләрне (майя мәдәнияте), шулай ук эшчәнлекнең һәм хәятның үзенчәлекле даирәләрен (хезмәт мәдәнияте, сәяси мәдәният, нәфис мәдәният) характерлау өчен кулланыла. Таррак мәгънәсендә мәдәният кешеләрнең рухи даирәсен аңлата.

Аңа кешеләр эшчәнлегенең предмет тормышы рәвешендәге нәтиҗәләре (машиналар, корылмалар, тикшеренү нәтиҗәләре, сәнгать әсәрләре, әхлак һәм хокук нормалары һ.б.), шулай ук кешенең эшчәнлегендә файдалана торган көчләре һәм сәләтләре (белем, һөнәр, күнекмә, интеллект, әхлакый һәм эстетик үсеш дәрәҗәсе, дөньяга караш, кешеләрнең аралашу ысуллары һәм рәвешләре) керә.

Мәдәниятнең үзәген **кыйммәтләр** тәшкил итә. Мәдәнияткә мондый билгеләмә бирү — философлар тәкъдиме, ул исә мәдәни

күренешләр асылына үтеп керүне (фикерләү, төшенү ярдәмендә) күздә тота.

> **КЫЙММӘТ** — әйләнә-тирә мохит объектларының кеше, иҗтимагый төркем, гомумән җәмгыять өчен уңай яисә тискәре әһәмияте.

Бу әһәмиятне бәяләү критерийлары һәм ысуллары әхлакый принципларда һәм нормаларда, идеалларда, күрсәтмәләрдә, максатларда чагылыш таба. *Кыйммәтләрнең матди, иҗтимагый-сәяси һәм рухи; уңай һәм тискәре төрләре була.*

Сүзнең киң мәгънәсендә кыйммәт дип уңай күренеш, өстенлек бирелә торган нидер турында, ягъни кешенең (яки кешеләр төркеменең, җәмгыятьнең) нинди дә булса мәнфәгатьләрен, ихтыяҗларын, ниятләрен, максатларын, планнарын канәгатьләндерә торган нәрсәләр турында гомумиләштерелгән, тотрыклы күзаллаулар атала. Әхлакый нормаларны үтәү мәҗбүри. Хәтта мәҗбүри генә дә түгел, бернинди ташламаларсыз мәҗбүри була. Бу исә *алар билгеле бер шартларда гына түгел, бәлки һәрчак үтәлергә тиеш* дигәнне аңлата. Кешеләр туган-тумачалары, дуслары, хезмәттәшләре, ватандашлары белән генә түгел, бәлки барлык кешеләр белән мөнәсәбәтләрен әхлакый нормалар нигезенә корырга тиешләр.

Аларны шулай ук изгелек, гаделлек, ватанпәрвәрлек, романтик мәхәббәт, дуслык һ.б. шундыйлар турында җәмгыятьтә хупланучы һәм күпчелек тарафыннан кабул ителүче күзаллаулар дип тә аңлап була. Кыйммәтләр икеләнүгә юл калдырмый, алар барлык кешеләр өчен өлге, идеал булып торалар. Әгәр хәзинәләр гәүдәләнешенең, төрләренең, рәвешләренең һәм типларының бөтен төрлелеген гомумиләштерсәк, һәммә кешеләр һәм җәмгыятьнең барлык даирәләре өчен әһәмиятле булган җиде фундаменталь кыйммәтне аерып күрсәтергә туры киләчәк. Бу ***Хакыйкать, Матурлык, Шәфкать, Файда, Хакимлек, Гаделлек, Ирек.***

Без җәмгыятьнең дүрт төп даирәсен һәм җиде фундаменталь кыйммәтне аерып күрсәттек. Алар арасында ярашу барлыкка килә. *Икътисад даирәсенең* нигезен **Файда** тәшкил итә. Аның нинди хосусый терминнар — керем, табыш һ.б. — аша чагылдырылуы мөһим түгел.



Социаль даирәдә иң мөһиме — **Гаделлек.**

Тигезлек, туганлык, күмәклек, дуслык, алмашу, хезмәттәшлек гаделлеккә нигезләнә. Ул боларның иң югары эчтәлеген һәм мәгънәсен тәшкил итә.

Сәяси даирә икенче бер фундаменталь кыйммәт — **Хакимлек** тирәсендә оеша. Хакимият, лидерлык, өстенлек, басым ясау, карьера, конкурентлык өчен көрәш — болар барысы да хакимлеккә нигезләнә. Гәүдәләнеш рәвешләре төрле булса да, асыллары бер үк.

Рухи даирә — барлык дүрт даирә арасында иң чуары. Аңа мәгариф, фән, мәдәният һәм дин керә. Алар берьюлы өч кыйммәткә — **Хакыйкатькә, Матурлыкка, Шәфкатькә** таяна. Дин — шәфкать, фән — хакыйкать, мәдәният һәм сәнгать матурлык тирәсендә оеша. Мәгариф өлкәсендә төп рольне шәфкать һәм хакыйкать уйный.

Ирек дигән кыйммәт аерым урын тота. Ул һәр кешегә һәм дүрт даирәнең һәрберсендә кирәк. Икътисад даирәсендә — эшмәкәрләргә эшләрен уңышлы алып бару өчен. Чикләүче законнар һәм карарлар аларга файда (табыш) китермәячәк. Дин тоту иреге дә зарур. Фәндә, мәгарифтә һәм сәнгатьтә иҗат иреге шулай ук бик югары бәяләнә. Ирек сәясәтчеләргә, гади гражданнарның шәхси эшләрендә дә гаять кирәк. Шулай итеп, ***ирек — һәркем өчен уртак хәзинә, уртак кыйммәт*** булып тора.

Әлеге сүзләр, әлбәттә, дөньяның гаять схематик һәм берьяклы күренешен чагылдыра. Тормышта барысы да күпкә катлаулырак. Әйтик, галим уйлап тапкан хак теория бер үк вакытта файдалы да була. Рәссам исә үзенең матур картиналары белән кешеләрдә шәфкать тә тудырырга тырыша. Бер үк кеше берничә кыйммәткә омтыла. Җәмгыятьнең аерым даирәсе бары бер һәм бердәнбер кыйммәткә генә нигезләнә алмый.

Берсе икенчесен инкарь итә торган кыйммәтләр дә бар. Кайбер, беренче карашка, төрле **кыйммәтләр** янәшә яшәргә, берләшергә мөмкиннәр. Мәсәлән, табыш алуга омтылу хакимлек белән яраша. Эре сәясәтчеләр белән эре эшмәкәрләр берлеге нәтиҗәле була. Хакимиятне гаять зур акчалар түләп сатып алалар, ә чикләнмәгән хакимият исә зур табыш алу мөмкинлеге бирә. Әмма сәясәтчеләр арасында гомере ахырына кадәр гадел һәм шәфкатьле булып калганнары бик сирәк.

Фундаменталь **кыйммәтләр,** фундаменталь институтлар кебек үк, — кешелек җәмгыятенең таянычы.

Хәзер *мораль, әхлак*, һәм *этика* турында сүз алып барыйк. «Этика» термины «ethos» дигән борынгы грек сүзеннән алынган. Борынгы грек философы Аристотель этик уңай сыйфатлар дигәндә кеше холкындагы рухи хасиятләрне, атап әйткәндә, чама хисен, егетлекне, юмартлыкны күздә тота. Аристотельнең «этик» дигән терминын грекчадан латинчага тәрҗемә иткәндә, Борынгы Римның күренекле ораторы һәм сәяси эшлеклесе Цицерон «moralis» (әхлакый) дигән термин куллана. Ул бу сүзне «mos» (mores — күплек санда) сүзеннән — грек телендәге «этос» сүзенең холык, темперамент, мода, кием өлгесе, гореф-гадәт дигәнне аңлатучы латинча аналогын кулланып ясаган. IV гасырда латин телендә «moralitas» («мораль») термины пәйда була. Ул — грек телендәге «этика» терминының турыдан-туры аналогы. Әлеге сүзләрнең икесе дә Европа телләренә кергән.

Рус телендә аларга — «**нравственность**», татар телендә «**әхлак**» төшенчәсе тәңгәл килә. Соңрак этика дигәндә, — белемнең аерым бер тармагын, ә мораль (әхлак) дигәндә, ул өйрәнә торган предметны күздә тоталар. Кайчак әхлак дигәндә, — югары идеаллар, ә мораль дигәндә, кешенең үз-үзен тотышының гадәти нормалары аңлана. Шулай да «этика», «мораль» һәм «әхлак» сүзләре гадәттә бер үк нәрсәне аңлату өчен кулланылалар.

Моральне кайчак, берьяктан, мәдәният сүзенең синонимы, икенче яктан, рухи даирәне билгеләүдә тагын бер термин буларак файдаланалар. Бу карашларның берсен дә дөрес дип әйтеп булмый. Мораль — ул рухи хәятның бер ягы гына. Мәдәни нормаларның барысы да рухка бәйләнмәгән һәм алар барысы да моральгә генә кайтып калмый. Социаль хәятта рухи тормыш белән бәйләнмәгән күп кенә нормалар бар. Әйтик, гигиена, гимнастика, этикет, акча эшләү һ.б. шундыйлардан. Моннан «мәдәният» төшенчәсе «рухият» төшенчәсеннән киңрәк дигән нәтиҗә чыгарып була.

Кешедә әхлак нормалары тәрбияләү андагы рухиятнең башлангычы дип санйлар. «Мораль» һәм «рухият» төшенчәләре бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә. ***Рухият — кешенең югары кыйммәтләргә — идеалга омтылышын, аның аңлы рәвештә үзүзен камилләштерүгә, үз тормышын идеалга якынайтырга, рухи баерга тырышуы ул.***

Моральнең төп билгеләре:

Әхлакый таләпләрнең ***гомумилеге*** (ягъни әхлакый таләпләр, яшь яисә карт, ир яисә хатын, бай яисә ярлы, католик яисә православие динен тотучы булуына карамастан, һәркемгә кагыла).

Таләпләрне үтәүнең ***ирекле****лег*е (нормаларны үтәү мәҗбүри булган хокуктан аермалы буларак, моральдә таләпләрне үтәү бары кешеләрнең аңлылыгына һәм иҗтимагый фикернең абруйлылыгына гына нигезләнә).

Кыйммәтләр эчтәлекләре ягыннан аерылалар: ләззәт, файда, дан, хакимият, иминлек, матурлык, хакыйкать, шәфкать, бәхет һ.б. Кыйммәтләр уңайга һәм тискәрегә бүленәләр: ләззәт — хәсрәт, файда — зыян, иминлек — хәвеф, матурлык — ямьсезлек, хакыйкать — ялган, шәфкать — явызлык, бәхет — бәхетсезлек һ.б. Кайбер кыйммәтләр — гамәли, ә кайберләре — рухи була.

Төшенчәләр: *мәдәният, кыйммәт, мораль, этика, әхлак.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Сез нинди фундаменталь кыйммәтләрне беләсез? Алар җәмгыятьнең нинди даирәләренә карый?

2. Моральнең төп билгеләрен атагыз һәм аларга кыскача характеристика бирегез.

***3.** Хайваннар дөньясында күп кенә төрләр (арсланнар, агулы еланнар, шулай ук төкле туралар, бал кортлары) шул дәрәҗәдә яхшы коралланганнар, алар арасындагы сугыш кимендә бер хайванның һәлак булуына китерер иде. Шуңа күрә табигать төр эчендәге «көрәштә» корал куллануны тыя — бәхәсләр турнирларда хәл ителә. 50 ел элегрәк австрияле зоолог, Нобель премиясе лауреаты Конрад Лоренц бу күренешкә табигый мораль дигән атама бирә.

Күп кенә төрләрнең үз-үзен тотышын анализлап, ул мораль тыюларның көче корал көченә пропорциональ була, дигән нәтиҗә ясый. Табигать тарафыннан кеше һәм аның борынгы бабалары бик начар коралландырылган була — алар хәтта юньләп тешләшә дә алмаганнар. Шуңа күрә, кешедәге табигый мораль баштан ук зәгыйфь була. Әмма тарихи үсеш барышында кеше Җирдәге иң коралланган төргә әверелә. Сез ничек уйлыйсыз: иҗтимагый моральне ясалма дип әйтеп буламы? Ул табигый моральдән ни белән аерыла? «Мораль тыюларның көче корал көченә пропорциональ», дигән гыйбарәне сез ничек аңлыйсыз?

***4.** «Явызлыкка каршы тормау» һәм «явызлыкка булышу» дигән мораль гамәлләр бер-берсеннән ни белән аерыла?

***5.** Кытай халкының борынгы мәсәлендә аксакалга, хакыйкать юлын күрсәтче, дип, үзен шәкертлеккә алуны сорап бер яшь егет мөрәҗәгать итә.

«— Син алдаша беләсеңме соң?» — дип сораган ди аксакал.— Юк, әлбәттә! — дип җавап биргән егет.— Урлаша да белмисеңме? — Белмим.— Ә җан кыя аласыңмы? — Юк...

— Алай булгач, бар,— дигән остаз, — боларның барысын да эшләп, ни икәнен белеп кара. Белгәч — беркайчан да кылма!»

Этик яктан чыгып караганда, сез бу мәсәлне ничегрәк аңлатыр идегез?

***6.** Күренекле француз философ-экзистенциалисты Ж.П. Сартрның (1944): «Оккупация чорындагыдан да артыграк ирек бездә башка беркайчан да булмады» дигән сүзләрен сез ничек аңлатасыз. 1942 елда чолганышта калган Ленинградта Ольга Берггольц: «В грязи, во мраке, в голоде, в печали, (Баткаклыкта,

караңгылыкта, ачлыкта, хәсрәт эчендә,)/ Где смерть, как тень, тащилась по пятам, (Үлем күләгәдәй артыбыздан ияреп йөргәндә,) / Такими мы счастливыми бывали, такой свободой бурною дышали, (Без бик бәхетле була, шул тикле ирекле сулыш ала идек,)/ Что внуки позавидовали б нам» (Безгә оныкларыбыз кызыгып карарлык)», — дип яза. Әлеге ике гыйбарә арасында нинди бәйләнеш бар?

? Проблема. Ирек «аңлы ихтыяҗ»мы?

§ 13 (§ 34). Әхлак хисләре һәм кешенең моральгә нигезләнеп үз-үзен тотышы.

Әхлаклылык үз хисләреңне тыя белүдән башлана. Хисләрнең барысын да йөгәнләргә кирәк, дигән сүз түгел бу. Әгәр кеше, үз-үзенә зыян китереп, үз гомерен куркыныч астына куеп булса да, уйлап тормыйча берәр сабыйны янгын эченнән коткара, үз-үзен корбан итә, ачлангач берәү белән соңгы телем икмәген бүлешә икән, аның мондый омтылышлары җәмгыятьтә һәрчак хуплау таба. Мондый очракларда кеше ни өчен акылга таянып эш итмичә, хис ташкынына бирелеп, үзенең гомеренә зыян китерердәй гамәлләр кыла? Күрәсең, мондый хисләр йөгәнсезлеге шәхес тарафыннан күптән кабул ителгән, йөрәгендә ныклы урын алган, дөньяга карашының аерылгысыз бер өлешенә әверелгәндер. Мондый адымны кеше аның нәтиҗәләрен һәм килеп туарга мөмкин булган куркынычны аңлаган хәлдә ясый. Киресенчә, ахырдан үзен кызарырга мәҗбүр итә торган, томанлы аң төпкелләреннән күтәрелгән «сукыр» дәрт-омтылышларын кешенең акылы кире кага, алар шәхеснең дөньяга карашына туры килми, әмма, шуңа карамастан, тәэсир көчен югалтмый. Түбән дәртләренең колы дигән дан күтәрергә әзер кешеләр арабызда бик аз очрый. Әгәр кем турында булса да: «Ул үз сүзенә хуҗа, хисләрен йөгәнли белә», — дип сөйләсәләр, ул бер көлтә уңай тойгы-кичерешләр ала, үзенең инану-карашлары дөреслегенә ышанычы арта.

Мораль тыйнаклыкка һәм аскетлыкка, рухи дөньябызның кешеләр тарафыннан *аеруча югары бәяләнә торган яхшылык — зирәк акыл* урнашкан полюсына якынрак тора. Үзендәге куркаклык һәм ризык колы булу, әхлакый тотнаксызлык һәм комсызлык кебек сыйфатларны йөгәнләүчеләр һәрчак абруйлы булган һәм аларны зирәк акыллы затлар дип таныганнар. Әмма кешенең үз йөрәгендәге хисләр муллыгын чикләргә тырышу аның мораль җитешсезлеге булып санала. Әсәр каһарманнары һәм экрандагы геройлар тормышы белән яшәгәндә, мәхәббәт утында янганда яисә якын кешеләребезне кайгыртканда без якты хисләр кичерәбез. Алар күңелне сафландыра, иң нечкә кылларына кагыла. Греклар мондый халәтне *катарсис* (чистарыну, арыну) дип атыйлар.

Мораль бары адәми затка гына хас. Тойгы һәм хисләрдән азат булмасалар да, акыллары булмаганлыктан, хайваннар моральгә ия булмый. Ул бары кешеләрдә генә була. ***Мораль ике капма-каршы башлангычны — явызлыкны һәм игелекне, түбәнлек һәм бөеклекне, акыллылык һәм хислелекне тигезлектә тота.***

Кешенең акылга нигезләнеп, төгәлрәге, *тирәннән фикер йөртеп* ***эш кылуы*** һәрчак уңай күренеш булмый. Җинаятьче салкын канлылык белән корбанын билгели һәм үзенең явыз ниятен тормышка ашыра. Кайчак тирәнтен уйлап, риясызлыгы шикле булган чаралар кулланудан тайчынмыйча хезмәт урынында карьера ясау белән дә очрашырга туры килә. Димәк, акыл да, хисләр дә бердәй яхшы һәм начар, әхлаклы һәм әхлаксыз булырга мөмкин. Этика өлкәсендәге белгечләрнең тикшеренүләре безгә бүген элегрәк билгесез булган нәрсәләрне ачып бирде.

Акыллы гамәлләр бары ихлас хисләргә нигезләнгәндә генә әхлаклы була. Һәм киресенчә. Кешенең хисләре белән акыл идарә итсә генә аның үз-үзен тотышы әхлаклы дип танылa.

Акыл һәм **хис** бер-берсенә бик тыгыз бәйләнгән. Әгәр болар аерылса, кешенең әхлаксызлык упкынына тәгәрәү куркынычы да бар. Алар арасында каршылык туарга тиеш түгел.

Элек-электән ир кешедә — акыл, ә хатын-кызда хис өстенлек итә дип санала. Әгәр болар берсе-икенчесеннән аерылса, алардагы сыйфатлар кырый чиккә килеп җитә, бары аларның берлеге генә гармония һәм тигезлек тудыра. Әмма ул капма-карщы җенесне, аңа хас сыйфатларны бастыруга түгел, бәлки үзара ихтирамлы мөнәсәбәткә нигезләнә. Бер-береңне контрольдә тоту хәтта сизелми дә, ачыктан-ачык та булмый, аны хәтта контроль дип атау да дөрес түгел.

Әхлак бары эчтән — бары кешенең үз-үзен контрольдә тотуы аша һәм бары ирекле рәвештә генә формалаштырыла. Мәҗбүриләп кешедә нечкә хисләр уятып та, аннан дөрес гамәлләр көтеп тә булмый. Кешене мондый гамәлләрне үз теләге белән кылсын өчен кызыксындырырга кирәк.

Моральгә карата «күп», «аз», «бөтенләй юк», «бик аз» дигән категорияләр кулланылмый яки кулланылмый диярлек. Төссез кинодагы кебек, биредә ике полюс бар, яисә син урлашасың (күпме урлавың мөһим түгел), яисә тыелып торасың, ягъни нәфесеңне чиклисең. Әхлак принципларын бер тапкыр бозсаң, түбән тәгәрәсеңне көт тә тор, дигән гыйбарә бар. Тыелган чик аша атлап чыгуы — шәхеснең әхлакый яктан ялгыш юлга керүе ул.

Начар гамәл (җинаять) кылганнан соң шәхеснең бөтенләй икенче кешегә әверелүен психологлар күптән әйтә киләләр. Чынлыкта, тыелган чикне атлап чыгудан бик күп кешеләр тыелып калырга сәләтле. Теләсә кайсы халыкның күпчелеген асылда шәфкатьле һәм әхлаклы кешеләр тәшкил итә. Бөтен хикмәт шунда ки: чын әхлаклы шәхес өчен чик дигән төшенчә бөтенләй юк. Ул бу чиккә хәтта якын да килми. Бу чик аның яшәү рәвешеннән бөтенләй читтә тора.

Шәхеснең *үз-үзен әхлаклы тотуы* очсыз-кырыйсыз лабиринтта адашып йөрүне хәтерләтә. Биредә кешегә һәр адым саен үз-үзе белән компромисска керергә, парадоксларга һәм каршылыкларга очрарга туры килә һәм ул аларны һәрчак уңышлы хәл итә дә алмый. Ике яклы мораль кагыйдәсен генә алыйк: башкаларга карата



без үзебезгә караганда һәрчак артыграк таләпләр куябыз, башкаларга гафу ителмәгән күп нәрсәләрне үзебезгә кичерәбез. Ә әхлак (мораль) законнары абсолют икән, алар кешенең үзе һәм башкалар өчен ничек төрле була ала?

Әхлаклы кеше башкачарак гамәл кыла: ул үзенә башкаларга караганда югарырак таләпләр куя. Мондый кеше үзенә кичерелмәгәннәрнең күбесен башкаларга кичерә. Һәм теге яисә бу гамәлне тирән ышаныч белән генә түгел, бәлки йөрәк кушуы буенча башкара. Әмма башкаларга да, үзенә дә бердәй кырыс мөнәсәбәттә булучылар да бар. Алар үзләренең аеруча принципиаль булуларыннан хәтта рәхәтлек тә кичерәләр. Башкаларга карата ни өчен рәхимсез булулуары турында сорасалар, алар үзләренә карата да таләпчән булуның шундый хокук бирүе һәм үзләренең кырыс, әмма гадел икәнлекләре турында әйтәләр.

Билгеләмәсенә караганда, мораль, 1) акылның аффектлардан өстенлеген; 2) иң яхшыга омтылышны; 3) шәфкатьлелекне һәм мотивларның эчкерсезлеген күздә тота.

Әхлаклы (шәфкатьле) кеше үз-үзен тыя, көчле теләкләрен чикли белә. Әмма бу ни өчен эшләнә соң? Тирә-юньдәге кешеләр белән тату яшәр өченме? Әгәр шулай икән, шәхесләр арасындагы мөнәсәбәтләрне осталарча ничек кирәк алай борып, теләсә нинди катлаулы очракларны булдырмый калучы хәйләкәр заттан ул кайсы ягы белән аерыла? Аның өчен шәфкатьле булу отышлы. Дөрес, аның гамәлләрен башкачарак та аңлатып була: башкаларга юл куюы белән ул үзенең эгоистлыгын, башкалар белән хисаплашмыйча үзенчә эшләү теләген чикли. Ә бу инде әхлакый позиция дигән сүз.

Әхлаклы кеше иң югары яхшылыкка ирешүне максат итә. Әмма иң югары дәрәҗә яхшылык нәрсә ул? Һәм ул ниндирәк югарылыкта тора? Бу очракта югары идеаллар һәм яхшылык чикләре төгәл билгеләнмәгән бер җыелма хәлендә күзаллана һәм аның чикләрен без үзебез тәгаенләргә мәҗбүрбез. Бу очракта без үзебез теләгәнчә һәм үзебезгә ничек кирәк, шулай гамәл кылабаз. Башкачарак әйткәндә, абсолют принципларга без чагыштырмалылык һәм субъективлык төсмере бирәбез. Югары кыйммәтләрне түбән бәяләүләргә кайтарып калдырмыйбызмы икән? Әмма югары идеаллар универсаль һәм абстракт булган саен, алар шуның кадәр күбрәк кеше өчен яраклы була. Димәк шушы юл белән алар максатларына ирешәләр: күпчелек кешенең үз-үзләрен тотышын җайга салуга хезмәт итәләр.

«Җан кыйма!» принцибы барлык мәдәниятләр өчен уртак әхлакый закон булып тора. Әмма нормалар абстрактлыгының икенче ягы да бар — ул кешенең үз-үзен тотышында төрле вариантлар булуны күздә тота. Бер үк принцип бик күп ысуллар белән аңлатылырга мөмкин. Әмма алар оригиналга охшаган булалармы? Шәрехләүдәге вариантлылыкка башкаруда вариантлар күп булу өстәлә. Кешегә «җан кыйма!» дигән күрсәтмә бирелә. Ә кеше исә икеләнеп кала: әгәр ул а) илемнең дошманы, б) менә хәзер генә кеше үтергән, в) намуслы кешене рәнҗеткән икән һ.б. аны ничек үтермисең ди инде? Әгәр «Җан кыйма!» абсолют закон икән, ни өчен югары әхлаклы дворяннар җәмгыятендә дә дуэльләр рөхсәт ителгән булган, аеруча авыр җинаять кылган өчен күп кенә (барысында да булмаса әле!) илләрдә әле күптән түгел генә үлем җәзасы бирелә иде, ә җәмгыятьләрнең барысында да дошманны иң күп кырган сугышчы аеруча абруйлы саналган?

Абстракт әхлак нормаларының парадокслылыгы аларның кемгә дә булса төгәл аталмавыннан тыш, әле субъектив булмавында да. Фәнни теориянең һәм әдәби әсәрнең конкрет авторы була. Ә әхлак нормаларының авторы бармы? Беркемнеке дә булмагач, аларны санга сукмаган өчен кем җәза бирә ала? Әгәр тәгаен иясе юк икән, димәк, әлеге рольне һәркемнең үзенә алу мөмкинлеге бар. Әмма башта әлеге һәркем кылынган гамәлне җәзага тарту кирәкме-юкмы икәненә бәя бирергә хаклы. Ләкин, шулай булгач, Библиядәге: «Башкаларны хөкем итмә, үзеңне дә хөкем итмәсләр», — дигән формуланы ничек аңларга? Әхлакый бәянең парадокслыгы әхлакый хөкемне кем чыгара алуы, әхлакый бәя чыгару хокукы кемгә бирелүе турындагы мәсьәләгә бәйләнгән. Бәлки ул илбашы булырга тиештер? Әмма аңа бит башка өлкәләрдә эш йөртү йөкләнгән, ул сәяси мәсьәләләр буенча хөкем чыгара. Алай булгач, бәя бирүче илдәге иң әхлаклы кеше булырга тиештер. Әмма кем соң ул иң әхлаклы кеше? Бәлки, ул руханидыр? Әмма аңа Аллаһ исеменнән Аллаһ бары үзе генә хәл итә алырдай нәрсәләрне башкару тыелган. Әллә соң сүз берәр изге — рухи камиллекнең иң югары дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше турында барамы икән? Ләкин нәкъ менә шушы дәрәҗәгә ирешкәч, кеше акылы да иң югары ноктасына җитә: иң мөһиме — тыйнаклык һәм буйсыну булуына төшенә.

Философ Сократ Борынгы Грециянең акыл ияләре арасында иң мәшһүре дип танылган. Әмма ул: «Мин бары берни белмәвемне генә

беләм»,— дигән бит. Парадокс менә нәкъ шунда инде, ләкин бу тыштан карагаңда гына шулай. Күбрәк белем туплаган саен кеше чынлап та акыллырак һәм белемлерәк була бара. *Әмма күбрәк белем туплаган саен, кешенең тирәсендә әле ачылмаган билгесез нәрсәләр күбәя. Акылы арта — кеше тыйнаклана, дөресрәге, үзенең камил булмавына ныграк төшенә бара.*

Кешенең әхлак дәрәҗәсе белән аның үзенә мөнәсәбәте тыгыз бәйләнештә була. Димәк, чын әхлаклы кеше үзен кемгә дә булса хөкем чыгарырга хаклы дип санамый.

Тагын бер парадокс килеп чыга: хөкем чыгарырга лаеклылар — баш тарта, ә әхлакый сыйфатлары мактанырлык булмаган башкалар мондый гамәлне исә рәхәтләнеп кыла. Адым саен безгә кисәтүләр ясыйлар, күрсәтмәләр бирәләр, гаеплиләр һ.б. Конвейер туктаусыз хәрәкәттә — трамвайда, урамда, мәктәптә, өйдә, эштә. Ә без һәрберебез гомуми әйләнешнең бер өлеше генә. Һәм шушы вакытта әхлак мәсьәләләрендә остаз һәм хөкемдар ролен бик теләп үз өсләренә алган кешеләрнең әхлаклылык белән бөтенләй ярашмый торган сыйфатлары — үз-үзләреннән үтә дә канәгатьлекләре ачыла. Һәр тумыш көн саен көнкүрештә һәм хезмәт урынында әхлакка бәйле дилеммаларны хәл итәргә туры килгәнлектән, без үзебезне — кайберәүләребез хаклы рәвештә, әлбәттә — мондый эшләрдә шактый яхшы белгеч дип исәплибез. Үзебезне экспертлыкка үзебез үк билгелибез.

Шунысы кызыклы, экспертлык дәрәҗәсе турыдан-туры социаль рангка бәйле: шәхес иҗтимагый иерархиядә никадәр югарырак урын биләсә, шундый ук үҗәтлек белән үзен әхлак мәсьәләләрендә белгеч дип ышандыра. Әмма кеше карьера ясау юлында уңышларга ирешә, югарыга үрли барган саен, аның әхлакка сыймый торган гамәлләре шуның кадәр күбәя бара. Иң әхлаксызлар — хакимияткә ия булган затлар, дип очраклы гына әйтелми. Инануларының бик аз өлешен генә булса да саклап калган кешеләр урта бер җирдә дистанциядән төшәләр. *Иерархиядә һәркем үзенең тәмам әхлаксызлыгы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә* дигән үзенә күрә бер канун формалаштырырга мөмкин. Ул Питерның: *«Идарә итүдә һәркем үзенең компетентсызлыгы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә»*, дигән мәгълүм принцибының тулы аналогиясе булып тора. Моңа алдарак ачыкланган парадоксны да өстик: әхлакый хөкем чыгарырга хаклы кешеләр моны эшләмәячәк, ә хөкем итәргә теләүчеләргә моны ышанып тапшырырга ярамый. Сез ничек уйлыйсыз: алар бер-берсенә каршы килмиме?

Әхлакый камиллеккә омтылу юлына баскан кеше иң беренче эш итеп башкаларны хөкем итүне тыя. Әмма бу әхлакый бәяләмәнең үз-үзеңне бәяләүгә кучүен аңлата. Сез иң беренче нәүбәттә үзегезгә хөкем чыгарасыз. Ләкин әхлакый хөкем тагын нинди булырга мөмкин? Мөгаен, ул башка төрле булырга тиеш тә түгелдер. Юридик хөкемне гомуми закон — Җинаять кодексы исеменнән бер кеше икенче кешегә чыгара. Кешенең башкалар алдында закон буенча җавапка тартыла торган гамәле җинаять була; шул ук гамәл, әгәр кеше аның өчен үз вөҗданы алдында җавап тотса, гөнаһка әйләнә. Явызлык яисә гөнаһ — әхлакый законны бозу ул. Фәнни танып-белүдән аермалы буларак, әхлакый танып-белү өлкәсендә экспериментлар уздырып булмый. Әйтик, сез башкалар эшенә һичкайчан тыкшынмауны үзегез өчен яхшы, дип саныйсыз ди. Әмма әлеге фикернең хаклыгын ничегрәк тикшерергә соң? Үз өстеңдә экспериментлар ясаргамы, әллә башкалар өстендәме? Башкалар өстендә экспериментлар ясаганда, кешеләр аларның хаталарын кабатламаска өйрәнәләр. Бу акыллы принципны беребез дә кире какмый. Дөрестән дә, үзеңә хаталану һич шарт түгел, читләрнең ялгышыннан гыйбрәт алырга кирәк. Шулай икәнен аңлап та, үзебез әлеге принципны үтәмибез. Нигә икән? Мөгаен, сәбәп читләр тәҗрибәсенең безгә яраксызлыгындадыр. Кеше үз тәҗрибәсенә таянырга тиеш. Ятларның хаталарын без абстракт күзлектән карап, экспериментта катнашмыйча гына өйрәнәбез. Аларны хәл итү алгоритмын теләсә нинди кыен хәлдә үзеннән-үзе ярдәмгә килерлек итеп ныклы үзләштерә алмыйбыз. Галимнең ялгыш теорияне тикшереп ясаган нәтиҗәләреннән дөньяның барлык фән кешеләре файдалана бит. Әмма сез әхлакый кагыйдәне тикшерәсез икән, эксперимент нәтиҗәсе бары сезнең өчен генә яраклы була, анысы да әле һәрчак түгел.

Мораль лабиринт, үз-үзеңә әхлакый аттестация уздыру белән тыгыз бәйләнгән мораль бәяләмә парадоксы һәм әхлакый тәртип парадоксы дигән ике яңа шарт кертелгәч, тагын да чуала.

Димәк, ***әхлак — кешеләргә йөкләтелгән һәм алар тарафыннан кабул ителгән үзара йөкләмәләр системасы ул. Бу йөкләмәләр конкрет шартларда һичшиксез үтәлә торган билгеле бер яшәеш бурычлары буларак аңланалар.***

Төшенчәләр: *әхлак, мораль, әхлаклылык.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Әхлаклы шәхестә акыл һәм хис ничек яраша?

2. Әхлаклылыкның критерийларын билгеләгез.

3. Хәзерге җәмгыятьнең нинди әхлакый нормаларын атый аласыз?

4. «Башкаларны хөкем итмә, үзенне дә хөкем итмәсләр», — дигән әхлакый кагыйдә бар. Башка кешене мактаган очракта бу кагыйдәнең гамәле ниндирәк булыр икән? Яңа формула төзегез һәм аңа аңлатма бирегез.

***5.** «Әхлак кешегә гомум кешелек исеменнән мөрәҗәгать итә», — дигән гыйбарәнең мәгънәсен аңлатыгыз.

***6.** Әхлаклылык парадоксын Борынгы Рим шагыйре Овидий: *«Яхшыны күрсәм, мактыйм, начарлыкка тартылам»,* — дип сурәтләгән. Бу ни дигән сүз?

*** 7.** Евангелиедәге: «Аларны җимешләреннән таныырсыз», — дигән кагыйдә нәрсәне аңлата?

? Проблема. Әхлаксыз җәмгыятьтә, коллективта әхлаклы булып калу мөмкинме һәм бу кирәкме?

Практикум. Апостол Павел «Галатларга юллама»сында әхлакка дини караш асылын түбәндәгечә билгели: «*Чөнки бөтен закон бер сүзгә сыеп беткән: Якыныңны үз-үзеңне яраткан кебек ярат! Әгәр бер-берегезне чәйнәшәсез һәм ашыйсыз икән, бер-берегезне кырып бетерүдән сакланыгыз... Сезгә әйтәм: җаныгыз кушканча гамәл кылыгыз, шуннан соң бәдәнегез таләп иткәннәрне үтәүдән азат булырсыз, чөнки җан — бәдәнгә, ә бәдән — җанга каршы тели: алар бер-берсе белән тарткалаша, шуңа да сез үз теләгәнегезне түгел, бөтенләй башканы эшлисез. Әгәр сез җаныгыз белән тату икән, сезгә закон кагылмый. Бәдәннең эшләре мәгълүм инде; аларның асылы: азгынлык, нәҗеслек, яраксызлык, потка табыну, тылсым, дошманлык, кычкырышу, көнчелек, ярсу, ызгыш, каршылыклар (алдап кызыктыру), илаһны танымау, нәфрәт, җан кыю, эчкечелек, башбаштаклык һәм шуның ишеләр; сезне элеккечә үк кисәтәм: болай яшәүчеләр Аллаһы хозурыннан мәхрүм калачак. Рух (җан) җимеше исә: сөю, шатлык, тынычлык, сабырлык, шәфкать, иман, юашлык, тыелганнардан тыелу. Тәкәббер булмыйк, бер-беребезнең ачуын кайнатмыйк, хөсетле булмыйк». (Галат. 5:14–26).*

Әлеге вәгазьнең бүгенге көндә актуальлеге турында фикерләрегезне белдерегез.

§ 14 (§ 35). Әхлакый категорияләр һәм игелек

Әхлакый категорияләр күптөрле була. Аларга: ***а) әхлакый нормаларны, б) әхлакый кыйммәтләрне, в) әхлак сыйфатларын, г) әхлакый принципларны, д) әхлакый идеалларны характерлый торган төшенчәләр керә.***

Әхлакый категорияләр уңайга һәм тискәрегә бүленәләр. Менә аларның кайберләре генә. Гуманлылык, эчкерсезлек, ватанпәрвәрлек (патриотлык), сизгерлек, ярдәмчеллек, эшсөярлек, намус, шәфкать, тугрылык, яхшылык теләү, батырлык, үзара ярдәмләшү, бурыч, җаваплылык, абруй, гаделлек, аңлылык, принципиальлек, максатчанлык, эшкә тугрылык, кыюлык, пөхтәлек, тыйнаклык, үз-үзеңне хөрмәт итү, мөлаемлек, әдәплелек, сакчыллык, киң күңеллелек, битарафлык, җавапсызлык, рәхимсезлек, принципсызлык, яраклашучанлык, саранлык, эгоистлык, үз-үзең турында югары фикердә булу, тәкәбберлек, көнчелек, куркаклык, җыйнаксызлык, әрсезлек, тупаслык, икейөзлелек, сабырлык, риясызлык, тугрылык, оялчанлык, горурлык, килешмәүчәнлек, явызлык, шәфкатьлелек, намуслылык, оят һ.б.

Этик мәгънәсендә **идеал** берникадәр универсиаль, ягъни шартларга, затларга, шәхси зәвыкъларга карап үзгәрми торган *стандартны* күздә тота. Кешенең әхлак дөньясы — әхлак категорияләрендә гәүдәләндерелгән кыйммәтләр дөньясы ул.

Яхшылык һәм явызлык. Әхлакый аңның үзәк төшенчәләре — яхшылык һәм явызлык традицион рәвештә *төп әхлак категорияләре* дип танылалар. Беренчесенә — уңайлыгы шик тудырмый торган, гомум җәмгыять яисә аерым бер зат аларны үти торган, ә икенчесенә исә бөтенләе белән тискәре сыйфатлар керә. Кешеләрнең яхшылык һәм явызлык, бурыч һәм намус турындагы күзаллаулары төрле сыйныфлар, катлаулар, сәяси режимнар, чаралар һәм төрле диннәр мәнфәгатьләренә карап тарихи үзгәреш кичергәннәр.

Борынгы чорда ук *яхшылык һәм явызлыкның гаять тыгыз бәйләнештә булуы* идеясе турында бик тирән фикерләр әйтелгән. Борынгы акыл ияләренең берсе: *явызлыкның ни икәнен белмәгән һәм үзе татымаган кеше чын-чынлап шәфкатьле була алмый*, дигән.

Явызлыкка каршылык күрсәтергә әзер булмыйча торып,

явызлыкның ни икәнен һәм аңа каршылык күрсәтергә кирәклеген аңлап булмый. Бу үзе генә яхшылыкка китермәячәк. Яхшылык чынлыкта явызлык кире кагылганда гына ныгый.

Игелек һәм әхлаксызлык. *Игелек — тискәре сыйфатлар һәм гамәлләр җыелмасы булган әхлаксызлыктан аермалы буларак, кешенең бары уңай сыйфатлары һәм гамәлләре тупланмасын гәүдәләндерүче әхлакый категория.* Этика төшенчәләрен чагыштырыйк: яхшылык һәм явызлык, игелек һәм әхлаксызлык. Болар ни белән аерыла? Яхшылык һәм явызлык кеше өчен файдалы яисә зарарлы дигән абстракт төшенчәләрне чагылдыралар, алар абсолют булалар һәм кешеләрнең берсе дә аларга ия булмый. Игелек — конкрет кешенең йә холкында, йә гамәлләрендә яхшылык принципларының чагылышы ул. Начарлык та нәкъ шулай кешенең сыйфатлары һәм гамәлләре җыелмасы булып тора. Дөрес, игелек һәм әхлаксызлыкны кайбер әхлакый кагыйдәләрне чагылдыручы әхлакый кыйммәтләр (яхшылык һәм явызлык кебек) буларак киңрәк мәгънәсендә аңлату да бар. Гаделлек, юмартлык, киң күңеллелек, кеше хәленә керү һ.б. — болар игелек, ә ялганчылык, саранлык, вакчыллык, каты күңеллелек һ.б. — начар гамәлләр булып тора.

Чынлыкта игелек абстракт түгел, аңа дәвамлы яхшы гамәлләр кылу нәтиҗәсендә ирешелә. Кеше гадел, акыллы гамәлләр кылса, аның турында — «акыллы», батыр һәм тәвәккәл эш итсә, «гайрәтле» диләр. Игелекнең ни икәнен аңласа да, кеше чынлап игелекле гамәлләр кылмаска мөмкин.

«Игелек» сүзе *ике мәгънәдә* кулланыла. Беренче мәгънәсендә ул — ***кешегә хас сыйфат***, ә икенчесендә — ***кеше холкының*** гомумиләштерелгән күрсәткече. Чынлап та, холкы ягыннан кеше йә әхлаклы (игелекле), йә әхлаксыз (бозык) була.

Әгәр яхшылык төшенчәсе берлек санда кулланылса, игелек исә күпсанлы мәгънәләрне берләштерә, бу очракта ул шәхеснең конкрет әхлакый сыйфатларын аңлата. Бу очракта кешенең уңай сыйфатлары күп булуы турында сөйлиләр: ул бик төгәл, аек тормыш рәвеше алып бара, тирән фикерле, гадел (кыерсытылганнарны яклый), шәфкатьле (мохтаҗларга һәм ятимнәргә ярдәм күрсәтә), гайрәтле һәм намуслы. Әмма кешедә әхлаксызлык (начар сыйфатлар) та күп булырга мөмкин: ул еш кына исерек, шапшак була, сүзен үлчәп сөйләми һәм әйләнә-тирәдәгеләргә карата тупас мөгамәлә күрсәтә, вәгъдәсез, үчле һәм тәкәббер, һавалы була.

Антик чорда ук инде философлар кешедәге игелеклелек сыйфатларын исәпкә алып, аларны системага салу турында уйланганнар. Борынгы Грециядә яшәгән мәшһүр философ ***Аристотель*** (б.э.к. 384–382 еллар) беренчеләрдән булып кешенең аларны төрләргә бүлүне тәкъдим итә. Ул акылга һәм әхлакка нигезләнгән, икенче төрлерәк әйткәндә, *акыл* һәм *холык* сыйфатларын (игелек) аерып күрсәтә. Беренчеләре кешене өйрәтү, тәрбияләү нәтиҗәсе булалар. Мондыйларга *акыллылык, зирәклек, тиз* һәм *дөрес фикер йөртү* кебек сыйфатлар кирә. Икенчеләре кешенең гадәтләреннән, табигатеннән килеп чыга: кеше эшли, тәҗрибә туплый, шуның нигезендә аның холкы формалаша. Аристотель уңай һәм тискәре сыйфатларның теоретик схемасын төзи. Биредә игелек (уңай сыйфат) ике кырый чикләр арасындагы алтын урталыкны тәшкил итә. Мәсәлән, хәвефкә мөнәсәбәтле рәвештә *гайрәт* батырлык һәм куркаклык арасында урталыкта тора. *Акыллылык* — хисләрнең йөгәнсезлеге һәм салкынлыгы, *юмартлык* — исрафчыллык белән саранлык, *гаделлек* — мактанчыклык белән ихлассызлык, *тапкырлык* — шамакайлык белән дорфалык, *дустанә мөнәсәбәт* — ялагайлык һәм ярарга тырышу, *оялчанлык* — оятсызлык белән кыюсызлык арасында тора һ.б. Аристотель игелек турындагы мәгълүматны практик игелекле гамәлләр белән тыгыз бәйләнешкә куеп карый. Аның тәгълиматы буенча, әгәр кеше бер нәрсәне белеп, икенче төрле гамәл кылса, димәк, аның ия булганы белем түгел, караш кына, һәм аңа практик эшчәнлектә кулланыла алырлык чын белемгә ирешергә кирәк.

Игелек парадоксын белем белән гамәл арасындагы өзеклек тәшкил итә: мәктәп тәрбиясе, белем алу, китаплар уку, матбугат һәм телевидение йогынтысында хәзерге җәмгыятьтә кешеләр, гомумән алганда, игелекнең ни икәненнән хәбәрдар, эмма күпләр (ә кайчакта — күпчелек) бозыклыклар кылалар. Бу нәрсә? Практикада гамәлгә ашырып булмый торган абстракт белемнәрме яисә кешенең үз-үзен тотуындагы кайбер үзенчәлекләрме? Мөгаен, икенчеседер. Без кешеләрдән игелек таләп итәбез һәм аларның намуссызлыгы, аеруча бу үзебезгә кагылганда, ачуыбызны кабарта. Әмма эш үзебезгә килеп терәлгәч, без дөрес гамәл кылмыйча, үзебезгә рәхәтлек китерүче гамәлгә өстенлек бирәбез. Игелек кылуны башкалардан таләп итеп, без йөрәгебезгә хуш килгәне белән тиешле гамәлнең кайсысына өстенлек бирү кебек кыен мәсьәләдән читләшәбез, тормышыбызны җиңеләйтеп, җанның даими эшләргә тиешлеген онытып җибәрәбез. Кеше рухының урталай бүленүе, шәхестәге килешмәүчәнлек — каршылыклар һәм рухи кануннарның — игелек хакындагы белемнәрнең җисми теләк-омтылышлар белән бәрелешүе ул.

Кешенең уңай сыйфатлары арасында бурыч аеруча мөһим урын тота. ***Бурыч ул — шәхеснең әхлакый идеал куйган таләпләрне һәм шуның нәтиҗәләрен һичшиксез үтәргә тиешлеген аңлавы***. Психологик яктан бурыч билгеле бер гамәлләрне кылу зарурлыгы буларак аңлана.

Оят. Үтәлмәгән бурыч кешедә оят хисе тудыра. Бу — тагын бер әхлакый категория. ***Оят — а) эчке контроль механизмы, б) кеше тарафыннан үз-үзенең кабул ителгән нормаларга һәм әйләнәтирәдәгеләр үзеннән көткәннәргә туры килмәвен төшенүе***, димәк, гаеплелек хисе туу. Оят тулысынча нормаларның бозылуына бәйле рәвештә гаепләү белдерүче башка затлар фикеренә бәйле, һәм кеше өчен бу затлар никадәр абруйлы булса, оят хисе дә шуның кадәр көчле була. Шуның өчен дә шәхес гамәлләренең очраклы, көтелмәгән нәтиҗәләре өчен дә, үзенә гадәти булып тоелганнары өчен дә, әгәр аларны башкалар гаеп итеп саный икән, оят хисе кичерергә мөмкин.

Вөҗдан. Оят хисе белән «вөҗдан» дигән категория бик тыгыз бәйләнгән. ***Вөҗдан ул — кешенең үз гамәлләренә, уйларына, теләкләренә критик бәя биреп, үзенең тиешле критерийларга туры килмәвен — бурычын үти алмавын аңлау сәләте һәм шуны***

авыр кичерүе. Вөҗдан тирә-юньдәгеләр фикеренә бәйле түгел. Б.э.к. V гасыр ахыры IV гасыр башында ук борынгы грек философы Демокрит: «Хәтта ялгыз калганда да оят гамәл кылма, үз-үзеңнән башкалардан да артыграк оялырга өйрән», — дип киңәш биргән. Бу ни дигән сүз? Вөҗдан синнән башкалар сине күзәтмәгәндә дә намуслы булуны таләп итә. Субъектив рәвештә ул кешенең калебендәге ят бер аваз, «башка мин» авазы буларак кабул ителергә мөмкин. Шушыннан вөҗданның асылы турындагы капма-каршы ике нәтиҗә килеп чыга. Берәүләр вөҗданны — Аллаһы авазы, ә башкалар абруйлы затларның эчке планга күчерелгән гомумиләштерелгән авазы дип карыйлар. Ике очракта да вөҗдан оятның аерым бер рәвеше буларак карала.

Вөҗдан иҗтимагый тормышта катнашу һәм тәрбия барышында, балага туктаусыз «ак белән караны» аңлату, күрсәтү аша формалаша. Шәхес үсешенең башлангыч чорында вөҗдан абруйлы тирәлек (референт төркем) — ата-аналар, тәрбиячеләр, яшьтәшләр «авазы», аларның боеруы буларак чагылыш таба, һәм шуңа бәйле рәвештә, алар тарафыннан гаепләү, шелтә белдерү, җәза бирү мөмкинлегендә, шулай ук үз гамәлләре өчен оят хисе кичерүдә күренә. Без үзебезгә очраклы рәвештә уңайсызлык китергән кешене: «Сезгә ничек оят түгел?», — дип ачуланабыз. Моның белән нәрсәгә ирешергә телибез? Гаепле кешенең вөҗданына мөрәҗәгать итеп, кылганнары өчен оят хисе кичерергә, аның күңеле түрендәге принциплар запасын уятырга тырышабыз.

Вөҗдан — кешенең үз-үзе алдындагы җаваплылыгы ул.

Вөҗдан газабы кичергәндә үз-үзенә нәфрәтләнүдән тыш, кеше хаталарын төзәтергә, начар гамәле өчен җавап тотарга әзер була. Вөҗдан газабы шәхеснең төзәлә башлавын, әхлакый камиллеккә таба тәүге адым ясавын күрсәтә, чөнки үз-үзеңне гаепләү тәүбәгә килүне, кылганнарың өчен кайгыруны, башка мондый адымга бармаячагыңны аңлата. «Вөҗдан газабы» төшенчәсенең асылы үз гаебеңне тануда ачыла.

Ирек. Вөҗдан газабыннан тыш әле тагын **«вөҗдан иреге»** дигән гыйбарә дә очрый. Ул ***кешенең эчке рухи тормышы бәйсезлегенә хокукын һәм үз инануларын үзе билгеләү мөмкинлеген аңлата***; тар-рак һәм ешрак кулланыла торган мәгънәсендә «вөҗдан иреге» дин тоту һәм дини йолаларны күмәк оешкан төстә үтәү ирегеН белдерә.

Ирек берничә мәгънәгә ия. Юридик ирек — үзенә-үзен хужа булу, сак астында булмау. Сәяси ирек сүз, җыелышлар, матбугат, дин тоту хокукын һ.б. чагылдыра. Фәлсәфи ирек — ихтыяр, гамәл һәм кешенең үз-үзен тотышында ирекле булуы.

Иң гомуми мәгънәсендә ***ирек — басымнан һәм чикләүләрдән азат булу*** дигән сүз. В.Даль сүзлегендә бу сүзнең эчтәлеге түбәндәгечә аңлатыла: «ирек» — азатлык ул. Әмма бу сүзләр синоним түгел. Ирек басымның булмавын, ә азатлык — коллыктан, крепостнойлыктан, ирексезлектән, көч кулланудан азат булуны аңлата.

Кешенең иреге **сайлау ирегендә** чагылыш таба. Әйтик, кеше төрмәгә ябылган яисә тоталитар җәмгыятьтә яши икән, сәяси ирек турында берниндидә сүз булуы мөмкин түгел. Аның сайлау хокукын, шуның белән бергә ирегенн дә кемдер бик катгый тыя. Әмма төрмә диварлары һәм сәяси басым булмаганда да кешенең ирегенн, мәсәлән, обывательлек стереотиплары, ялган күзаллаулар, милли хорафатлар, бозыклыкка омтылу чикләргә мөмкин. Бер егет икенче бер милләт яисә икенче бер сыйныф вәкиле булган кызга өйләнергә тели ди, ә туганнары һәм танышлары аңа: ул сиңа тиң түгел, бәхетсез булачаксыз, дип тукый. Гәрчә егеткә берәү дә сәяси басым ясамаса да, аның сайлау ирегенн чикләнә. Ирек анлы сайлау һәм кешенең үз ихтыяры белән бәйле. Кеше үз сайлаганы өчен үзе җаваплы була.

Шәфкатьлелек. ***Башка берәүгә карата кайгыртучан, хәерхаһлы, мәрхәмәтле, яратып мөнәсәбәт күрсәтү, һәрбер мохтаҗга ярдәм итәргә тырышу шәфкатьлелек була.*** Борынгы Грециядә ул — хаксыз кыерсытылганнарга карата туган хисне, ә Борынгы Һиндстанда якын кешеләреңне яратуны аңлаткан. Күп кенә мәдәниятләрдә шәфкатьлелек һәм мәрхәмәтлелек кешелек мотивларына кертеп карала һәм файда алу, дан-шөһрәт казану омтылышына каршы куела. XIX гасыр рус философы В.С.Соловьев карашынча, шәфкатьле кеше — үзе өчен кешеләрдән нәрсә өмет итсә, аларга да шуны ук эшләүче ул.

Шәфкатьлелек һәм гаделлек (аның турында җентекләп алга таба сөйләрбез) әхлакый тәҗрибәнең төрле даирәсенә һәм дәрәҗәсенә караган фундаменталь уңай сыйфатлар (игелекләр) булып тора. Беренче, түбәнрәк баскычта тирән әхлаклы булырга омтылучы кеше гаделлек принцибын үти, ягъни кешеләргә яхшы һәм начар гамәлләренә карап мөнәсәбәт күрсәтә, башка кешеләр хокукларына кагылмыйча,

үз хокукларын яклый. Икенче, югарырак дәрәҗәдә аның кешеләргә мөнәсәбәте үзен түгел, башкаларны ярату («Үз-үзеңне яраткан кебек, тирә-юньдәгеләрне ярат») кануннарына нигезләнә. Хәсрәт чигүчеләргә ярдәм итү — аларны ярату, шәфкатьлелек күрсәтү дигән сүз ул. *Тирә-юньдәге кешеләр хакына үз шәхси мәнфәгатьләреңнән баш тартырга әзер тору шәфкатьлелек була инде:* «Алмашка ни алачагыңа алдан исәп тотмыйча гына башкаларга бир!». Шулай итеп, шәфкатьлелек әхлакның — иң югары, ә гаделлек — иң башлангыч принцибы булып тора. Икенчесе беренчесе булуны күздә тота. Гадел булу шәфкатьле булуга караганда җиңелрәк, шуңа күрә шәфкатьле кешеләргә караганда гадел кешеләр күбрәк. Шәфкатьлелек — кешегә әхлакый таләп, әмма ул үзе башкалардан гаделлектән арыны күтә алмый.

Төшенчәләр: *әхлакый категорияләр, игелек, яхшылык, явызлык, бурыч, оят, вөҗдан, ирек, шәфкатьлелек.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Уңай һәм тискәре әхлак категорияләрен санап чыгыгыз.

2. Түбәндәге өзекне укып чыгып, аңлатма бирегез:

«Әхлак күзелегеннән караганда, явызлык китергән зыян яхшылык китергән файдадан артыграк булып чыга. Әхлакый яктан гаделсезлеккә юл куймау изге гамәлләр кылуга караганда мөһимрәк булып чыга: җәмгыять өчен гаделсезлектән туган явызлыкның җимергеч көче шәфкатьлелек китергән яхшылыктан артыграк». (*Гусейнов А.А.* , *Апресян Р.Г.* Этика: Дәреслек. М, 1998. 250 б.).

3. Оят һәм вөждан арасындагы уртаклык һәм аерымлык нидә чагыла?

4. Игелек — яхшылыктан, ә явызлык бозыклыктан ни белән аерыла?

***5.** Сезнең карашкача, сайлау мөмкинлегенең ике төре арасындагы аерма нидән гыйбарәт: а) яхшылык белән явызлыкның икесенең берсен сайлау; б) зур һәм артык зур булмаган яхшылык яисә зур һәм артык зур булмаган явызлыкның берәрсен сайлау мөмкинлеге?

***6.** Әгәр бар кешеләр шәфкатьлегә әйләнсә, явызлык юкка чыгармы?
***7.** Түбәндәге төшенчәләрне чагыштырыгыз:
- әдәплелек, инсафлылык;
- яхшы күңеллелек;
- игелеклелек;
- яхшылык.
Алар ни белән аерыла?
* **8.** Яхшылыктан һәм явызлыктан «читкә чыгу» мөмкинме?

? Проблема. Яхшылык йодрыклы булырга тиешме? Шул турыда фикер йөртегез.

✍ **Практикум 1.** Яхшылык һәрчак кешеләргә генә бәйлеме? Яхшы гамәл кылу өчен теләк кенә җитәме?

✍ **Практикум 2.** Төркемнәрдә эшләү өчен бирем. Теләсә кайсы мәгълүм әдәби геройның уңай һәм тискәре сыйфатлары исемлеген төзегез һәм аның үз-үзен тотышын анализлагыз.

§ 15 (§ 36). Бәхет, ләззәт, гедонизм

Кайбер галимнәр әхлак турындагы фәнне «кеше бәхете нәрсә ул һәм аңа ничек ирешергә мөмкин» дигән сорауга җавап эзләү һәм шул турыда фикер алышулар нигезендә туган дип исәплиләр. Гадәттә бу философның гади кеше белән бәхәсе — акыл ияләренең һәм кара халык вәкилләренең бәхетне ничегрәк аңлавын каршы кую аша ачыкланган. Гади кеше югары дәрәҗәгә җиткән шатлыкны, теләгәнеңне булдырудан барлыкка килгән рәхәтлек хисен, максатка ирешүдән туган куанычны, канәгатьлекне бәхет дип атый. ***Һәр кешенең теләк һәм максатлары төрле булганлыктан, бәхет тә төрлечә аңлана.*** Берәүләр аны — данга ирешүдә, яки сөйгәненең җылы карашында, икенчеләре исә байлык туплауда һәм тыныч тормышта күрә. Әмма теләкләр ничек кенә бер-берсеннән аерылмасын, аларның рәвеше бер үк төрле — аларны күреп, тотып карап була,

ул — конкрет. Ни өчен бәхет абстракт булмый? Хыялыгызны эшкә җигеп абстракт бәхетне күз алдыгызга китереп карагыз. Иманым камил, ул мизгел эчендә икенчерәк әйбергә күчә дә куя. Бу бәхет түгел, әйтик, тулысынча тынычлану халәте. Мөгаен, абстракт бәхет юктыр, ул һәрчак конкрет буладыр. Алай гына да түгел, ул һәрчак кемгә булса да аталган, бик үзенчәлекле һәм тирәнтен шәхси була. Бәхет турында сөйләгәндә, кешеләр иң беренче нәүбәттә шәхси бәхетләрен күздә тоталар, ә ул исә һәркемнең үзенеке. Әгәр шулай икән, бу төшенчәнең әхлакка ни кагылышы бар? Барлык әхлак нормалары, идеаллары һәм кыйммәтләре универсиаль, ягъни барлык кешеләр өчен бердәй бит.

Акыллы философлар бәхет турындагы гадәти күзаллауларны ялгыш дип күрсәтәләр һәм ул әхлак категориясе буларак — шәхси бәхет турында түгел, бәлки иҗтимагый бәхет турында сүз алып барылганда гына мөмкин дип саныйлар. Үзең генә бәхетле булу җиңел, дип фикер йөртә Л.Н.Толстой, әмма таныш булмаган кешене бәхетле итү бик авыр. Ә бит авырлыклар чигеп максатка омтылу аша бара ул әхлакый камилләшү. ***Чын әхлаклы кеше башкалар бәхете белән, үз иленең бәхеткә ирешүе белән бәхетле.*** Әгәр юк икән, аның җаны тыныч була алмый. Бәлки абстракт бәхет бардыр ул?

Борынгы грекларда «бәхет» сүзе — «эвдемония» — сүзгә сүз тәрҗемә иткәндә, илаһи көчләр канат астындагы кешенең язмышын аңлаткан. Аристотель заманында гына (б.э.к. IV гасыр) ул югары дәрәҗәдәге уңайлыкларга, рәхәтлекләргә ирешү дигәнне аңлата башлаган. Баштарак бәхетле булуны өстен көчләр мәрхәмәте астында, уңышлы, язмышлы (өлешле) булу дип аңлаганнар. Бәхет — *уңыш, бәхетле очрак, җай килү ул.* Димәк ки, бәхет — кешедән тормый торган бер нәрсә.

Әгәр ул «ишелеп төшсә» генә мираска калган байлыкны уңыш дип атап була. Әгәр сез аңа алдан ук исәп тоткансыз икән, биредә уңышлы очрак турында сүз алып бару урынсыз. Бәхетне көтеп тә, исәпләп тә китереп булмый, ул — могҗиза кебек. Ул сезнең тырышлыкларыгызга һәм хезмәтләрегезгә дә карап тормыйча килә, шулай булмаса, бәхет түгел, ә лаеклы бүләк була ул. Алайса, кешеләр ни өчен үз хезмәтләре, тырышлыклары нәтиҗәсендә нәрсәгә дә булса ирешкән очракта аеруча бәхетле булалар. Күбрәк тырышлык һәм хезмәт куелган саен, бәхет хисе дә шунын кадәр көчлерәк була.

Кеше үз тырышлыгы нәтиҗәсендә ирешкән нәрсәләрне бәхет дип атыйлар. Бәхетсезлекләр исә, кайгы-хәсрәтме ул, сызлану-газапмы, аның теләгенә каршы төшеп килә. Бәхет очраклылык һәм уңыш белән генә чикләнми. «Бәхет елмаюы» яисә җай чыгу асылда бәхет була алмый. Кеше аңының бер почмагында: ничек килсә, шулай китәргә дә мөмкин, дигән курку яши. Һәм бер ни кылыр хәл юк. Зарланып та булмый, ул бит хезмәт итеп табылмаган. Ул — бары җай чыгу, бүләк ителгән нәрсә генә. Шулай булырга тиеш тә. Язмышның очраклы бүләгенә кеше нигә аеруча куана соң? Бәлки, ул аныкы булмаган өчендер? Яисә тиешсез бирелгәнгәдер? Һәм аны югалту, табу кебек үк, гадел эштер? Байлык үзеннән-үзе кешене бәхетле итми, хак юл белән эшләп табылганы гына бәхетле итә. Муллыктан һәм байлыктан баш тартмыйлар, чөнки мохтаҗлыкта бәхет кешене читләтеп үтә.

Бәхетне гомумән тормыштан даими һәм тулысынча канәгать булу дип карарга мөмкин. Тик бәхетнең ни икәнен тирәнтен аңлау өчен бәхетсезлекне татып карау кирәк икән. Бары хәсрәт, кайгы кичергәч кенә, кеше үз өлешенә тигән бәхетнең кадерен белә башлый. Бер төркем яшьләргә дөньяда борчылу-сагыш юкка чыкса ни буласын күз алдына китерергә һәм үз фикерләрен әйтергә тәкъдим итәләр. Алар бер авыздан диярлек: бу дөнья күңелсез, сөюсез, гаиләләрсез һәм дусларсыз булачак, дип җавап бирәләр.

Шулай итеп, яхшылык һәм явызлык, бәхет һәм бәхетсезлек парлы категорияләр булудан тыш, алар бергә бәйләнгән, аерылгысыз да булырга тиешләр. Аларның чиратлашуы гына һәрберсенең бәясен аңлауга китерәчәк. Кешенең эшләре даими җай гына барса яисә ул үзен һәрчак яхшы хис итсә, ул хәвефләнә башлый: бередә нинди дә булса бер хикмәт бар, болай була алмый.

Бәхет һәм бәхетсезлек һәркемгә килә. Берәү дә хатадан, авырулардан, дошманнардан хали (азат) түгел яисә ул кайчан да булса якыннарын югалтачак — бу котылгысыз. Болар барысы да кешене бәхетсез итәчәк. XIX гасырда Бөекбританиядә «утилитаризм» дип аталган (лат. utilitas — файда дигән сүз) философик юнәлеш барлыкка килә. Аның вәкилләре файданы әхлакның нигезе һәм кеше гамәлләренең критерие дип исәплиләр. Утилитаристик этикада кешенең төп әхлакый максаты — мөмкин кадәр күбрәк кешенең мөмкин булганча зуррак бәхеткә ирешүе дип игълан ителә һәм шул рәвешчә бары үз

бурычын үтәү, ягъни игелекле булуы аша гына кешенең чын-чынлап бәхетле була алуы күздә тотыла. Әмма җәмгыятьтә бар кеше берьюлы бәхетле була алмый. *Берәүләр бәхетле булганда икенче берәүләр һәрчак бәхетсез булалар.* Бәхет парадоксы нәкъ менә шунда, дип белдерәләр галимнәр. А.А.Гусейнов һәм Г.Г.Апресян, мәсәлән, *бәхет турындагы ике караш — бер яктан шәхси уңайлыкларга ия булудан туган рәхәтлек һәм канәгатьлек, икенче яктан, игелек кылудан канәгатьлек хисе кичерү — нәкъ менә шушында берләшә* дип санныйлар. Кешенең аерым бер эшчәнлеге максаты яисә тормышындагы берәр бурыч буларак бәхет чынлап та юк. Бер кеше бәхетле булырга тели, аңа омтыла. Әмма бу бәхет эшчәнлекнең әхлакый нигезенә әверелергә тиеш дигән сүз түгел. Ләззәт, тынычлык, муллык, байлык яисә дан артыннан куып кына бәхет табып булмый. Бәхет билгеле бер яшәеш рәвеше — игелекле тормыш нәтиҗәсе булып торадыр.

Бәхет һәм рәхәтлек — кеше күңеленең үзара бәйләнгән ике халәте ул. Әмма рәхәтлек игелеккә һәм әхлак нормаларына керәме?

РӘХӘТЛЕК (ләззәт) — хаҗәтләрне һәм мәнфәгатьләрне канәгатьләндерүдән барлыкка килгән хис-тойгы.

Этикада мондый позиция **гедонизм** (грекчадан hedone — ләззәт) дип атала. Карашлар системасы һәм тормыш рәвеше буларак гедонизмның нигезендә ләззәткә омтылыш һәм хәсрәттән качу кеше гамәлләренең төп мәгънәсен, бәхетнең чын нигезен тәшкил итә дигән күзаллау ята. Гедонизмны ләззәтнең этикасы дип атыйлар. Гедонизм логикасына караганда, әйләнә-тирә мохиттагы һәр нәрсә ләззәт өчен яратылган. **Гедонизм «әхлагын» гади итеп кенә ни барысы ике сүз белән әйтеп биреп була: ләззәт рәхәтлек бирә.**

Гедонизмның этик эчтәлеге ике принципта чагылыш таба: 1) «Ләззәт — тормышның максаты, һәм ләззәтле булган һәр нәрсә һәм аңа ирешү юллары — уңай нәрсәләр»; 2) «Күбрәк ләззәтләнергә тырыш!».

Гедонист үз тормышын өзлексез ләззәт артыннан куура багышлый. Әгәр ләззәтләнү һәм туктаусыз күңел ачуга омтылу тормышыгызның төп максатына әверелгән икән, сез — гедонист (яки гедоник). Гедонист өчен ләззәт алу гына җитми, аңа торган саен яңадан-яңа төрле күңел ачулар кирәк. Күңел ачу китергән



ләззәт һәрчак тиз уза. Шулай итеп, аның гомере күз ачып күз йомганчы уза торган ләззәтле мизгелләр җыелмасына әверелә; кайчак бик озакка сузыла торган эчпошыргыч паузалар белән узалар. Кеше күңелсезләнә, кулыннан эш төшә, газаплана. Киләсе күтәрелешкә кадәр шулай дәвам итә.

Адәм заты тумыштан ук диярлек гедонист була. Сабый кичерә торган ләззәт гади һәм талымсыз: тамагы тук булу, бишеккә салып тирбәтү, әнисенең кул җылысы, ягымлы сүзләр, хуплау, бүләкләр, уен. Балалык чоры безнең хәтеребездә хәвефсез, мәшәкатьсез, имин чак булып кала. Артык мәшәкатьләнмичә генә бирелгән ләззәтләнү вакыты буларак, без аны һәрчак юксынабыз, аңа тартылабыз. Бала чагын искә алганда, соңрак кеше аны романтик ләззәт чолганышында күрә. Олыгая барган саен, аңа ешрак төрле чикләүләргә очрарга һәм теләсә нинди ләззәт, бәхетле халәт зур бәяләр хисабына бирелүен аңларга туры килә. Тирә-юньдәгеләр белән мөгамәләсе һәм аралашуы кешедән ләззәткә омтылышларын контрольдә тотуны, башкалар теләгенә бәйлелекне, даими ләззәт алудан баш тартуны, рәхәтсезлекләргә түзүне һ.б. таләп итә.

Гедонизмның иң чик формасы (ул җәмгыять әгъзаларының бик аз өлешендә генә күзәтелә) үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүне һәм көчле теләкләрен культ дәрәҗәсенә күтәрүдә чагылыш таба. Бу очракта көчле теләкләрне канәгатьләндерү иң беренче урынга куела. Әмма «бәһасенә карамастан ләззәт алу» башкалар хисабына,

тирә-юньдәгеләрнең газап чигүе хисабына була. Ләззәтләнү әхлагы тора-бара җәбер һәм кансызлык әхлагына әверелә. Бу күренеш массачылга әверелсә, бер генә җәмгыять тә исән-имин кала алмый. Үз мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен, җәза алудан курыкмыйча гына, һәркем талау, үтерү, урлау белән шөгыльләнгән җәмгыятьне күз алдына китерегез әле!

Әгәр тыю-чикләүләр булмаса, күпләр гедонизмның ымсындыруына каршы тора да алмаслар иде, бәлки. Беренчедән, *башкалар хисабына ләззәтләнүне җәмгыять тыя.* Икенчедән, *бетмәс-төкәнмәс рәхәтлек чигү, ләззәтләнү ахыр чиктә барыбер туйдыра.* Гедонист үз-үзенә барлык юлларны бикли: ләззәт артыннан куу монотон агышлы конвейерга әверелә, һәрбер операция саен ләззәт алу кими бара. Үз гомерләрен ләззәт артыннан куугa багышлаган әдәби геройларны һәм тарихи шәхесләрне генә искә төшерегез.

Халыкның күпчелеге бер үк вакытта, үз-үзенә зыян китермичә генә гедонист була алмаганлыктан, һәркем бик кыска гына вакытка булса да шушы рольдә булып алырга тели. Безнең беребез дә, мәшәкатьле, артык кыйммәт булмаса һәм күңелсез нәтиҗәләргә китермәсә, ләззәтләнүдән баш тартмый. Җәмгыятьнең, әхлак полициясенең, җәмәгатьчелек агентларының кырыс күзәтүеннән ычкыну, азга гына булса да кагыйдәләр чигеннән чыгу, бераз гына «тышаусызлану» — күпләрнең теләге шундый. Кайчак законга буйсынып гомер итүче кешегә дә хәтта тиешлелек кысаларыннан чыгып гамәл кылу рәхәтлек бирә һәм кызыклы була. Кагыйдәләрдән читкә чыкканда ул үзен бәйсез һәм ирекле итеп тоя.

Кайчак ул үзе үк урнаштырган кагыйдәләрне боза. Кайбер җәмгыятьләрдә кагыйдәләрдән массакүләм тайпылыш өчен хөкүмәт рәсми рәвештә билгеле бер вакыт бүлеп бирә, хәтта аларны бәйрәм рәвешендә оештыра да әле. Бу фестивальләр, карнаваллар, күмәк күңел ачу һ.б. булырга мөмкин. Җәмгыятьтәге иң четерекле темалар чагылыш таба торган анекдотлар, шаяру, көлү, сатира шулай ук киеренкелектән бушану чарасы булып торалар.

Гедонист аз-маз тәртип бозгаласа да, зуррак җинаятьләр кылуга бармый. Җинаять кылу күңелсезлекләргә сәбәпче була, ә гедонист исә аларны булдырмаска тырыша. Әмма вак кына тәртип бозулар да зур мәшәкатьләр китереп чыгарырга мөмкин. Дуслары компаниясендә кеше «үлән» тартып карады яисә бер-ике рюмка спиртлы эчемлек

эчте, ди. Бу аңа ошап китә. Тыелырга көч табып булмый, әхлак тыюлары да бөтенләй юк яисә алар җитәрлек нык түгел. Мавыгу барлыкка килә. Ярты елдан бу инде ихтыяҗга әйләнә. Еллар узу белән бу кеше үтә чыккан наркоманга яисә эчкечегә әйләнә. Бу конвейер гына түгел инде, бу — ләззәтләр эскалациясе: һәр яңа доза артыграк ләззәт китерә, ихтыяҗга һәм мәңгелек гадәткә әверелә, ә шәхес торган саен артка чигенә (деградацияли) бара. Күпчелек белгечләр наркоманиянең һәм эчкечелекнең дәвалап булмый торган чир икәнен таныйлар. Мәҗбүри дәвалау нәтиҗә бирми. Кешенең үз ризалыгы, дәвалануга әзер булуы кирәк. Мондый ризалык һәм әзерлек булган очракта да, ул вакытлыча гына туа, кешенең үз-үзен тотышында яңа стратегия кирәк. Анысын исә шәхес булдырырга тиеш, әмма шәхеслек юкка чыккан. Гедонизм шулай итеп башланган ноктасына кабат-кабат кайта да төшә.

Авантюризм, хәтәр маҗаралар теләү — гедонизмның бер рәвеше. Кешеләр ни өчен тәвәккәл адымнар ясап ләззәтләнү эзлиләр, чит илләргә сәяхәт кылалар, стратосферага чыгалар, үлем куркынычы янаган автоярышларда катнашалар һ.б.? Безне яңа һәм еш кына бик куркыныч күңел ачу рәвешләре җәлеп итә. Алар гаҗәеп ләззәт бирәләр, рәхәтлек хисен тагын да көчәйтәләр. Әгәр авантюра аерым бер кеше тормышы өчен хас икән, бу очракта җәмгыятькә аннан артык зыян юк. Әмма тарихта тулаем илләргә һәм материкларга фаҗигалы һөҗүмнәр оештырган бөек авантюристлар исемнәре дә байтак. Пиратлар — күмәк авантюризмга уңышлы мисал. Бер командага авантюристлар, маргиналь шәхесләр, булдыксызлар, җинаятьчел элементлар һәм баю, хәтәр маҗаралар хакына үз тормышын корбан итәргә әзер торучы башка адәмнәр туплана. Авантюризм канга сеңә, тора-бара әхлаксызлыкка әйләнә: авантюристлар теләсә нинди нормаларны һәм законнарны санга сукмаска мөмкиннәр, ләззәтләнү юлына аркылы төшкән бер гаепсез җаннарны кыярга да әзер торалар.

Сүз дә юк, үзенә күрә ләззәтләнү әхлаксызлык була алмый, шуңа күрә гедонизмны тәнкыйтьләү ләззәт принцибыннан бөтенләй баш тарту дигән сүз түгел. Аннан башка иҗтимагый тормыш була да алмый. Биологик яктан караганда, ләззәт һәм хәсрәтнең роле аларның җайлашу функциясен үтәүләре белән билгеләнә: ләззәт организм ихтыяҗларына җавап бирүче активлыкка этәргеч бирә; ә

ләззәтнең булмавы, хәсрәт кичерү аның өчен куркыныч гамәлләргә чик куя. Психофизиологик күзлектән чыгып караганда, ихтыяҗ канәгатьләндерү нәтиҗәсе буларак ләззәт эчке киеренкелекнең (физик һәм психик) кимүе һәм бөтенләй бетүенә китергәнлектән, ул организмның тереклек функцияләрен тергезүгә ярдәм итә. Бу мәгънәсендә ләззәт, һичшиксез, уңай күренеш, ул бик кирәк. Шушыннан билгеле бер норматив позиция килеп чыга. Аның буенча ләззәтләнүдән канәгатьлек кичерү халәте организм өчен идеаль була, һәм кеше мондый халәткә ирешү өчен тырышырга тиеш.

Гедонизм этик таләпләргә буйсындырылганда гына акылга муафыйк буладыр, мөгаен: үз теләкләреңне тормышка ашырырга омтылганда, башбаштаклык кылма һәм башкаларның да ләззәтләнүгә хокукы барлыгын онытма. ***Акылга нигезләнгән гедонизм, әгәр ул иҗатка, сәнгатькә, фәнгә этәргеч булса, җәмгыятьтә разыйлык кына түгел, хуплау да таба.*** Галим һәм актер үз хезмәтләреннән иң югары дәрәҗәдәге ләззәт алырга тиешләр, юкса аларның эшкә күңелләре суынуы бар. Физик хезмәт кенә түгел, еш кына азрак төшемле акыл хезмәте дә гаять зур эчке канәгатьлек таләп итә. Кеше китап язу, симфония иҗат итү, фәнни теория эшләү процессыннан иң югары ләззәт алырга тиеш. Ул теләсә-нинди бүләкләрдән — гонорар, мактаулы исемнәрдән, дан-дәрәҗәләрдән өстенрәк дип санала. Ләззәт биредә этик яктан аклана.

Гедонистлар янәшәсендә ***үз дигәнчә генә эш итәргә теләүчеләр*** урын ала. Мондый затлар психологик һәм әхлакый басым, башка кеше аңына, аның үз-үзен тотышына йогынты ясауның төрле алымнарын кулланалар. Бары бер шәхес кенә хөрмәткә лаек, башкаларның моңа хокукы юк дип танызла. Кемнең дә булса үз дигәнен генә булдырырга омтылуы — башкаларның фикер-теләкләре белән исәпләшмичә, үзе корган планнарны эзлекле һәм мәҗбүриләп тормышка ашыруы ул.

Төшенчәләр: *бәхет, ләззәт, гедонизм.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Төрле чор фәлсәфәчеләре һәм язучылары бәхетне ничегрәк аңлаганнар?

2. Гедонистның үз-үзен тотышына характеристика бирегез.

***3.** Классик язучының: «Барлык бәхетлеләр бертөсле, бәхетсезләр генә бер-берсенә охшамаган», — дигән сүзләрен сез ничек аңлыйсыз? Бу кайсы классик сүзләре?
***4.** «Уңышлы, шат, бай, дан-дәрәҗәле кеше бәхеткә дә җиңелрәк ирешә һәм бәхетле мизгелләрне ешрак кичерә», — дигән гыйбарә белән килешәсезме? Үз җавабыгызны дәлилләгез.
***5.** Сезнең фикерегезчә, ни өчен «бәхет» дигән фәлсәфи төшенчә бар, ә менә «бәхетсезлек» дигәне юк?
***6.** Ни өчен бәхет психологиядә, социологиядә һәм политологиядә түгел, ә философиядә өйрәнелә?
***7.** Кайчак: кешеләрне гаепләү өчен генә түгел, бәлки мактау өчен дә хокук алу кирәк, дигән сүзләр ишетергә туры килә. Мондый хокук кемнәргә бирелә?
***8.** Яхшылыктан башка гына бәхет була аламы? Бу турыда сез нәрсә уйлыйсыз?
***9.** «Дөньяда бәхет юк ул, бары тынычлык һәм ирек кенә бар», — дигән гыйбарәне сез ничек аңлыйсыз? Мондый позиция белән килешәсезме?

? Проблема. Бәхет тышкы сәбәпләргә яисә кешенең эчке халәтенә бәйлеме?

✍ **Практикум.** Рим философы, стоицизм вәкиле, император Неронның тәрбиячесе, көчле теләкләрдән азатлыкны алга сөргән һәм үлемне санга сукмавын ачыктан-ачык белдергән Сенека (якынча б.э.к. 4 нче ел — б.э. 65 нче елы) кешенең үз мал-мөлкәтенә мөнәсәбәтен тикшерү өчен үзенчәлекле тест тәкъдим итә: «Йортыңның ишекләрен ачып, ватандашларыңны керергә чакыр, һәрберсенә ул үз милке дип санаган әйберне алырга тәкъдим ит. Әгәр шуннан соң да синең мал-мөлкәтең кимемәсә, синең турыда чын-чынлап бай кеше дип әйтергә мөмкин булыр».
Сез бүген бу тестны ничегрәк һәм нинди иҗтимагый төркемнәргә карата кулланыр идегез?

✍ **Практикум 2.** Төркемнәрдә эшләү өчен бирем. Бәхет турында мәкальләр һәм әйтемнәр туплап, аларның мәгънәләрен аңлатыгыз.

§ 16 (§ 37). Гаделлек һәм тигезлек

Гаделлек хисе, күзгә күренмәсә дә, теләсә нинди әхлакый норманы үтәүдә катнаша булса кирәк. Гаделлек кемгә дә булса кылган гамәленә барәбәр хак түләүне күздә тота. Башкалар аз эшләгәндә, ни өчен мин күп хезмәт итәргә тиеш, дип сорыйбыз без бик еш. Башкалар муллыкта гомер кичергәндә, ни өчен мин хәерче булырга тиеш? Бүтәннәр караклык белән көн күргәндә, миңа да нигә урлашмаска? Димәк ки, миңа яхшылык эшләсәләр, мин дә яхшы булам. Әгәр киресенчә булса? Ул очракта — гафу итегез. Көндәлек тормышта без нәкъ шулай фикер йөртәбез. Әмма бу әхлаклылык була аламы?

Гаделлек ул кешеләр арасында иҗтимагый кыйммәтләрне бүлү (кабаттан бүлү), шул исәптән үзара алмашуга кагылышлы үзара мөнәсәбәтләрне җайга салучы принципларның берсе булып тора. Мондый кыйммәтләр функциясен ирек, уңай мөмкинлекләр, керемнәр һәм байлык, абруйлылык һәм ихтирам билгеләре һ.б. үти ала.

Законнарны бозмаучы һәм изгелеккә изгелек белән җавап бирүче кешеләрне — гадел, ә башбаштак, бүтәннәрнең хокукларын санга сукмаучыларны (аларны ирексезләүче һәм милкәтләрен тартып алучыны) гаделсез кеше дип атыйлар. Һәркемгә казанышларына карап бирелгән бәһа — гадел, һәм, киресенчә, тиешсезгә бирелгән дан-дәрәҗә, яки җәза гаделсез, нахак буларак таныла. Кешенең үз бурычларын үтәве, хәтта аларның кайберләре ачыктан-ачык күздә тотылмаса да, гаделлек дип санала.

Борынгы грек акыл ияләре Платон һәм Аристотель гаделлекне иҗтимагый игелек (шәфәгать) дип карыйлар. Аристотель фикеренчә, гаделлек кешенең барлык башка шәфәгатьләреннән дә өстенрәк тора. Закон буенча ул кешегә нинди эшләрдә ирлек күрсәтергә, ә ниндиләрендә акылга таянып гамәл кылырга кирәклеген билгели. Кимчелекле, әйтик, куркак һәм сатлык кешене түбән җанлы һәм гаделсез дип атыйлар. Гаделлекне ике төргә аерып йөртү традициясе Аристотельдән үк килә. Беренчесе дан-дәрәҗә һәм матди байлыкларның гражданнар арасында аларның



лаеклыгына, казанышларына карап бүленүендә чагылыш таба. Икенчесе алыш-бирештә катнашучы якларны, аларның лаеклылыгы дәрәҗәсенә карамастан, тигезләүне бурыч итә. Хәзерге заман философлары исә гаделлекне хакыйкать белән чагыштыралар. Фәлсәфә тарихында гомум кешеләр өчен яхшы булган нәрсә гаделлек була, дигән караш ныгып урнашкан.

Гаделлек еш кына байлык-уңайлыкларны бүлүгә кагылса да, ул үзе боларга бәйле булмый.

Социаль гаделлек чагыштырма була. Берәр патшаның теләсә нинди башбаштаклыгын гадел дип танырга да була, ни өчен дигәндә, ул бит дәүләттә беренче кеше, хакимлек аңа Ходайдан бирелгән. Патшаны үлемгә хөкем итүче ярсыган кешеләр төркеменең нәфрәте дә хаклы, чөнки әлеге патшаның хакимлеге аларны хәерчелек хәленә төшергән. Бер гаепсез кешеләрне ашыкпошык үлем җәзасына хөкем иткән «өчлек» тә (Сталин судлары) гадел дип саналган (пролетар дәүләт халык дошманнарын рәхимсез кырырга тиеш, янәсе). Кыскасы, ни теләсәң шуны диярлек гаделгә чыгарырга була. Әмма өстен катлау гаделлекне ничек кенә үз мәнфәгатьләренә яраклаштырырга тырышып карамасын, гади халыкның иҗтимагый гаделлек турында стихияле һәм дөресрәк үз төшенчәсе була. Үз мәнфәгатьләрен яклап көрәшкәндә алар нәкъ шуңа таянып эш итәләр.

Җәмгыятьтә гаделлек күпчелек очракта **тигезлек** проблемасы буларак карала. ***Тигезлек принцибын бозмау — гаделлек***

принцибының иң гади таләбе. Борынгы җәмгыятьтә үк кешеләр гаделлек белән тигезлек арасында бәйләнеш барлыгын тоеп алалар һәм ул канлы үч (үч алу таләбе) институтында чагылыш таба: башкалар сиңа карата нинди мөгамәләдә булса, син дә аларга шуның белән үк җавап бир, яисә «күз өчен — күз, теш өчен — теш». Җәбер салучы җәзасыз калмасын өчен үч алу бар: рәнҗетүенә барәбәр ул җаваплылыкка да тартылырга тиеш.

Тигезлекне болай аңлату җәмгыятьнең иҗтимагый һәм мәдәни үсешендә бик зур адым була. Чынлап та, кыргыйлык чорында кешеләр берлегендә (галимнәр аны кешелек барлыкка килгәнгә кадәрге көтү дип атыйлар) өстенлек һәрчак көчленеке булган: көчле көчсезне талый, иң яхшысы иң начарга хаким була, куәтле куәтсезне бастырып тора. (8–9 сыйныфлар курсындагы сәяси хакимият турындагы бүлектән исегезгә төшерегез: мондый йогынты рәвеше ничек атала?) Канлы үч законы кыерсытылган тарафның күмәкләшеп үч алуын таләп иткән. Гаепле кеше үч алулары мөмкин икәнен яхшы белә, һәм бу кешеләр арасындагы мөгамәләдә башбаштаклык очракларын тыебрак тора. Шул рәвешчә, ыруглык строеннан килүче канлы үч законы иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салуның беренче чарасы булып торган.

Әмма соңрак, җәмгыять үсешенең югарырак баскычларында, төгәлрәге, Антик чорда, кешеләрдә: үч алу белән генә гаделлекне торгызып буламы соң, дигән сораулар туа башлый. Җан кыйган кешене үтерү белән генә ул кылган явызлыкны йолып булмый — аның корбанын барыбер кире бу дөньяга кайтару һәм туган-тумачасының хәсрәтен җиңеләйтү мөмкин түгел. Үтергән өчен үтерү аша үч алына, әмма гаделлек торгызылмый. Беренче очракта кылынган явызлык икенче очракта юкка чыкмый, бары көчәя генә. Канлы үчнең гасырлар буе сузылу, буыннан буынга тапшырылу очраклары да байтак, ул тулаем нәсел-ыруларның һәлак булуына китергән.

Христиан дине гаделлек үсешендә яңа этап булып тора. Ул «таш атканга — аш ат», «кешеләрне хөкем итмә, үзеңне дә хөкем итмәсләр» принципларын алга сөрә. Яңа этика канлы үчне тыюны таләп итә. Әмма «кешеләрне ярат» дигән өндәүгә ияру кешеләр арасында, шактый цивилизацияле булуларына да карамастан, кы-

енлык белән генә бара. Бүген дә әле көнкүрешебездә без икенче кагыйдәгә караганда, беренчесен кулайрак күрәбез. Сәясәттә дә хәтта канлы үчнең төрле рәвеш алган принциплары еш кына халыкара низаглар һәм сугышлар килеп чыгуга сәбәпче була. Җәмгыятьтә әхлакый аң үсә барган саен гаделлекне бары тигезлек белән генә тәңгәлләштерү дә кими бара. Шулай булса да әле хәзергә кадәр гаделлек дигәндә, күпчелек нәкъ менә тигезлекне күздә тота. Социаль сәясәт өлкәсендә, бер яктан, кешеләргә кем күпме булдыра ала, шуның кадәр акча эшләү мөмкинлеге бирү — алынган керемнең бер өлешен прогрессив салым салу механизмы аша ярлылар файдасына калдыру (8–9 сыйныфлар курсыннан прогрессив салым салу механизмы ни икәнне, аның асылын нәрсә тәшкил итүне исегезгә төшерегез) — гаделлек дип санала.

Җәмгыятьтә бай кешеләр күбрәк булган саен, мохтаҗларга ярдәм итү өчен алардан шуның кадәр күбрәк акча алып була. Көнбатышта шундый караш яши. Моның белән безнең сәясәтчеләр дә килешә, әмма бу принципны тормышка ашыру өчен аларга кайбер объектив шартлар комачаулык итә. Ә совет сәясәтчеләренең фикерләре башкачарак иде. Тигезләү нәтиҗәсендә кешеләрнең муллыкта яши алмаячагы билгеле булса да, сәясәтчеләр шуны алга сөрделәр (әлеге сәясәт хаким өстен катлауга, зур вазыйфа биләүче бюрократларга кагылмый иде). Мондый тыйнак яшәеш күп кенә социаль проблемаларны булдырмый һәм күпмедер вакытка кадәр җәмгыять өчен файдалы була. Ул тирән нәфрәт хисе тудырмый, шулай булгач, агрессия һәм фетнә дә килеп чыкмый.

90 нчы елларда базар мөнәсәбәтләренә нигез салына, ә бу шартларда байлык туплауга бернинди дә киртәләр калмый. Нәтиҗәдә бай кешеләр барлыкка килә, һәм алар башкаларда көнчелек кенә түгел, хәтта нәфрәт хисе тудыралар. Алар байлыкны хак юл белән тупламаган, дигән ныклы ышану яши. Гомум социалистик тигезлектән соң ничек кинәт кенә аеруча өстенлекле кешеләр барлыкка килде соң? Бәлки аларның байлыгы буыннан-буынга фидакарь хезмәт куеп җыелгандыр? Әллә аларга бәхет елмайдымы, мираска зур хәзинә калдымы? Юк, моның берсе дә булмады. Бары бер генә юл кала: байлык хәрәмләшеп тупланган. Ә бу исә — әхлаксызлык. «Яңа руслар»ның бер өлеше, алар ничек кенә акла-

нырга тырышмасыннар, гадел булмаган юллар белән баючылар дип танылырга тиешләр. Оештыру сәләтенә ия булган һәм талантлы икенче бер өлеше һич кенә дә мондый бәягә лаек түгел. Әмма иҗтимагый фикер аларга барыбер шул ук ярлыкны тага. Нәтиҗәдә барлык бай кешеләр бер очракта хаклы, икенче очракта хаксыз рәвештә гаделсез юллар белән байлык туплаучылар рәтенә кертеп карала. Җәмгыятьтән тигезлек һәм гаделлек бер үк вакытта юкка чыкты.

Күрәсең, кешелек җәмгыяте өчен иң чик тигезлек кебек үк иң чик тигезсезлек, тулы гаделлек кебек үк, аның булмавы да бердәй зарарлыдыр. Аз гына тигезсезлек кирәктер кебек. Әмма аның чамасын алдан, ягъни теоретик юл белән билгеләп кенә булмый. Вакыт-вакыт төрле экспериментлар уздырырга туры килә. Һәр милләтнең һәм һәр мәдәниятнең үз рецепты: кемнәрдер шәхси ирекне өстенрәк күрә, ә кемнәргәдер кумәклек идеаллары күбрәк ошый. Тигезлекне бераз бозуың була, илдә зар күтәрелә: шәхси ирекне кысалар, яисә кумәклек традицияләренә хөрмәт юк, янәсе. Тайпылышларны тигезлек хәленә китерер өчен законнар кабул итәргә туры килә. Бу исә ризасызлыкка барыбер чик куймый.

Теләсә нинди җәмгыятьтә, аның составының төрлелеге аркасында, теләсә кайсы идеянең, программаның, яңалыкның һәм тарафдарлары, һәм каршылык күрсәтүчеләре була. Һәрбер төркем, сәяси хәрәкәт парламент яки президент аша үзләре хак дип санаган идеяләрне уздырырга тырышачаклар.

Шулай итеп, без гаять катлаулы әхлак категорияләре мохите белән таныштык һәм аның эчтәлеге төрле чорларда, мәдәниятләрдә үзгәреп торуын, төрле фәлсәфи юнәлешләрдә аның төрлечә булуын күрдек. Хәер кешеләр дә көндәлек хәятларында кайчак яхшылык һәм явызлык, намус һәм абруй, начарлык һәм игелек (шәфәгать) төшенчәләрен капма-каршы мәгънәдә аңлап гамәл кылалар. Капма-каршы ике як бер-берсе белән гаделлек өчен көрәшәләр, соңрак исә аларның икесенең дә гаделлектән бик ерак торулары ачыклана. Гадирәк әйткәндә, әхлак гаять зур лабиринтны хәтерләтә, аның һәр борылышында шәхес я әхлакый сайлау алдында кала, я әхлакый тупикка килеп терәлә. Бөтен гомерегез буенча сез шушы лабиринтта дөрес юнәлеш табарга өйрәнәсез.

Төшенчәләр: *гаделлек, тигезлек.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Борынгы вакытлардан алып хәзерге чорга кадәр гаделлек турындагы карашлар ничек үзгәрүен тасвирлап бирегез.

2. Тигезлек идеясе гаделлек турындагы идея белән ничек яраша?

3. Гаделлек башка игелек-шәфәгатьләр белән ничек яраша?

*4. Өч әхлакый хакыйкатьне үзара чагыштырыгыз: а) башкаларга аларның сиңа карата нинди мөнәсәбәттә булуларын теләсәң, шундый ук мөнәсәбәттә бул; б) «Аллаһы авазын ишеткәндәй гамәл кыл», — дип яза Н. Бердяев; в) Алар сиңа нинди мөнәсәбәттә булсалар, башкаларга карата син дә шундый мөнәсәбәттә бул.

Уртак һәм аерым сыйфатларны күрсәтегез. Сезнең карашларга туры килгәнен сайлап алыгыз һәм сайлаганыгызны дәлилләгез.

*5. Ни өчен кешеләр, ирекнең бик тансык булуына да карамастан, кайчак аннан баш тарталар? Ә гаделлеккә кагылышлы эшләр ничегрәк тора?

*6. Мәгълүм булганча, шәфкатьне башкаларга күчерелгән үз-үзеңне ярату хисе дип аңлаталар. Алай булгач, әгәр тирәюньдәгеләрне яратырга кирәк икән, ни өчен башта үз-үзеңне яратмаска? Сез бу сорауга ничегрәк җавап бирер идегез?

? Проблема. Россиянең хәзерге җәмгыятенә карата «социаль гаделлек» төшенчәсен кулланып буламы?

✍ **Практикум 1.** Сократ үз вакытында: «Әгәр туганнарыгыздан яисә дусларыгыздан берәрсе гаделсезлек кылса, моны яшерергә ярамый — судка барып, барысын да сөйләп бирергә һәм шул рәвешчә, аңа җәза бирелүгә ярдәм күрсәтеп, туганнарыгызга яисә дустыгызга явызлыктан арынырга ярдәм итәргә кирәк», — дигән фикерне алга сөргән. Иң зур явызлык — гадел-

сезлек кылып та, җәзасыз калуда. Борынгы грек фикер иясенең бу гыйбарәсен сез ничегрәк аңлыйсыз? Әлеге фикерне раслый яисә кире кага торган конкрет мисаллар китерегез.

✍**Практикум 2.** «Гомум тигезлекнең асылы...» дигән темага эссе языгыз.

5 (11) бүлек.
Кешенең күңел дөньясы һәм социальләшүе

§ 17 (§ 38). Кеше психикасының төзелеше

Хәзерге фәндә кеше асылының ике өлештән торуы турындагы караш яши. Аның эволюциясе ахыр чиктә кешедәге табигый башлангычның социаль (мәдәни, цивилизацияле) башлангыч тарафыннан кысрыклануына китерә. Ул ике зур этаптан тора — *биологик* һәм *социаль* (яки *мәдәни*) этаплар. Беренчесе икенчесенә караганда озынрак.

Биологик эволюция мәдәни эволюциягә караганда бик күпкә озаграк дәвам иткән. Ул 2,5 миллион ел барган. Кешенең үсеше 40 мең ел элек төгәлләнгән. Нәкъ шушы вакытта аны бүген дә башка тереклек ияләреннән аерып торучы фундаменталь билгеләр формалашып җиткән: ике аякта йөрү, камилләшкән ми, икенче сигнал системасының булуы, фикерләү, тел һәм аң, балалык чорының дәвамлырак булуы, хезмәт коралларын кулланырга, уттан файдаланырга өйрәнү. Алар *биологик эволюциядән мәдәни эволюциягә күчү өчен шарт булып торалар.* Кешенең соңгы 40 мең ел эчендә үзләштергәннәре биологиягә түгел, мәдәният һәм җәмгыятькә бәйләнгән.

Кешенең үсешен табигый башлангычның социаль башлангыч тарафыннан кысырыклану процессы буларак күзалларга мөмкин. Кешенең кул чуклары биологик яктан караганда кашык яисә карандаш тоту, киемен төймәләү яисә рояльдә уйнау өчен җайлашмаган. Алар

бары мәдәни эволюция дәвамында гына пианинода уйнаучының гаять сизгер коралына әвереләләр.

Кешенең һәм хайваннарның уртак һәм аерым сыйфатлары бар. Югары үсешле хайваннар белән кешене күңел хәрәкәтләренең һәм күренешләренең (сизү-тою, хис-тойгылар, хәтер һ.б.) җыелмасына (грекчадан psychikos — җаннан килүче) — психикага ия булулары берләштерә. **Аңлы** булуы кешене башка хайваннардан аерып тора.

Фикерләү мигә хас функция (әмма минең бер өлеше түгел) булган кебек, психика — югары оешкан материягә хас. ***Психика — чынбарлыкны чагылдыруның үтә үзенчәлекле бер рәвеше.*** Ул биологик эволюциянең билгеле бер баскычында барлыкка килә. Терек системаларның әйләнә-тирә мохит белән үзара тәэсир итешү нәтиҗәсе аның эчтәлеген тәшкил итә. Психологлар шәхес турында сүз алып барганда, беренче чиратта психиканы күздә тоталар.

Австрия психиатры ***З. Фрейд*** (1856–1939) кеше күңел дөньясының катлаулы төзелешен ачучыларның беренчесе була. Ул уйлап тапкан психоанализ принциплары кешелек мәдәниятенең бик күп өлкәләрендә — мифологиядә, фольклорда, нәфис сәнгатьтә, диндә һ.б. — кулланыла. Фрейд кеше үзен тәрбиясез тотканда ачыла торган табигый башлангычны гына түгел, бәлки аның үзеннән һәм башкалардан яшерен серләрен, төгәлрәге, табигать үзе үк бездән яшергән нәрсәләрне дә аңларга тырышып карый.

Шәхес структурасында Фрейд өч төп компонентны күрсәтә. Болар: «Ул», «Мин» һәм «Гадәттән тыш Мин» компонентлары һәм алар шул ук тәртиптә томанлы аң, аң һәм аңнан тыш ятучы өлкәләрдә урнашалар.

Томанлы аң («Ул»):

— ***биологик ихтыяҗлар***: җенси теләк, табигый хаҗәтләрне үтәү, ризыкка ихтыяҗ, салкыннан саклану ихтыяҗы һ.б., бастырылган тыелган теләкләр һәм омтылышлар (интим теләкләр);

— ***бастырылган теләкләр***: җавапсыз мәхәббәт, чынга ашмаган хыяллар, яшерен үпкә, җәнҗал һәм кешенең начар данын чыгара торган гамәлләре һ.б.;

Безнең томанлы аңыбыз өлкәсенә шәхеснең күңелендәге барлык юшкыны һәм унышсызлык кичергән мизгелләре туплана. Әмма бу тулы дөреслек булмас. Томанлы аң бер үк вакытта күңелнең табигый тупланмалары да әле ул. Җир астында яктылык һәм энергия

чыганагы булган нефть ятмалары сакланган кебек, томанлы аңыбыз да безнең өчен бетмәс-төкәнмәс көч-куәт чыганагы булып тора. «Ул» — социальләшү процессында «Мин» һәм «Гадәттән тыш Мин» үсентеләре шытып чыга торган орлык. Бу шәхесне шәхес итә торган материал, инстинктив психологик энергия чишмәсе — ***либидо***. Аны аңламый, фикер, рефлексия объекты итми торып, томанлы аңыбызга башкача күз сала алмыйбыз. Әмма томанлы аңны сүз кабыгына төрү беренчел образны бозуга китерә. Электрон микроскоп ярдәмендә (ул 40000 тапкыр зурайта) субатомлы мохитка үтеп керергә тырышучы физика белгече иң гади кисәкчәне траекториясеннән нәкъ шулай тайпылдыра, ягъни беренчел сурәтне боза. XIX гасырда Ф. Тютчев томанлы аң мәсьәләсен бик ачык тоеп: «Әйтелгән фикер — ялган», — дигән. Фрейд фикеренчә, томанлы аң принципиаль рәвештә сүз калыбына салына алмый, бу бары читләтеп кенә: төштә, хыялда, саташканда гына мөмкин була. Томанлы аңга ләззәтләнү принцибы җитәкчелек итә. Аның белән бертуктаусыз көрәшергә, бик еш теләгәнеңне түгел, тиешлесен эшләргә туры килә.



Психиканың З.Фрейдча төзелеше

Аң яисә «Мин» (Ego) — безнең тышкы дөнья белән бәйләнешебез белән идарә итүче компонент. Кеше дөньяга килгәндә аның бары биологик ихтыяҗлары гына була. Алар кичекмәстән канәгатьләндерүне таләп итәләр һәм организмга рәхәтлек бирәләр (киеренкелекне бетерәләр). Әмма тора-бара ата-аналар, аннан соң тирә-юньдәге кешеләр дә, баланы үз табигый теләкләрен йөгәнләргә, реаль шарт-

ларга яраклашып үз тәртибеңне кагыйдәләргә туры китерергә, дөрес гамәлләр кылырга өйрәтәләр.

Шул рәвешчә, тәрбия процессында кеше үзен чикләргә күнегә. Тора-бара аның «мин»е формалаша, аның белән икенче принцип — чынбарлык принцибы идарә итә. Ул кешене һәр нәрсәдә акылга, мантыйкый дәлилләргә таянып эш итәргә, һәр нәрсәдән файда табарга, кешеләр һәм шартлар белән хәйләкәрләрчә гамәл кылырга, бар нәрсәгә шик белән карарга, беренче очраган кешегә күңел тойгыларыңны ачып салмаска, әйләнә-тирәдәгеләрдән фикерләреңне яшерергә этәрә. Рациональ «Мин» кешене туң йөрәкле, җансыз, прагматик итеп кенә калмый, бәлки эшлекле, исәпле, уңышка ирешергә, кыен хәлләрдән чыгарга сәләтле дә итә. Кеше үзенең «мин»енә мантыйклы фикерләве, карарлар кабул итү механизмы кебек иң камил коралга ия булуы белән бурычлы.

Цивилизация казанышлары – күпчелек очракта «Мин» эшчәнлеге нәтиҗәсе. Социаль тормышның нигезе, социология фәне өйрәнә торган бар нәрсә аның җимеше дип тә әйтеп була.

Аң ике өлешле: а) акыл, мантыйк, б) цензура. Кеше акылы әйләнә-тирә мохиттан бары үз-үзен саклау, төпле урынын табу өчен кирәк нәрсәләрне генә сайлап ала. Башкаларын исә читкә тибәрә. Әмма мондый сайлау белән шөгыльләнүче нәкъ цензор була да инде.

Гадәттән тыш аң — «гадәттән тыш Мин». Шәхес структурасының бу өлеше Фрейд тарафыннан иң аз өйрәнелгән. Фрейдның «гадәттән тыш Мин»е – кешедә ныгып урнашкан мәдәни нормалар, кагыйдәләр, таләпләр, тыюлар, стереотиплар, законнар ул. «Гадәттән тыш мин» — әхлакый тойгылар тирәлеге ул.

П.Флоренский, Н.Бердяев, С.Булгаков, В.Соловьев кебек рус философлары традицияләрен дәвам итүче күренекле социолог ***П.Сорокин*** (1881–1968) гадәттән тыш аңны башкачарак аңлата.

Кешенең гадәттән тыш аңын тәшкил итүче әхлакый законнар — абсолют, ә менә «Мин» яшәү өчен көрәшкәндә таяна торган мантыйкый законнар һәм иҗтимагый нормалар бары шартлы була. Аң һәм гадәттән тыш аң, Сорокин фикеренчә, — бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике дөнья. Беренчесе — хәрәкәттә һәм вакытлы, икенчесе — абсолют һәм мәңгелек мохиты. Әхлак һәм мораль — иң югары, мәңгелек хакыйкатьләр тупланмасы. Биредә кешенең сулышы киңәя.

Әлеге ике мохитның урыннары алышынса, кеше бәлагә юлыга. Әгәр абсолют шартлыга әверелсә, җәмгыятьтә тәртипсезлек (хаос) башлана, мәдәнилек юкка чыга. Шәхеснең әхлакый үсешен бары тик вертикаль буйлап югарыга — Ходайга таба хәрәкәт дип күзаллап була, ә «Мин»нең гадәти яшәеше исә горизонталь яссылыкта — шартлы кыйммәтләр мохитендә бара. Вертикаль яссылыкта кешеләрне, Ходайны эчкерсез, альтруистларча ярату, шәфкатьлелек, вөҗдан, үзеңне гаепле, бурычлы тою хисләре һ.б.

Тикшеренү өчен мисал:

Альтруистларча яратуны өйрәнү өчен П.Сорокин 4600 изге кешенең тормышын тасвирлаган язманы һәм сөю энергиясен күңелендә саклаучы 500 америкалы замандашы гомер юлын анализлаган. Ул тарихи һәм шәхси мисаллар туплаган, аларны колледж студентлары, шифаханәләрдә дәваланучылар катнашында тәҗрибәләр уздырып тикшергән һәм альтруистик яратуның аерым шәхесләр сәламәтлеге өчен генә түгел, бәлки гомумән социаль институтлар, тулаем җәмгыять өчен дә кирәклеген исбатлаган. Сөю аша яңа әхлакый югарылыкка күтәрелү генә кешелекне коткарып калачак. Сорокин, халыкның башка төремнәре белән чагыштырганда, динле кешеләрнең озаграк яшәвен ачыклаган. Шулай итеп, П.Сорокин дини төшенчәләрне һәм кыйммәтләрне, аларга фундаменталь категорияләр мәгънәсе биреп, фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән.

Һәркем рухи югарылыкка күтәрелә алмый. Әмма күп кенә дини эшлеклеләр (Серафим Саровский, Сергий Радонежский, Мохандо Ганди), бөек рухи юлбашчылар (Леонардо да Винчи, Микеланджело, Сократ, Ф.М.Достоевский, Л.Н.Толстой) һәм күп санлы рухи тормыш тарафдарлары — дәрвишләр, монахлар, тәкъва аксөякләр — иҗади дәртнең, күңел күзе ачылуның, әхлак хакына корбан китерүнең ни икәнен яхшы аңлаганнар. Россия патшабикәсенең сеңлесе — Елизавета Федоровна (үзенең бөтен мөлкәтен сатып, XX гасыр башында Марфа-Мария игелек йортына нигез сала), замандашыбыз Тереза Ана

шуңа ачык мисал булып тора. Гади кешеләргә мондый дәрәҗәдәге үк югары үзаң хас түгел, әмма артык зур булмаган әхлакый гамәлләр кылып, алар шәхес буларак формалашалар һәм җәмгыятьнең тотрыклылыгын ныгыталар.

Төшенчәләр: *психика, томанлы аң, аң, гадәттән тыш аң.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Кешеләр һәм хайваннарның психикасы кайсы ягы белән охшаш һәм нәрсәсе белән аерыла?

2. Кеше психикасы структурасына характеристика бирегез.

***3.** Кеше эволюциясе барышында табигый һәм иҗтимагый факторлар ролен анализлагыз. Сөйләм барлыкка килү, ми үсеше һәм уттан файдалана башлау кебек факторлар ролен күрсәтегез.

***4.** Фрейд теориясе һәм П.Сорокинның гадәттән тыш аңны ничегрәк аңлатуы турында сөйләгез. Алар арасында чик уздырыгыз.

*** 5.** Ни өчен кеше үсешен табигый башлангычның иҗтимагый башлангыч тарафыннан кысрыклап чыгарылуы дип аңлаталар?

*** 6.** Фрейд теориясендә чынбарлык теориясе һәм цензура ничек бәйләнгән?

? Проблема. Кешенең «эчке авазы» дигәндә психиканы тәшкил итүче өлешләрнең кайсысын күздә тоталар?

✍ **Практикум.** Сезгә таблица тәкъдим ителә. Сул баганада — Фрейд буенча психика дәрәҗәләренең атамалары, ә уң як баганада — билгеләмәләр бирелә. Әмма таблицаның юллары туры килми. Нинди атамага нинди билгеләмә тәңгәл килә?

Атамалар	Билгеләмәләр
Томанлы аң	Акыл кагыйдәләре җыелмасы
Аң	Әхлакый тойгылар өлкәсе
Гадәттән тыш аң	Кысрыклап чыгарылган теләкләр даирәсе

§ 18 (§39). Кеше психикасы һәм аңының элементлары

Кешенең психик тормышы оештырылышында ***инстинктлар*** һәм ***рефлекслар*** мөһим роль уйный. Боларны кеше берничек тә контрольдә тотмый һәм алар тулысынча табигатьтән бирелә. Кешенең үз-үзен саклау инстинкты (исән калу) — шулардан иң мөһиме һәм ул кешенең күп кенә гамәлләренә этәргеч бирә. Әйтик, сез бармагыгызны пешердегез яисә инә чәнчедегез — сез шул вакытта ук кулыгызны тартып алачаксыз. Авырту — чикне атлап чыгып, үз-үзегезне саклау инстинктын санга сукмавыгыз турында физиологик кисәтү ул. Һәр тереклек иясе үз гомерен саклап калу өчен көрәшә.

Ихтыяҗлар шулай ук идарә ителми торган диярлек этәргечләр булып торалар. Ачыксагыз, сез озакка сузмыйча тамагыгызны туйдырырга тырышачаксыз. 8–9 сыйныфлар өчен җәмгыять фәне курсыннан белүегезчә, А. Маслоу теориясе буенча ихтыяҗлар билгеле бер иерархия тәшкил итәләр. Ихтыяҗлар белән янәшә **гадәтләр** килә. Болары — кеше тарафыннан үзләштерелгән ихтыяҗларны канәгатьләндерү һәм инстинктларга җавап бирү ысуллары. Һәркемнең үн һәм йөз мең гадәте бар. Гаять вак атомнар молекула булып оешкан кебек, кешенең көндәлек үз-үзен тотышы да гадәтләрдән оеша. Ватыла торган нәрсәләрне саклык белән генә куярга кирәклеген, ыргытырга ярамаганлыгын, үз артыннан ишекне ябарга, биек киртәләрне әйләнеп узарга кирәк икәнлекне һ.б. белү — сезнең көндәлек тормышыгызда ярдәмчегез, сез моны хәтта тоярга да тиеш түгел. Алар, акыллы хезмәтчеләр кебек, һәр нәрсәне автоматик, дөрес итеп, вакытында башкаралар.

Гадәтләрнең инстинктлар һәм ихтыяҗлар белән бары бер урталыгы бар — алар автоматик, аңсыз рәвештә тәэсир итәләр. Әмма гадәтләрнең барлыкка килүе төрле юллар белән бара. Гадәтләрне күп тапкыр кабатлап кына үзләштереп була. Баланы ватыла торган әйберләрне ыргытмаска, сак кына өстәлгә куярга өйрәтү өчен ата-аналарга ничә ай вакыт кирәк? Көннәрме, айлармы, елламы? Аны үрмәләп йөрүдән биздереп, ике аягына басып тәпиләргә өйрәтү өчен күпме вакыт һәм көч сарыф ителә! Тормыш дигән олы дәрья буйлап озын-озак сәяхәткә чыгып китәр алдыннан ата-аналар балаларына никадәр файдалы һәм мөһим гадәтләр йоктырырга тиеш?! Таныш түгел кешеләргә ишек ачма, көненә ике тапкыр тешләреңне чистарт, идәнгә түкермә һ.б.

Гадәтләр — күпчелек очракта аңлы рәвештә һәм максатчан өйрәтү җимеше. Сез туганнарыгызга бер айга кунакка килдегез, ди. Тиздән сез иртә белән йокыдан соңрак торсагыз яхшырак булачагын аңладыгыз. Ул вакытта юыну бүлмәсе һәм бәдрәф буш була, һәм сез туганнарыгызга комачау итмисез, аларның кәефен кырмыйсыз. Тиздән соңрак уяныргa гадәтләнерсез. Әмма сез өегезгә кайткач, кирәксезгә чыккан гадәтегезне онытачаксыз. Болар безнең вакытлы булышчыларыбыз. Сез күп кенә гадәтләрне мәктәптә, урамда йоктырасыз, ял итү лагереннан, туристик походтан һ.б. алып кайтасыз.

Шулай итеп, гадәтләр *вакытлы* һәм *даими, шәхси* һәм *күмәк* булырга мөмкиннәр. Телесериаллар карау, мәсәлән, күмәк гадәткә мисал булып тора. Һәр көн саен, кырык эшен кырык якка ташлап, бик күпләр дөньясын онытып телевизор экранына текәлә. Аннан соң фильм вакыйгалары турында күршеләр, танышлар белән очрашкач, бәйрәм өстәле артында утырганда, телефон аша һ.б. фикер алышулар башлана. Телевизорлар янына билгеле бер вакытта миллионлаган кеше — яше-карты, төрле катлау һәм төрле милләт вәкилләре җыела. Сериалны күрсәтү вакыты үзгәрсә, яисә аны күрсәтүне туктатсалар, бу кешеләр үзләрен талангандай хис итәләр.

Гамәлгә аңлы этәргеч бирүче мотивлар барлыкка килүләре ягыннан катлаулырак була. Тикшерүче, җинаятьне ачкан вакытта, иң беренче нәүбәттә гамәлнең яшерен мотивларын — кешенең комсызлыгын канәгатьләндерү максатларыннанмы, билгеле бер мәнфәгатьләрне күздә тотып кылынганмы икәнен ачыкларга тырыша. Берсе — тутакаеның мирасын үзләштерергә, икенчесе — күптәнге көндәше белән исәпләшергә, өченчесе намусына тап төшерүчеләрдән үч алырга тырышкан. Тикшерүче бер нәрсәне истә тота: мотивларны ачыкласаң, җинаятьченең кемлеге, димәк ки, җинаятьнең сәбәпләре дә ачыклана.

Күпчелек очракта җинаятьләрнең мотивы була, ягъни алар аңлы рәвештә кылыналар, әмма мотивлары булмаган җинаятьләр дә очрый: гаепләнүче пычак алып нигә кешегә кадаганын аңлатып бирә алмый. Тикшерүче акылга нигезләнгән аңлатмаларны, ягъни мотивларны бу очракта таба алмый. Шулай итеп, «мотив» һәм «ихтыяҗ» сүзләре асыл мәгънәләре ягыннан тәңгәл түгелләр. *Мотив — акылга нигезләнгән гамәл. Ихтыяҗ — организмның яисә*



психиканың бары тоелган, кичерелә торган халәте генә, аңа уңайсызлык тою (дискомфорт) хас була һәм ул субъектив мәгънәгә ия булмый.

Психиканың югарырак катлавында гаять киң хисләр дөньясы ята. Хиснең билгеләмәсе бу китапның беренче бүлегеннән сезгә таныш инде. Хисләр бик күп, һәм алар үз табигатьләре ягыннан — гади тойгылардан алып катлаулы иҗтимагый хисләргә кадәр — гаять күптөрле булалар.

Хисләрнең катлаулылыгы алар арасыннан кайберләренең безнең физиологик конституциябез тарафыннан билгеләнүе белән аңлатыла. Аларның комбинацияләре күпчелектә ***темперамент — шәхеснең психик үзенчәлеге төре*** дип атала. *Сангвиник, холерик, меланхолик* һәм *флегматиклар* була. Башка хисләр бер үк вакытта иҗтимагый тирәлек һәм кешенең эчке дөньясы белән билгеләнә. Күп кенә хисләрне тәрбияләргә мөмкин генә түгел, бу хәтта зарури да. Мәсәлән, намуслылык, бурыч, өлкәннәргә хөрмәт хисләре. Шулай ук ихтыяр көчен ныгытып һәм тәрбияләп була.

Ихтыяр көче — кешенең үзенә рәхәтлек китерми торган яисә бернинди биологик ихтыяҗ булмаган нәрсәләрне башкара, төрле киртәләрне җиңеп чыга алуы. Хезмәтнең нигезендә, тәрбия нигезендә кебек үк, ихтыяр көче ята. Аңа, үзенчәлекле корыч каркаска беркетелгәндәй, бөтен хисләр дөньясы диярлек беркетелә. Ихтыярый башлангыч хисабына аморф оеткыдан алар кешенең **характерына** йогынты ясый торган тәртипкә салынган бербөтенгә әвереләләр. Характерлар нинди була? Характердан темперамент нәрсәсе белән аерыла?

Характеры булган кеше **шәхес** булды дигән сүз түгел әле. ***Шәхес — кеше иҗтиһатының иң югары ноктасы, аның үз рухи дөньясына кагылышлы җентекле эше нәтиҗәсе ул.*** Характер кешегә индивидуальлек төсмере бирә. Сез характерга ия икән, димәк, сез — индивид, әмма әлегә шәхес түгел.

Хисләргә бай кеше — ***күңел дөньясы*** бай кеше була. Ярдәмчеллек, шәфкатьлелек, ихласлык һәм кичерешләргә нигезләнгән башка шундый сыйфатлар кеше **күңеленә (җанына)** хас. Җанның урыны йөрәк урнашкан төштә дип уйланыла. Дөрес, моны берәү дә төгәл генә белми, әмма күпләр шулай дип ышана. Йөрәктән аермалы буларак, баш бөтенләй бүтән нәрсәләр белән «тулы». Анда интеллект, **аң**, акыл, рух урын алган. Бу сүзләр төрлечә бер үк нәрсәләрне — кеше аңының иң югары дәрәҗә гәүдәләнешен чагылдыралар. **Акыл** һәм **аң**, философлар фикеренчә, кеше психикасының төрле бүлемтекләрендә «яшиләр». Әйтик, дедукциягә һәм индукциягә сәләтлелек — акыл күрсәткече. Ә менә чөтерекле хәлдә көтелмәгәнчә яңа чишелеш таба белү — аң чагылышы. Ул бөтенләй башка, еш кына бары вариантлар санап чыгу һәм формаль-мантыйкый чагыштыру белән бөтенләй туры килми торган сәләтләргә таяна.



Кеше психикасы катламнары

Рухи омтылышларыбыз һәм инануларыбыз дөньясы тагын да катлаулырак.

143 нче биттәге рәсемдә схема рәвешендә кеше психикасының сурәтләнеше китерелә.

Кешенең эчке дөньясының әлеге элементлары катлаулы конфигурацияләр хасил итәләр, шуңа да безнең гамәлләребез — күпчелек очракта мотивларның, максатларның, кыйммәтләр һәм омтылышларның тулаем бер җыелмасы нәтиҗәсе ул. Шундый конфигурацияләрнең берсе — эшчәнлек.

Эшчәнлек — кешенең аңга нигезләнгән эчке (психик) һәм тышкы (физик) активлыгы ул. Эшчәнлекне *максат, чаралар, нәтиҗә, гамәлләр (процесс үзе)* тәшкил итә.

Кайбер гамәлләр кыска вакыт эчендә кылыналар: кадак кагу, күлмәк үтүкләү, кибеткә барып килү. Болар бер чылбырга тезелеп, көн саен кабатлана торгач, без эшчәнлек турында сүз алып барабыз. Кибеткә бер тапкыр барып килү — ***гамәл***, ә менә анда еш йөрү — ***эшчәнлеккә*** әверелә. Хуҗалык белән бәйле аерым гамәлләр берләшеп йорттагы эшчәнлеккә (яисә эшкә) әйләнә. Кая карама, бу нәкъ шулай була. Шөгыль, эш, эшчәнлек — болар янәшә торучы төшенчәләр. Кешелек җәмгыяте кешеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә алга бара.

Эшчәнлек җәмгыятьнең барлык өлкәләре өчен хас булганга, ул җәмгыять яшәеше рәвешләре нигезендә төрләргә бүленә. Шул рәвешчә, әйтик, сәяси эшчәнлек — сәясәт өлкәсенә, икътисади эшчәнлек икътисад өлкәсенә карый һ.б.

Хәзерге җәмгыятьтәге эшчәнлекнең танып белү, мәгълүмати, интеллектуаль, рухи, иҗади дигән әйдәүче төрләре бар. Рухи кыйммәтләргә ия булу, мөмкинлек һәм теләк кенә булудан бигрәк, катгый ихтыяҗга әверелә. Фундаменталь фәннәр, югары технологияләр, мәгариф һәм мәдәният үсеш алмаган җәмгыять дөнья цивилизациясе үзәгенә әверелә алмый. Һәм киресенчә. Матди кыенлыклар, икътисади һәм җитештерү өлкәсендә кыенлыклар кичерүче, әмма интеллектуаль мөмкинлекләрен җуймаган ил, кыска вакыт эчендә артталыгын җиңеп, алдынгы дәүләтләрне куып җитәргә сәләтле.

Төшенчәләр: *инстинктлар, рефлекслар, ихтыяҗлар, гадәтләр, мотивлар, хисләр, аң, рух, шәхес, эшчәнлек.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Түбәндәге төшенчәләр арасындагы аерманы күрсәтегез: күңел (җан), аң, инстинктлар, ихтыяҗлар, хисләр, гадәтләр.

2. Ни өчен гадәтләр, мотивлар белән чагыштырганда, гадирәк психик күренеш буларак танылалар? Җавабыгызны дәлилләгез.

3. Гаиләгез әгъзаларыннан берәрсенең, нинди дә булса танышыгызның яисә дустыгызның рухи портретын сурәтләп бирегез. Нинди сыйфатларга аеруча игътибар юнәлтер идегез?

4. Сезнең кайчан да булса ихтыяр көчегезне сынап яисә тәрбияләп караганыгыз булдымы? Шул турыда сөйләгез.

5. Мотивлар мәсьәләсен конкрет мисалларга, мәсәлән, үзегезнең гамәлләрегезгә яисә әдәби геройлар гамәлләренә таянып аңлатыгыз.

***6.** Сез ничек уйлыйсыз, кешедә — рухи байлыкмы, яисә күңел байлыгымы — кайсысы өстенлек итәргә тиеш? Үз карашларыгызны дәлилләгез.

***7.** Рухи, интеллектуаль, мәгълүмати эшчәнлекләрнең һәм сәнгать эшчәнлегенең үзара бәйләнешенә характеристика бирегез. Аларның охшашлыгы һәм аерымлыгы нидә?

? Проблема. Һәр кеше дә шәхес була аламы?

✍ **Практикум.** Әлеге гыйбарәләрне дәвам итегез:

1. Гадәтләр түбәндәгеләр – ...
2. Безнең хисләребез түбәндәгеләр белән билгеләнә – ...
3. Эшчәнлеккә түбәндәгеләр кирә – ...
4. Эшчәнлек гамәлдән түбәндәгеләр белән аерыла – ...

§ 19 (§40). Җәмгыятьнең шәхескә йогынтысы

Шәхес, биологик түгел, мәдәни эволюция җимеше булганлыктан, шәхескә иң зур йогынты ясаучы да табигать түгел, бәлки җәмгыять була. Җәмгыятьнең шәхескә йогынтысы уңай да, тискәре дә була ала. Беренче очракта — шәхес үсә, икенче очракта исә — йомыла.

Үз гомеренең өчтән берен кеше катлаулы иҗтимагый мөнәсәбәтләр мохитында яшәргә өйрәнүгә сарыф итә. Соңгы вакытларда белгечләр мондый осталыкка кешеләр бөтен гомерләре буе өйрәнәләр, дигән нәтиҗә ясадылар. Хәзерге чорда җәмгыять шундый таләп куя. Бу процесс *социальләшү* дип атала.

Кеше үзенең ерак бабалары — хайваннардан гына түгел, бәлки үзенең ата-анасыннан, әби-бабасыннан мираска бик күп нәрсә ала. Туганда адәм баласы, җәнлек-җанвар балалары белән чагыштырганда, ярдәмгә мохтаҗрак булса да, иҗтимагый тәҗрибәне үзләштерүгә әзерлеклерәк булып чыга. Башкача булса, аны мантыйкый фикерләүгә һәм символик телгә өйрәтеп булмас та иде. Галимнәр күпме генә тырышмасын, маймылны моңа өйрәтеп булмый бит менә.

Социальләшү *балачакта*, кеше шәхесенең 70%ы тирәсе формалашкан чорда башланырга тиеш. Шуннан да соңга калынса, төзәтелмәслек процесслар башланырга мөмкин. Балачакта социальләшүгә *нигез* салына, һәм шуның белән бергә, бу аның өчен иң хәтәр чор да. Җәмгыятьтән аерылган балалар социаль җәһәттән «үлек» була, ә олы кешеләр, тирән фикерләргә һәм дөньяны тамаша итүгә бирелеп, кайчак аңлы рәвештә ялгызлыкка омтылалар. Ихтыярларыннан тыш һәм озак вакытка җәмгыятьтән аерылып торырга мәҗбүр булган олы кешеләр рухи һәм иҗтимагый яктан югалмыйлар. Киресенчә, авырлыкларны җиңә-җиңә, алар шәхес буларак үсә баралар, өр-яңа яклардан ачылалар.

Социальләштерүнең балаларны олылар тормышына әзерләү буларак аңлатылуы турында сөйләгән идек инде. Бу ике дөнья ни белән аерыла соң? Алар арасында шул дәрәҗәдә аерымлыклар бармы соң? Берсеннән икенчесенә күчәр өчен махсус әзерлек шулай ук кирәкме икән?

Балалар һәм өлкәннәр буй, физик көч, акыл сәләте һәм аны файдага эшләтү, хәтәрлеккә мөнәсәбәт, акыл һәм хиснең үзара мөнәсәбәте, тупланган белемнәр күләме, зирәклек, четерекле хәлләрдә дөрес

карарлар кабул итү, өстәмә җаваплылык йөкләргә әзер тору кебек үлчәмнәр белән бер-берсеннән аерылалар. Бик теләсәк, бу исемлекне дәвам итеп тә булыр иде.

Әмма төп аерымлык — *социаль рольләрне башкаруда.* **Балалар** — *халыкның иҗтимагый статуслары һәм иҗтимагый рольләре булмаган бердәнбер категориясе.* Әлбәттә бу очракта «сабый», «ир-хатын җенесе», «ул-кыз», «әне» һ.б. кебек, алар тарафыннан әле тулысынча аңлап та бетерелмәгән статусларны исәпкә алмыйбыз. Балалар матди байлыклар житештермәгәнлектән һәм халыкның икътисади мөстәкыйль категориясенә кермәгәнлектән, аларның һөнәри, икътисади һәм сәяси статуслары һәм рольләре булмый. Статусларның асылын тәшкил итүче хокуклар һәм бурычларның ни икәнен алар белми. Балалар инженер, табиб, укытучы, парламентарий һәм башкаларның бурычларын белми. Өлкәннәр күбесе турында аларга сөйләгән булса да, җаваплылык, иҗтимагый нормалар аларга таныш түгел.

Иҗтимагый рольләр турындагы теоретик һәм якынча белемнәренә карап кына балаларның аларны үзләштерүе турында сүз алып барырга иртәрәк. Рольләр башкаруларына карамастан, алар үзләрен иҗтимагый роль таләпләренә туры килерлек итеп тотмыйлар: иҗтимагый тормышны бары уен аша гына өйрәнәләр. Олы кешеләр, бизнестагы уен методы аша өйрәтүне санамаганда, беркайчан да роль уйнамыйлар.

Ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләр социальләшүнең хәлиткеч моменты була. Алар *иң җаваплы моментта* — кеше яхшылыкка һәм явызлыкка аеруча бирешүчән булган, бар яңаны бик тиз сеңдергән вакытта, ягъни сабыйлык чорында үзләрен нык сиздерә. Икенче бер характерлы сыйфат — мөнәсәбәтләр бөтен гомер буена дәвам итәләр, шулай булгач, аларның *тәэсире дә дәвамлы* була. Өченче сыйфат — ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләр кешелек җәмгыятендәге барлык мөнәсәбәтләрнең иң тыгызы һәм иң якыны булуда.

Бик күпләр **ата-ана хисе** кешегә биологик юл белән күчә һәм тәүге сабые дөньяга килгәч уяна, дип ышаналар. Дөрестән дә, кошлардан алып имезүчеләргә кадәр барлык тереклек ияләренең ата-ана буларак сабые турында кайгыртуы геннар дәрәҗәсендә программалаштырылган. Әмма адәм балалары өчен бу — хакыйкатьнең яртысы гына. Ата-ана хисе — иң беренче нәүбәттә аларга җәмгыять йогын-

тысында көчкән. Бары тик адәм затлары гына аңлы рәвештә баласын ташлап китә яки башка бер гаиләгә тәрбиягә яисә дәүләт кайгыртуына тапшыра. Бары тик кешелек җәмгыятендә генә тәрбиячесез калган балалар өчен махсус йортлар һәм ата-ана бурычын яхшы үтәгән өчен — бүләкләү, яисә начар үтәгән өчен җәзага тарту чаралары системасы уйлап чыгарылган.

Сакланып калган чыганакларга караганда, бик борынгы заманнарда ук инде сабыйларны үз ата-аналары ук үтерү, язмыш кочагына ташлау, коллыкка сатып җибәрү, закладка салу, гарипләндерү, куркуда тоту һәм көчләү очраклары булган. Мондый гамәлләрне заманының тирән акыллы һәм белемле кешеләре аклаган. Борынгы грек философы Аристотель гарип балаларны ашатып-эчертеп тору мәҗбүри түгел дип санаган, ә Борынгы Рим акыл иясе Сенека зәгыйфь һәм гарип балаларны батырып үтерергә тәкъдим иткән. Борынгы Спартада физик яктан зәгыйфь балаларны юкка чыгаруны дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрәләр. Аларга кадәр бик күп элек борынгы кабиләләрдә корылык, ачлык хөкем сөргән, ризык житмәгән елларда сабыйлардан котылу гадәти булган. Урта гасырлардан калган кулъязмаларда ата-аналарның үз балаларын кыйнаулары, мыскыллаулары, кансызлык һәм битарафлык күрсәтүләре турындагы мәгълүматлар гаять күп. Русларның «Домострой» дип аталаган көнкүреш кагыйдәләре һәм күрсәтмәләре җыентыгы (XVI гасыр) балаларның ата-анага берсүзсез буйсынырга тиешлеге рухы белән сугарылган. 1649 ел Уложениесенә караганда, балаларга ата-аналарына каршы шикаять бирү тыелган. Баласын үтергән өчен ата-

ны яисә ананы бер елга төрмәгә утыртканнар, ә атасын яки анасын үтергән ул яисә кыз үлем җәзасына хөкем ителгән.

Шунысы гаҗәп, Европаның һәм Азиянең күпчелек илләрендә XX гасыр башына кадәр диярлек *ата-ананың баласы алдындагы җаваплылыгы дигән төшенчә бөтенләй булмый. Киресенчә, балаларның ата-аналары алдындагы җаваплылыгы* гаять күпертелгән була. Шулай итеп, кешелек тарихының буеннан-буена диярлек балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләре тигезсез булган: берәүләренең җаваплылыгы арттырылган, икенчеләренеке, киресенчә, киметелгән.

Бары XX гасырда гына ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрдә кискен борылыш барлыкка килә. Алар кеше асылы өчен табигый эзгә төшә. *Партнерлык һәм үзара җаваплылык принцибы барлык цивилизацияле илләрдә гражданнар хокуклары системасына кертелгән.* Бер гаиләдәге балалар саны бу вакытта кинәт кенә кими һәм аларның кадере арта. Ата-аналар үз балалары хакына, ә алары үз чиратында үзләренең булачак балалары хакына яшәргә тиеш, дигән фикер кешелекне киредән гуманлылык эзенә төшерә һәм социальләшүнең табигый чылбырын ялгый.

Күп гасырлык үсеше дәвамында җәмгыять ата-аналарга кагылышлы кыйммәтләрнең, гореф-гадәтләрнең, нормалар һәм тәртип кагыйдәләренең, иҗтимагый контрольнең гаять катлаулы системасын (тән җәзасы, мирастан мәхрүм итү, өлкәннәргә ихтирамлы булу, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү) барлыкка китергән.

Социальләшүнең актив чоры *үсмерлек* белән тәгәлләнә. Гадәттә 13 яшьтән алып 19 яшькәчә булган яшь кешеләрне үсмерләргә кертәләр (аларны әле **тинэйджерлар** дип тә атыйлар). Бу чорда үсмерләр билгеле бер психологик күчешләр китереп чыгаручы мөһим физиологик үзгәрешләр (шуларның берсе — җенси җитлегү) кичерәләр: капма-каршы җенескә тартылу, кайчак бөтенләй сәбәпсез агрессивлык күрсәтү, җиңел акыл белән хәтәр эшләр кылуга омтылу һәм аларның ни дәрәҗәдә куркыныч булуын бәяләүгә сәләтсезлек, юри күзгә ташланырлык итеп бәйсезлеккә омтылу.

Психофизиологик үзгәрешләр социальләшү барышына һәм эчтәлегенә йогынты ясый алмыйлар. Инноватикага һәм иҗатка омтылу, берьяктан, бернинди дә авторитетлар алдында баш имәү, икенче яктан, күзгә бәрелеп тора торган автономия һәм бәйсезлек *яшьләр*

субкультурасы дип аталучы үзенчәлекле күренеш барлыкка китерәләр. Ул наркотиклар, секс һәм көч куллану кебек өч тискәре сыйфатны, күренеш-символны күз алдына бастыра. Үсмерлекне «авыр чор», «борылыш чоры» дип атыйлар. Бу вакытта яшьләр кечкенә балаларга хас булган тулысынча тыңлаучанлыктан тыйнак сансызлыкка — яшертен генә ата-аналарына буйсынмаута күчәләр. Әгәр моңа кадәр аларның дөньяга карашы ата-аналарыныкыннан аерылмаса, хәзер исә *аларның параллель рәвештә үз карашлары һәм кыйммәтләр системасы* барлыкка килә, болар ата-аналар позициясе белән өлешчә генә, шулай ук өлешчә яшьтәшләре карашлары белән тәңгәл килә.

Бу чорда шәхеслек нигезе, дөньяга караш тулысынча формалаша. Үз «Мин»ен аңлау үсмергә ата-анасы, дуслары, әйләнә-тирәдәге кешеләр тормышында үзенең нинди урын биләүен ачыклау аша килә. Шул ук вакытта тормыш, яшәү мәгънәсен яңача аңлатырга тырышу белән бәйле әхлакый ориентирларны даими эзләү күзәтелә. *Үсмерләр* һәм яшь *кешеләр* әйләнә-тирәдәгеләрнең *тискәре бәяләренә үтә сизгер булалар.* Алар үзләренең киеменә, тышкы кыяфәтенә, үзләрен тоту рәвешенә, танышларына, ягъни «Мин»нең иҗтимагый тирәлеген һәм иҗтимагый символикасын тәшкил итүче барнәрсәгә карата булган тискәре бәяләрне аеруча авыр кичерәләр. Ахыр чиккә җиткерелгән мөстәкыйльлек үсмер бәяләренең кискенлегендә чагылыш таба: күпчелек тинейджерлар өчен бары аларга охшаган нәрсәләр генә яхшы һәм дөрес.

Психофизиологик җитлегү тинейджерларның социаль-икътисади хәлен үзгәртми диярлек. Ата-аналарның һәм үсмерләрнең статусы элеккечә үк туры килми: ата-аналар акча таба, балалары һәм милекнең кагылгысызлыгы өчен әхлакый һәм хокукый җаваплы була, иҗтимагый тормышта һәм җитештерү эшчәнлегендә катнашалар. Өлкәннәр — милекчеләр, файдаланучылар, опекуннар, җитештерүчеләр, законнар чыгаручылар, кулланучылар, яклаучылар һ.б. Ә тинейджерларның исә икътисади мөстәкыйльлеге юк, алар һаман да әле иҗтимагый яклаута мохтаҗ һәм хокук мөнәсәбәтләрендә катнашмыйлар, рольләре чикләнгән. Үсмерләр милекчеләр дә, файдаланучылар да, җитештерүчеләр дә, законнар чыгаручылар да түгел. Алар — бары тик кулланучылар гына. Хокукый яктан мөһим карарлар кабул итә алмасалар да, психологик җәһәттән алар моның өчен җитлеккән була инде. Әмма ата-аналары аларны чиклиләр. Каршылыкларның башлануы нәкъ шушыннан килеп чыга.

Моның белән бәйле рәвештә социологлар тинейджерларның өлкәннәр белән чагыштырганда ***хокуклары*** һәм ***бурычлары кимрәк*** булуы турында сөйлиләр. Азрак мөмкинлекләргә ия булганга, тинейджерлар төрле әхлакый проблемалар белән очрашалар. Бу проблемаларны җитлеккәнлек чорында инде хәл иткәннәр. Тормыш тәҗрибәсенең житенкерәмәве нәтиҗәсендә үсмерләр өлкәннәр белән чагыштырганда күбрәк хаталаналар. Әмма хикмәт хаталарның санында түгел, бәлки сыйфатында, нәтиҗәләренең җитдилегендә: җинаятьчелек, наркотиклар куллану, эчкечелек, җенси азгынлык, шәхескә карата көч куллану. Күп кенә тинейджерлар мәктәптә укуларын ташлыйлар, шуның нәтиҗәсендә табигый социальләшү процессы бозыла. Белем туплауның өзелеп калуы үсмернең киләчәктәге икътисади хәленә йогынты ясый, тора-бара хезмәт базарында аңа эш табу гаять кыенлаша. Алга киткән илләрдә 18 яшьлекләр арасында эшсезлек, олылар белән чагыштырганда, 3 тапкырга артыграк.

Галимнәр җенси азгынлык, исерткеч эчемлекләрне чамасыз куллану һәм артык тәвәкәллек *өлкәннәр ролен уйнарга маташудан* башка нәрсә түгел, дигән фараз әйтәләр. Мөгаен, күпләрнең мәктәпне ташлавына да шул ук нәрсә сәбәптер, чөнки укучы статусы «балалык» буларак кабул ителә. Ул тормышта уңышка ирешүгә, шуның белән бергә яшьтәшләр арасында танылуга да ярдәм итми.

Хәзерге яшьләр берничә буынга бүленә. Алар инде элекке вакыттагы кебек өлкән буынга каршы торучы бердәм буын түгел. Яшьләр арасында идеаллары, кыйммәтләре бер-берсенә туры килми торган берничә буын бар һәм алар бер-берсе белән каршылыкта.

Балалыктан җитлеккәнлеккә аяк басу чорында яшь кешеләр алдында күп кенә катлаулы проблемалар килеп баса, алар бу кыенлыкларны үзләренең балалык тәҗрибәсенә яисә өлкәннәрнең тормыш тәҗрибәсенә таянып хәл итәргә сәләтле булмый. Алар өчен шул ук кыенлыкларга дучар булган һәм бер үк идеалларга һәм кыйммәтләргә таянып гомер итүче ***яшьтәшләр төркеменә*** кушылу ихтыяҗы туа. Бу төркем өлкәннәр субкультурасындагы кебек, үз әгъзаларына зарури ирек һәм бәйсезлек бирә, шул ук вакытта аларны, өлкәннәр сафына әлегә тулысынча кучеп бетмәүләре аркасында иҗтимагый яклауга мохтаҗ булганлыктан, мондый яклаудан һәм эмоциональ бәйләнешләрдән мәхрүм итми. Яшьтәшләр төркеме яшь кешеләр кылган гамәлләрне хөкем итәргә тулысынча хаклы, дип санала. Яшьтәшләре йогынтысын-

да үсмер үзенә читтән, туганнары түгел, ә башка кешеләр, яшьтәшләре күзлегеннән карарга өйрәнә. Яшьтәшләре төркемендә индивид олы кешенең «иҗтимагый киемнәрен» киеп карый.

Гомумән алганда, бала ата-анасы фикеренә колак салган кебек үк төркем фикеренә игътибар итә башлауга, ул сабыйлыктан чыга башлый, дип әйтергә мөмкин. Бу 10–12 яшьләр тирәсендә була. Зуррак үскән саен яшьтәшләр төркеменең бәяләмәләре һәм фикерләре өстенлек ала. Бөтен гомер буена да шулай дәвам итәргә мөмкин: үсмерлек елларыннан башлап, кешенең тормышыннан яшьтәшләре беркая да китми. Җитлеккән кешенең бөтен гомере яшьтәшләренең күпсанлы төркемнәре (эштә, көнкүрештә, ялда) чолганышында уза.

Күпсанлы төркемнәр белән янәшә гомер итеп, кеше аларга йогынты ясый һәм үзе дә алар йогынтысында була, әмма һәрчак үзенең шәхесен, индивидуальлеген саклап калырга тырыша.

Төшенчәләр: *социальләшү, балачак, үсмерлек чоры.*

Сораулар һәм биремнәр

1. Ана булу һәм ата булу институты, тулаем җәмгыятьнең генә түгел, һәрбер кешенең язмышында мөһим роль уйный. Ул безнең тормышыбызда нинди роль уйный? Сезнең шәхесегез формалашуда этиегезнең һәм әниегезнең роле бармы? Алар арасында тәрбия функцияләре ничегрәк бүленгән, кем ни белән шөгыльләнә?

2. Өлкәннәрнең балага йогынтысы һәм, киресенчә, баланың өлкәннәргә йогынтысы чараларын чагыштырыгыз. Нәтиҗә ясагыз.

3. Сезнең шәхесегез формалашуда яшьтәшләрегез төркеменең роле нинди булды?

4. Үсмерләрнең үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре нидән гыйбарәт һәм алар нәрсә белән бәйләнгән?

5. Ата-аналар һәм балалар проблемасына галимнәрнең карашлары һәм җәмгыятьтәге карашлар ничегрәк үзгәрә?

***6.** Балалар һәм өлкәннәр — капма-каршы ике дөнья вәкилләре. Мөстәкыйль рәвештә яки өлкәннәр ярдәменә таянып аларны өйрәнүне дәвам итеп карагыз. Күзәтү объекты буларак үз гаиләгезне (яисә танышларыгыз гаиләсен) сайлый аласыз. Әлеге

ике дөнья арасындагы мөнәсәбәтләрнең нәрсәгә корылуын күзәтегез, нәтиҗәләрегезгә нигезләнеп эссе языгыз.

*7. Үз балачагыгызны искә төшерегез, кече эне-сеңелләрегезне күзәтегез һәм түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

а) Үсә барган саен балаларның роль уйнавында нилəр үзгәрә, 7 яисә 10 яшьтә нәрсә күзәтелә?

б) Балалар уйнамаган вакытларында, әйтик, әниләре аларны кибеткә ашамлыклар сатып алырга җибәргәндә, нинди рольләр үзләштерәләр? Мондый һәм шуңа охшаш очракларда өлкәннәрнең нинди рольләре үзләштерелә?

в) Гомеренең кайсы өлешендә — беренче яртысындамы яисә икенчесендәме — кеше иҗтимагый рольләрне, мәдәни нормаларны күбрәк үзләштерә?

? **Проблема.** Кайбер ата-аналар кием, сөйләм, зәвык һәм үз-үзен тоту рәвеше мәсьәләләрендә улы (яисә кызы) белән яшьтәшләр позициясендә торуны хуп күрәләр, шуның белән аның үсмерлек проблемаларын аңлауларын күрсәтәләр.

Сез мондый караш белән килешәсезме?

Практикум 1. XX гасыр башында АКШның көньягыш штатларында тоткыннарга караңгы төстәге капюшоннар кидергәннәр. Аларга туганнары һәм якыннары белән күрешүне тыйганнар, җәмгыятьтән читләштергәннәр, алар бары Библия белән генә әңгәмәдәш булганнар. Шәфкатьсезлекме бу? Һич юк. Америкалылар һәрбер кешегә яңадан яши башлау мөмкинлеге бирелгән, дип саныйлар. Аны бу мөмкинлектән мәхрүм итәргә ярамый. Әмма төзәлү юлына басу җиңелрәк узсын өчен, элеккеге җинаятьчененң иңнәреннән начар үткәннәре йөген кагып төшерергә кирәк.

Социальләшү теориясеннән чыгып моңа аңлатма бирегез.

Практикум. 2 Белгечләр 20 яшен тутыргач беренче тапкыр наркотик кулланган, 30 ын тутырганда тәмам наркоманга әйләнгән кешеләрнең шәхеслеген югалтмавын раслыйлар. Ә 13 яшендә наркотик куллана башлаган бала исә 23 яшенә җиткәндә шәхес булудан туктый.

Бу нигә шулай? Проблеманы иҗтимагыйлашу теориясеннән чыгып аңлатыгыз.

Йомгаклау

Китапны тәмамлаганда автор кайбер гамәли мәсьәләләргә тукталып китүне кирәк таба. Аларны хәл итү күпчелек очракта сезнең югары уку йортларына керүегезгә йогынты ясаячак. Шулай итеп, сезнең алдыгызда мәктәптә чыгарылыш имтиханнарын тапшыру һәм югары уку йортларына керү имтиханнарына әзерлек тора. Сездән нәрсәләр таләп ителәчәк? Югары уку йортлары укытучылары иң беренче чиратта мәктәп программасы кысаларында җәмгыять белеме буенча сезнең белем дәрәҗәгезне тикшерергә тырышачаклар. Биредә сүз 8–9 һәм 10–11 сыйныфларда тупланган гомуми белемнәр турында бара. Аларны берләштерергә кирәк булачак, чөнки 8–9 сыйныфларда үтелгән темалар 10–11 сыйныфларда өйрәнелми, яңа материалга җай гына һәм эзлекле күчү өчен аларны кыскача кабатлап узу гына каралган.

Ике очракта да тиешле минимумны Мәгариф министрлыгы билгели һәм аны җәмгыять белеме буенча ике мәҗбүри — аерым-аерым 8–9 һәм 10–11 сыйныфлар минимумы тәшкил итә. Әгәр бу дәреслекләрне чагыштырсак, кайбер темаларның кабатлануын күрербез. Мәсәлән, «Җәмгыять даирәләре» дигән тема ике минимумда да бар. Әмма мондый кабатлану бер үк тема ике дәреслектә дә бер үк күләмдә һәм бер үк эчтәлекле булырга тиеш дигән сүз түгел. Кабатлану әлеге теманың дәреслек авторы өчен түгел, бәлки мәктәп укучысы өчен мөһим икәнлеген аңлата. Теманы кабатлау аның әле 10–11 сыйныф өчен имтихан сорауларына кертелү мөмкинлеген дә белдерә. Моннан тыш, кабатланмый торган темалар да бар, бу 8–9 сыйныфтагы темалар сезгә югары уку йортына кергәндә очрамас дигән сүз түгел.

Шулай итеп, чыгарылыш имтиханнарына әзерләнгәндә 10–11 сыйныфлар өчен минимумга игътибар бирегез, ә менә югары уку йортына керү өчен сынау тотарга әзерләнгәндә әле тагын 8–9 сыйныфлар дәреслекләрен дә ныклап кабатлагыз. Моның өчен ике курсны чагыштырып, барлык темаларны берләштерергә, кабатланганнарын төшереп калдырырга кирәк. Автор сезгә югары уку йортына керү өчен «Җәмгыять белеме» курсы буенча имтиханнар тапшырганда белү кирәк булган төшенчәләр һәм проблемалар исемлеген тәкъдим итә.

Профильле белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы. Мәҗбүри өлкә: җәмгыять белеме

Чыгарылыш сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр.

Җәмгыять белемен өйрәнү укучыларга түбәндәге мөмкинлекләрне бирергә тиеш:

— җәмгыять иҗтимагый үсеш юллары һәм рәвешләре, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салу чарасы буларак хокук, иҗтимагый танып белү ысуллары турындагы, киләчәктәге һөнәри белем өчен нигез булачак белемнәрне теоретик һәм гомумиләштереп үзләштерү;

— кеше, кеше эшчәнлеге төрләре һәм аның мотивлары, кешенең дөньяны һәм үз-үзен танып-белүе, социаль альтернативалар шартларында кешенең ирекле һәм җаваплы сайлап алуы турында шәхеснең үсешенә ярдәм итүче белемнәрне теоретик үзләштерү;

— социология, политология, мәдәният, икътисад һәм хокук буенча җәмгыятьнең иң мөһим өлкәләрен һәрьяклап һәм системалы өйрәнүне тәэмин итүче белемнәрне үзләштерү;

— иҗтимагый объектларны чагыштырып анализлау, аларга системалы караш булдыру, классификацияләү һәм типларга бүлү, үз карашларыңны исбатлау өчен дәлилләр китерү, иҗтимагый гамәлләрнең, шулай ук үз гамәлләреңнең дә, нәтиҗәләрен фаразлау ысулларын үзләштерү.

— иҗтимагый фәннең язма һәм сөйләмә телдә массакүләм, шулай ук электрон матбугат чараларында файдаланыла торган төп төшенчәләрен (категорияләрен) иркен куллану;

— төрле чыганаклардан эшкәртелмәгән иҗтимагый

мәгълүматны үзлегеңнән туплау, системага салу, анализлау күнекмәләрен булдыру;

— белем алуның сайланган төп юнәлешендә уку-тикшеренү һәм проект эшчәнлегенең төп ысулларын үзләштерү, фәнни-иҗтимагый танып-белүнең иң мөһим ысуллары, фәнни эзләнүләрнең төп юнәлешләре һәм мәсьәләләре турында мәгълүматлы булу;

— мөстәкыйль тикшеренүләр нәтиҗәләрен төрле социаль практика рефлексиясен (тикшеренү һәм иҗади эшләрне тиешле формага китерү, халык алдында чыгыш ясау, дискуссияләрдә катнашу, социаль проектларны яклау) дә кертеп тәкъдим итү ысулларын һәм рәвешләрен үзләштерү;

— кылган гамәлләрең, чынбарлык вакыйгаларында үзеңнең сайлаган нәрсәләрең өчен җаваплылыкны үз өстеңә алырга әзерләнү, бергәләп карарлар кабул итүдә катнашу, килеп туган низагларны басым ясамыйча гына җайга салу.

— хезмәт базарындагы хәл-торыш турындагы мәгълүмат алу һәм аннан файдалану, һөнәри мөмкинлекләреңне бәяләү, аларны тормышка ашыру юлларын билгеләү.

Белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

Җәмгыять

Катлаулы, динамик система буларак җәмгыять. Җәмгыятькә бәйле системалар, иң мөһим иҗтимагый институтлар һәм мөнәсәбәтләр. Төрле үсеш баскычларында җәмгыять белән табигатьнең үзара йогынтысы. Мәдәният феномены. Мәдәният һәм цивилизация. Җәмгыять төрләре: традицион, индустриаль, постиндустриаль. Иҗтимагый үсеш юллары һәм рәвешләренең күптөрлелеге. Тарихны цивилизация һәм формацияләр ягыннан чыгып өйрәнү. Иҗтимагый алгарыш (прогресс) мәсьәләсе. Тарихның асылы һәм максаты. Хәзерге дөньяның бербөтенлеге, каршылыклары. Глобаль мәсьәләләргә иҗтимагый һәм гуманитар караш. Тынычлык һәм җәбер салмау культурасы. Өйрәнү объекты буларак җәмгыять. Иҗтимагый танып-белү һәм аның үзенчәлеге. Иҗтимагый фәннәр системасы, аларның өйрәнү предметы, тикшеренү ысуллары.

Хокукның җәмгыятьтәге роле. Хокукның табигате. Иҗтимагый һәм шәхси хокук. Хокук системасы төрләре. Кеше хокуклары системасы барлыкка килүнең төп этаплары. Хокукый аң. Хокукый нигилизм. Хокук мәдәнияте. Хәзерге Россиядә хокукның үсеше.

Кеше

Биологик, иҗтимагый һәм мәдәни эволюция продукты буларак кеше. Кеше асылының каршылыклылыгы, аның табигате турындагы фәнни бәхәсләр. Эшчәнлек төрләрен төркемләү һәм аның этәргечләре. Кеше аңының табигате. Кешенең җирдә яшәвенең максаты һәм мәгънәсе. Шәхес, аның җәмгыятьтәге тормышы һәм тәрбиясе. Шәхес буларак үзбилгеләнү мәсьәләсе. Кешенең рухи тормышындагы катлаулылыклар һәм каршылыклар. Дөньяга караш, аның төрләре. Шәхеснең тормыш кыйммәтләре һәм аның маяклары. Аңга нигезләнгән һәм нигезләнмәгән гамәлләр. Үз-үзеңне аңлау һәм тормышта үз урыныңны табу. Җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту. Шәхес ирегенең һәм җаваплылыгының бербөтенлеге. Өйрәнү объекты буларак кеше. Гуманитар белем, аның үзенчәлеге һәм тикшеренү ысуллары.

Дөньяны хис белән һәм рациональ танып белү. Танып белү эшчәнлеге юллары һәм ысуллары, аның чикләнгәнлеге. Хакыйкать һәм аның критерийлары. Хакыйкатьнең шартлылыгы. Кешелек гыйлеме рәвешләренең күптөрлелеге. Фәнни танып-белү, аның ысуллары. Законнар һәм категорияләр. Иҗтимагый һәм гуманитар гыйлем.

Иҗтимагый тормышның төп өлкәләре

Мәдәни һәм рухи тормыш. Мәдәни күренешләр, мәдәният дәрәҗәләре һәм төрләре: халык мәдәнияте, массакүләм һәм элитар мәдәниятләр; мәдәният һәм субкультура, яшьләр субкультурасы. Дөнья мәдәни системалары диалогы. Мәдәниятнең бер өлеше буларак массакүләм мәгълүмат чаралары, аларның җәмгыятькә йогынтысы. Сәнгать, аның төрләре, төп юнәлешләре, кешегә йогынтысы. Эстетик мәдәният. Дин феномены, аның җәмгыятьтәге роле. Дини аң үзенчәлеге. Дөнья диннәре һәм милли дин. Хәзерге дөньяда дин. Фән, аның иҗтимагый функцияләре. Фәнни гыйлемнең дифференциациясе һәм интеграциясе. Фән этикасы һәм галимнең җаваплылыгы. Хәзерге дөньяда мәгарифнең үсеш тенденцияләре. Кешенең өзлексез белем алуы һәм үзлегеннән белемен күтәрүе. Әхлак, аның категорияләре. Әхлакый мәдәният. Ватанпәрвәрлек һәм гражданлык. Россиядә рухи тормыш үсеше тенденцияләре.

Җәмгыятькә бәйле система буларак икътисад. Җәмгыятьнең икътисади үсеш дәрәҗәсе һәм аның күрсәткечләре. Россиянең хәзерге дөньядагы урыны. Икътисадның һәм сәясәтнең үзара бәйлелеге. Икътисади нәтиҗәлелек һәм социаль гаделлек. Икътисад һәм әйләнәтирә мохит. Икътисади эшчәнлекнең хокукый нигезләре. Икътисади сәясәт. Тотрыклы үсеш. Икътисади мәдәният.

Социаль мөнәсәбәтләр һәм үзара йогынтылар. Социаль структура, аның формалашу этаплары. Социаль берлекләрне төркемләү. Социаль бүленеш. Социаль мәнфәгатьләр. Социаль тигезсезлек һәм социаль гаделсезлек мәсьәләсе. Социаль мобильлек, аның төрләре, хәзерге чордагы үзенчәлекләре. Үсмерлек чорында шәхеснең иҗтимагый рольләре ишәю. Иҗтимагый статус һәм абруй. Иҗтимагый нормалар төрләре. Шәхеснең үз-үзен девиант тотышын төркемләү, аның сәбәпләре һәм аны кисәтү. Иҗтимагый контроль һәм кешенең үз-үзен контрольдә тотуы. Этник берлекләр. Этнос һәм милләт. Милләтара хезмәттәшлек. Милләтара мөнәсәбәтләр культурасы. Милли характер һәм менталитет. Милли сәясәт. Иҗтимагый институт буларак гаилә. Традицион гаилә кыйммәтләре һәм хәзерге җәмгыятьтә аларның кризисы чыганаклары. Көнкүреш мөнәсәбәтләре. Иҗтимагый төркем буларак яшьләр. Хезмәтнең иҗтимагый аспектлары. Иҗтимагый партнерлык. Иҗтимагый конфликтларның асылы һәм аларны хәл итү стратегиясе. Этник-иҗтимагый низаг. Иҗтимагый мәдәният. Хәзерге Россиядә иҗтимагый процесслар.

Җәмгыять хәятын җайга салучы буларак сәясәт. Сәяси институтлар һәм сәяси мөнәсәбәтләр. Хакимият, аның килеп чыгуы, төркемләү, ресурслары. Сәяси система. Сәяси система төрләре. Сәяси институт буларак дәүләт. Дәүләт хезмәте. Дәүләт бюрократиясенең асылы. Сәяси режимнарны төркемләү. Сәяси идеология. Заманның төп идея-сәяси агымнары. Күппартиялелек. Сәяси лобби куллану. Сәяси лидерлык. Лидерлыкны төркемләү. Гражданлык җәмгыятенең төп сыйфатлары. Хокукый дәүләт, аның билгеләре. Сәяси институт буларак массакүләм коммуникацияләр чаралары. «Паблик рилейшенс» технологияләре. Сәяси процесс. Сайлау системалары һәм электораль процесс. Сәяси иҗтимагыйлашу. Сәяси катнашу. Сәяси низаглар, аларны хәл итүнең юллары һәм ысуллары. Сәяси культура. Россиянең сәяси традицияләре һәм үсеш тенденцияләре. Халыкара сәясәт.

Дәреслектә барлык сорауларга җавап тапмавыгыз да ихтимал. Шул ук вакытта китапта мәҗбүри минимумнан артып киткән мәгълүмат та күп. Дәреслек һәм минимум берсе икенчесеннән нәрсә белән аерыла? Минимум — иҗтимагый белемнәр мохитында бары төп юнәлешләрне генә күрсәтүче компасыгыз ул. Җыелма минимумга керүче төшенчәләр топонимика функциясен башкаралар (topos — урын — һәм onyma — исем, атама). Алар теге яисә бу мәсьәлә белән якыннан танышу өчен нинди урамнарга, мәйданнарга һәм тыкрыкларга борылырга кирәклеген күрсәтәләр. Әмма дәреслек төшенчәләрне атап чыгу белән генә чикләнә алмый. Ул төшенчәләргә кыскача билгеләмә бирүче сүзлек тә була алмый хәтта. Дәреслекнең төп бурычы исә — теге яисә бу фән нигезләре турында системага салынган белемнәр бирү, җәмгыять алдында торган мәсьәләләрне ачыклау, мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтү.

Җәмгыять белеменең мәктәп курсы югары уку йортларына керү имтиханнарына мөстәкыйль әзерләнү өчен җитәрлек булырга тиеш. Ә алар исә елдан-ел катлаулана бара. Төрле уку йортларында, алар нинди генә юнәлешле булмасын — юридик яисә халыкара мөнәсәбәтләр институтларымы ул, икътисади академияме, әллә бүтәнме — абитуриенттан әлеге учреждение профиле буенча «алдынгы» белемнәр таләп итәчәкләр. Димәк, җәмгыять белеменең мәктәп курсы сезгә кирәкле белемнәрне бирергә тиеш.

Фундаменталь белемнәр бирүче дәреслек гади була алмый. Аңлаешлы булсын өчен, аның материаллары камил әдәби тел белән бәян ителергә, барлык терминнары һәм төшенчәләре шәрехләнергә, кызыклы фактлар, тормышта була торган хәлләр китерелергә, материал проблемалы бирелергә, аңны үстерә торган биремнәр ярдәмендә укучыны актив фикер алышуга тартырга тиеш. Әгәр боларның барысы, яки барысы диярлеге дәреслектә бар икән, катлаулы материал да хәтта тирән кызыксыну тудырачак һәм шиксез файда китерәчәк.

Безнең фәнебез һәм педагогия өлкәсендәге тәҗрибәбез билгеләнгән юнәлештә хәрәкәт итә башлаган, беренче адымнарын атлаган гынадыр әле. Бу алай куркыныч түгел. Иң мөһиме дөрес юнәлеш сайлау. Максатыбыз ачыкланган инде: үз белемнәренең киңлеге белән генә түгел, бәлки тирәнлеге, төплелеге һәм нигезлелеге белән дә һәрчак аерылып торган зыялыларыбызның дөнья базарында конкурентлыкка сәләтле дәвамчыларын әзерләү.

Мәктәп җәмгыять белеме системасы, үсеш чорындагы барлык баскычларны һәм кыенлыкларны җиңеп, XXI гасыр яшьләренә тормышта юл күрсәтергә тиеш. Иң элек аның фундаменталь булуы, ягъни аналитик фикер, проблема һәм бурычларны аңлауда мөстәкыйльлек шарт. Мондый стиль, аерып әйткәндә, Мәскәү физика-технология институтында формалаштырыла. Биредә 70 нче елларда ук инде студентларга имтихан вакытында теләсә нинди дәреслектән һәм белешмәлектән файдаланырга рөхсәт итәләр. Аларны сынау башланганчы ук таратып та чыгалар. Имтихан бирүчеләрдән физик процессларны күзаллау, фикри яссылыкта экспериментлар кую һәм проблеманы анализлый белү таләп ителә. Әлбәттә бу очракта студентның куелган таләпләрне оригиналь һәм иҗади башкаруына игътибар бирелә. Башка, аеруча гуманитар югары уку йортларының беренче курсларында исә нинди хәлләргә тап булабыз? Лектор проблеманы ача, бик бирелеп схемалар һәм графиклар сыза, әмма студентлар язып алырга өлгерми калалар. Шуңа күрә мәктәптә укыганда ук конспект ясарга, бик үк әһәмиятле булмаган мәгълүматларны төшереп калдырып, иң мөһимнәрен генә язып алырга өйрәнегез; китаплар һәм өстәмә материаллар конспектлау күнекмәләре булдырыгыз. Укып-белгәннәрегезне дусларыгыз белән бүлешегез, эчтәлеген сөйләгез, телдән сөйләм күнекмәләре булдырыгыз. Алар сезгә югары уку йортына кергәч беренче семестрда ук кирәк булачак. Реферат, башка язма эшләрне ахыргы көнгә калдырмагыз, юкса рәтле берни дә яза алмаячаксыз. Конспектланган лекцияне шул ук кичне укып чыгарга, хәтердә яңартырга, аңлашылмаган урыннарын билгеләп куеп, икенче дәрестә укытучыдан шуларны аңлатуын үтенергә кирәк. Сорау бирү укытучыга сезнең фәнне өйрәнү теләгегез барлыгын аңлатачак, ул исә сезнең белемнәрегезне арттыру өчен тырышачак. Әгәр материалны укып чыкмасагыз, имтихан җиткәч укырмын, дип алып куйсагыз, аңлашылмаган сораулар туплана, ә үзләштерелгәндәй тоелган материал онытыла. Ярты елдан имтихан вакытында сезгә авырга туры килүе мөмкин.

Автор әйтергә теләгән сүзләрнең, зур тормыш юлына аяк басу алдыннан сезгә теләкләренең бик аз өлеше менә шулар. Кыюрак булыгыз. Югары уку йортларында остазларыгыз сезне ачык күңел, якты йөз белән каршы алыр.

Сүзлек

Абруй — авторитет, йогынты; җәмәгатьчелек фикерендә урнашкан статусны хөрмәт итү.

Абсолют ярлылык — шәхеснең кереме аның азыкка, торакка, кием-салымга булган иң гади ихтыяҗларын да канәгатьләндерә алмый торган, яисә тәнендә җанын асрау өчен генә җитәрлек булган халәт.

Абстракт (лат. abstractio — читләтелгән) — читләтелгән, тормыштан аерылган, теоретик.

Автономия — тышкы шартларга бәйле булмау.

Авторитар (лат. auctoritas — хакимият) — шәхси хакимияткә, шәхси диктатурага нигезләнгән.

Авторитет (лат. auctoritas — хакимият) – гыйлемгә, уңай әхлакый сыйфатларга, тәҗрибәгә нигезләнгән йогынты.

Аграр (лат. agrarius) — җиргә, җир биләүгә, җирдән файдалануга кагылышлы, әйтик, аграр мәсьәлә.

Адаптация — физик яисә социаль тирәлеккә җайлашу.

«Ак якалар» — автоматлаштырылган производствода, фәнни һәм гамәли эшләрдә, шулай ук мәгълүмат өлкәсендә мәшгуль хезмәткәрләр.

Акцепт (лат. acceptus — кабул ителгән) — граждан хокукында — тәкъдим ителгән (оферт) шартлар нигезендә шартнамә төзүгә ризалык бирү.

Акциз (франц. accise) — читләтелгән салым төре, сатып алучыга ул кайбер товарларны сатып алганда салына һәм гадәттә әлеге товар бәясенә карата процентларда билгеләнә.

Акча — алмашу мөнәсәбәтләрен гамәлгә ашыру чарасы, гомум эквивалент.

Аллаһка гыйбадәт — Аллаһка ышанучыларның дини хисләре даимилеген һәм активлыгын саклауга юнәлтелгән үзенчәлекле тылсымлы йолалар җыелмасы, изгеләргә, иконаларга һәм сыннарга табыну, руза тоту.

Алыш-биреш — затларның үзләренең граждан хокукларын һәм бурычларын булдыруга, үзгәртүгә яисә туктатуга юнәлтелгән гамәлләре.

Альтернатива (лат. alter — икенең берсе) — мөмкин булган ике (яисә берничә) карарның, кирәкле вариантның берсен сайлап алу зарурлыгы.

Альтруизм (франц. altruisme, лат. alter — башка, бүтән) — башка кешеләр мәнфәгатьләре турында эчкерсез кайгырту, эгоизмның киресе.

Андерсыйныф — җәмгыятьнең бернинди сыйныфка да керә алмый торган элементларны (эчкечеләр, наркоманнар һ.б.) тәшкил иткән катлавы.

Анимизм (лат. anima, animus — җан, рух) — җан һәм рухлар барлыгына ышану.

Аномия (франц. anomia — законсызлык, оешмаганлык) — иҗтимагый аңның җәмгыять кризисы, игълан ителгән максатлар белән аларны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау арасында туган каршылык нәтиҗәсендә кыйммәтләр системасының таркалуы белән характерлана торган халәте.

Антиглобомитлар — икътисадны глобальләштерүгә каршы чыгучылар.

Антропоген йогынтылар (грек. anthropos — кеше, genes — тудыручы) — кеше эшчәнлегенең табигатькә йогынты ясау рәвешләре, мәсәлән, аны пычратуы.

Артефакт (лат. artefactum — ясалган, эшләнгән) — кеше тарафыннан ясалган, эшләнгән әйбер.

Аскетлык (грек. asketes — нинди дә булса күнекмәләр ясаучы) — фәлсәфи мәктәпләр (мәсәлән, киниклар) һәм төрле диннәр (монахлык һ.б.) өчен аеруча хас булганча хисси теләкләрне йөгәнләү яки бастыру, кешенең ихтыяри рәвештә үзен физик җәзалауга, ялгызлыкка дучар итүе.

Ассимиляция — этник йотылу, бер халыкның (кайчак берничә халыкның) икенче халык арасында тулысынча диярлек эреп бетүе.

Атеистлык (франц. atheisme, грек. átheos — алласыз) — Алланы, шуның белән бәйле рәвештә динне инкарь итү.

Атрибутлар (лат. attribuo — бирү) — зарури, әһәмиятле үзенчәлек.

Ачык җәмгыять — бер дәрәҗәдән (стратадан) икенчесенә күчү рәсми яктан берничек тә чикләнмәгән җәмгыять.

Базар — сатып алучылар һәм сатучылар (товар тәкъдим итүчеләр) бергә җыела торган теләсә нинди институт яки механизм.

Байлык — кешенең барлык милкенең бәясен чагылдыра торган акчалата сумма.

Без-төркем — әгъзалары үзара теләктәш булган кече төркем.

Бәя — товар яки хезмәт күрсәтү бирәмлеге өчен түләнә торган һәм алына торган акча (яки башка төр товар я хезмәт) күләме.

Бизнес (инглиз. business) — эшмәкәрлек эшчәнлегенең табыш алуга юнәлдерелгән төре.

Биләү — хуҗалык алып бару, ягъни фактик милеккә ия булу.

Бөтендөнья икътисади системасы — икътисади элемтәләр берләштергән территорияләр яки илләр күплеге.

Бүләкләү — хезмәте өчен кешене матди яисә мораль бүләкләү.

Бурыч — кемгә дә булса йөкләнгән һәм мәҗбүри үтәлергә тиешле гамәлләр һәм йөкләмәләр.

Бюджет — билгеле бер вакытка төзелгән, керемнәр һәм чыгымнар суммасыннан торган финанс планы.

Бюрократия — оештыру структурасына кертелгән, төгәл иерархия, «вертикаль» мәгълүмат агымнары, карарлар кабул итүнең формаль ысуллары һәм җәмгыятьтә аерым статус тенденциясе белән характерланучы профессиональ идарәчеләрнең социаль катлавы.

Вакыт буенча түләү — житештерелгән продукциягә карамастан, эш өчен сарыф ителгән сәгатьләргә карап түләү.

Вакыт бюджеты — аерым бер хезмәткәрнең һәм аның гаиләсенең, шулай ук билгеле бер халык төркеменең вакытны файдалану төрләре буенча аның сарыф ителү бүленешен характерлаучы күрсәткечләр системасы.

Вестернлаштыру (инглиз. western—көнбатыш)—Көнбатыш мәдәнияте кыйммәтләрен Көнбатышныкы булмаган җәмгыятьләргә тарату.

Виза (лат. visus — күрелгән, каралган) — башка илгә керергә, анда йөрергә яки аннан чыгарга рөхсәт бирү турындагы документ.

Виталь (лат. vitalis — тормышчан) — тормышчан.

Вөҗдан — кешенең үз гамәлләренә тәнкыйди карый алу, үз кимчелекләрен тану һәм үкенә белү сәләте.

Гадәти хокук — кешенең үз-үзен тотышының язылмаган, дәүләт тарафыннан санкцияләнгән кагыйдәләре.

Гадәтләр — билгеле бер хәлләрдә кешенең үз-үзен тотышының үзгәрми торган схемасы (стереотиплар).

Гаепсезлек презумпциясе принцибы — бары суд кына кешене җинаятьче дип атый ала һәм аңа җәза билгели ала, дигән кагыйдә.

Гаилә — көнкүреш бергәлеге; үзара ярдәм, әхлакый һәм хокукый җаваплылык белән бәйләнгән, никахка яки кан кардәшлегенә нигезләнгән кече төркем.

Гаилә бюджеты — аерым гаиләнең вакыт берәмлегенә карата (ай, ел) керемнәренең һәм чыгымнарының тулаем суммасы.

Гаиләнең тормыш циклы — гаилә тормышында әһәмиятле, этаплы вакыйгаларның эзлеклелеге — никахлашудан башлана һәм, ир белән хатын аерылган очракта, шуның белән тәмамлана.

Гамәл кылуга сәләтлелек — кешенең мөстәкыйль рәвештә бернинди чикләүләрсез хоукукларын куллану һәм бурычларын үтәү сәләте.

Генотип (грек. genos — ыру, килеп чыгыш, typos — эз, форма, үрнәк) — организмның генетик (нәселдән килгән) конституциясе, барлык геннары, тотрыклы сыйфатлары җыелмасы; аларны буыннан-буынга тапшыру нәтиҗәсендә халык яки этнос үзенең биологик асылын саклый.

Глобальләшү (франц. global – гомуми, лат. globus — шар) — милләтләрне һәм халыкларны якынайта, акрынлап традицион чикләрне бетерә, кешелек дөньясын бердәм системага әверелдерә торган тарихи процесс.

Гореф — кешенең үз-үзен тотышының традицион тәртибе.

Гореф-гадәтләр — җәмгыятьтә аларга карата гаять сакчыл караш урнашкан, бик югары бәяләнә торган массакүләм гамәл үрнәкләре.

Гражданлык — кешенең һәм дәүләтнең хокук һәм бурычларында чагыла торган даими сәяси-хокукый бәйләнеш.

Гражданлык буйсынмавы — хакимияткә күмәк буйсынмау рәвеше.

Гражданлык җәмгыяте — сәяси булмаган мөнәсәбәтләр җыелмасы; киң гражданлык һәм сәяси хокуклар бирелгән, дәүләт белән идарә итүдә актив катнашучы ирекле, суверен шәхесләр берлеген гәүдәләндерүче идеал.

Гражданлык никахы — закон нигезендә теркәлмәгән, ирекле килешүгә нигезләнгән никах.

Девиация (соңгырак чор лат. deviatio — тайпылу) — кешенең үз-үзен тотышында гомуми кабул ителгән нормалардан тайпылуы.

Дәгъва — суд арбитражына яисә өченче як судына гариза; кешенең хокукын яки законлы мәнфәгатьләрен яклауны сорап мөрәҗәгать итүе.

Делинквентлык (лат. delinquens — гаеп эш эшләүче) — социологиядә һәм юриспруденциядә җәза бирелергә тиешле җинаятьчел гамәлләрнең аталышы.

Депривация (лат. privatus — хосусый) (*искергән*) — нормаль тормышта яшәү өчен кирәкле шартлардан мәхрүм булу яисә аларның җитенкерәмәве.

Дәүләт — билгеле бер илнең хакимият режимы тибын (монархия, республика) , идарә итү органнарын һәм структурасын үз эченә алган сәяси оештырылышы.

Дәүләт бурычы — дәүләтнең кайтарылмаган займнар һәм аларның түләнмәгән процентлары буенча бурычларының тулаем суммасы.

Дәүләт бюджеты — дәүләтнең керемнәрен һәм чыгымнарын бер елга бүлеп билгеләп кую.

Дефицит (лат. — deficit — житмәү) — акча яки ресурсларның элегрәк билгеләнгән, планлаштырылган яки кирәкле дәрәҗә белән чагыштырганда кимрәк булуы; чыгымнарның керемнәрдән артып китүе.

Диада — ике кешенең үзара мөнәсәбәте.

Диаспора (гр. diaspora — сибелү) — халыкның шактый өлешенең үзе чыккан илдән читтә яшәве.

Дин (лат. religio — тәкъвалык, изге әйбер, культ предметы) — иҗтимагый аңның (идеология, фәнни белемнәр, гадәти фикерләр кебек үк) гайре табигыйлеккә инану белән аерылып торучы өлкәсе; кеше тормышының мөһим мәсьәләләрен хәл итәргә булышучы инанулар һәм гамәлләр системасы; билгеле бер дингә табынучыларның тормыш рәвешен һәм үз-үзләрен тотышын җайга салучы әхлакый принциплар җыелмасы; күк һәм җирнең гаять тыгыз бәйләнешен чагылдыручы культ инануларын һәм церемония гамәлләрен үтәү; общинаның, бер үк дингә табынучы кешеләр берлегенең үзенчәлекле төре.

Дога — кешенең Аллаһка нинди дә булса үтенеч белән мөрәҗәгате.

Дотация (лат. dotatio — бүләк) — предприятиеләрнең, фирмаларның зыянын каплау өчен дәүләт бюджетыннан бирелә торган акча, хәрби сәнәгатькә, инфраструктура тармакларына һ.б. финанс ярдәме.

Әхлаксызлык — әдәпсезлек, тәрбиясезлек.

Җаваплылык — гаепле кешенең үзе кылган гамәлләрнең күңелсез нәтиҗәләренә таруы.

Җәмгыять — нинди дә булса илнең нигезен социаль структура тәшкил иткән социаль оештырылышы.

Җәмгыятьнең полярлашуы — ике социаль полюсны тәшкил итүче ярлылар һәм байлар арасында керемнәре төрле булу аркасында хасил булган аерманың кинәт кенә шактый үсүе.

Җитештерелгән товарга карап түләү — житештерелгән товар күләменнән чыгып эш хакы түләү.

Җитештерү — икътисади продуктларның барлык төрләрен эшләп чыгару процессы.

Җитештерү хезмәте — продуктлар яки әйберләр (товар) житештерелә торган хезмәт.

Законнар җыелмасы — законнарда теркәлгән хокук.

Зәвыкъ — нәрсәгә дә булса күңел тарту яки мөкиббән булу, күп очракта — нәфислекне тою һәм аңлау хисе.

Идарә — карарлар кабул итү, производствоны оештыру, кешеләр эшчәнлегенә контрольлек итү процессы.

Идарә рәвешләре — хакимиятне оештыру; үзенең формаль чыганагы белән характерлана. Монархиядә ул — король, патша, фиргавен һ.б. Республикада закон буенча хакимият чыганагы — халыкның күпчелеге.

Идол (грек. eidolon, сүзгә сүз — образ, охшаш әйбер) — а) кеше яисә берәр төрле хайван рәвеше бирелгән матди предмет; б) берәр төрле илаһның яисә рухның дини табыну объекты буларак кулланылучы сурәте.

Иерархия (грек. hieros — изге һәм arche — хакимият) — бөтен өлешләрнең яки элементларның югарыдан түбәнгә таба урнашуы.

Иерархия принцибы — А.Маслоу теориясе буенча: һәр яңа буын кешеләренең ихтыяҗлары аларга кадәрге буынның таләпләре канәгатьләндерелгәннән соң гына актуаль була.

Изгелек — а) Аллаһның әһәмиятле характеристикасын; б) үзләренә Аллаһы рәхмәтен «сеңдергән» кешеләр һәм предметларны аңлатучы төп төшенчәләрнең берсе.

Ике карьералы гаилә — ир дә, хатын да хезмәт урынында эшли торган гаилә.

Икътисад — үзара җитештерү, куллану, бүлү, товар һәм хезмәтләр алмашу мөнәсәбәтләрендә катнашучы зур төркем кешеләрнең нәтиҗәле оештырылган эшчәнлеге.

Ил — дөньяның яисә берәр территориянең билгеле бер чикләргә һәм дәүләт суверенлыгына ия булган кисәге.

Имидж — кеше үзенең статусы нигезендә үзен ничек тотарга тиешлеге, әлеге статуста хокуклар һәм бурычлар нинди нисбәттә булырга тиешлеге турында иҗтимагый фикердә урнашкан күзаллаулар җыелмасы.

Импичмент (ингл. impeachment) — югары вазыйфа биләүче затларның җинаятьләре турындагы эшләрне судта карауның һәм аларны җаваплылыкка тартуның аерымлыклы тәртибе.

Индивидуализм (лат. individuum — индивидуум, зат) — индивид мәнфәгатенең төркем мәнфәгатьләреннән яки иҗтимагый мәнфәгатьләрдән өстенлеген тануны аңлата торган төшенчә; шулай ук кешенең әйбәт яшәве, иреге һәм шәхес буларак үсеше — югары максат, ә социаль институтларның һәм төркемнәрнең эшчәнлеге әлеге максатка ирешү өчен нигез һәм чара булып тора дигән идеяләр һәм практик принциплар җыелмасы. Гадәти сөйләмдә индивидуализм дигәндә эгоизмны күздә тоталар.

Индивидуальлек — кешенең үз асылын, башка кешеләрдән аерымлыгын тәшкил итә торган психологик үзенчәлекләре берләшмәсе.

Индивидуум (индивид) (лат. individuum — бүленми торган; зат) — аерым кеше.

Индустриальләштерү — сәнәгать технологиясендә фәнни белемнәр куллану, энергиянең элек кешеләр яисә йөк хайваннары башкарган эшне машиналардан эшләтү мөмкинлеген тудырган яңа чыганакларын ачу.

Индустрия (лат. industria — тырышлык) — сәнәгать төшенчәсенә тәңгәл.

Инноватика, инновация — яңалык, ачыш; яңа технологияләр, идеяләр булдыру һәм гамәлгә кертү.

Инноватор — нинди дә булса ихтыяҗны канәгатьләндерә һәм табыш китерә торган яңа эш уйлап табучы кеше.

Интернет — Җирнең төрле өлешләрендә яшәүче кешеләргә аралашу мөмкинлеге бирә торган глобаль компьютер челтәре.

Интерпол — җинаятьчеләрне эзләү буенча халыкара оешма. Мәскәүдә бүлекчәсе бар.

«Ирекле сәнгать» — урта гасыр университетларында грамматика, риторика, мантыйк, арифметика, геометрия, музыка һәм астрономия кебек фәннәрдән торган курс.

Ихтыяҗ — кешенең яшәү шартларын тәшкил итүче фактларга бәйлелеген чагылдырган халәте.

Ихтыяҗ — сатып алучыларның билгеле бер товарны үзләренең матди мөмкинлекләреннән чыгып сатып алу нияте.

Ихтыяри эшсезлек — тәкъдим ителгән хезмәт хакына эшләргә теләмәү аркасында килеп чыккан вакытлыча эшсезлек.

Ихтыярсыздан эшсезлек — хезмәткәрнең аңа бәйләнмәгән сәбәпләр аркасында килеп чыккан вакытлыча эшсезлеге.

Йола — горефләр яисә ритуал белән билгеләнгән гамәлләр җыелмасы.

Йөкләмә — башка затлар, оешмалар һәм учреждениеләр белән билгеле бер мөнәсәбәтләргә керүче зат үзенә кабул итә торган һәм башкарырга тиешле гамәл.

Кабилә — күп санлы ыруглар һәм кланнардан торган этник бергәлек һәм социаль оештырылыш төре.

Казна караклыгы — дәүләт милкен урлау.

Канун (грек. kanon — норма, кагыйдә) — догма характерындагы нигезләмәләр җыентыгы: 1) чиркәү кануны — догма, культ, чиркәү эшләрен оештыру өлкәсендә христиан чиркәве тарафыннан закон буларак кабул ителгән кагыйдәләр; 2) Библия кануны — Библия китапларының чиркәү тарафыннан «Ходай сулышын өргән» дип танылучы, «Изге Язма» сыйфатында Аллаһка гыйбадәт вакытында кулланыла торган тупланмасы; 3) ныгып урнашкан, гомуми кабул ителгән һәр нәрсә (*күчерелмә мәгънәдә*).

Капитал (лат. capitalis — төп, баш) — кешеләр тарафыннан булдырылып, товарлар җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өчен файдаланыла, табыш китерә торган ресурслар.

Капитализм — хокукый милеккә һәм ирекле (дәүләтнең катнашуыннан башка) базар мөнәсәбәтләренә корылган җәмгыять.

Каста — кешенең анда әгъза булуы фәкать тумышы белән генә билгеләнә торган социаль төркем (страта).

Катлау — гореф-гадәтләргә яисә юридик законга таянып беркетелгән һәм нәсел буенча тапшырыла торган хокукларга һәм бурычларга ия булган социаль төркем.

Керем — хезмәт хакы, пенсия, рента, пособие, алимент, гонорар һ.б. рәвешендә алынган акчаның теләсә нинди суммасы.

Керем салымы — физик затлар кеременнән (хезмәт хакы, өстәмә түләүләр, премияләр, дивидентлар, процентлар, күчемсез милектән керемнәр һ.б.) һәм юридик затлар кеременнән (табышка салым) турыдан-туры алына торган салымнарның бер төре.

Кешенең үз-үзен тотышы дәрәҗәсе — ата-аналарның бала алдында үз-үзләрен тотышы мәдәни нормаларга туры килүе яисә туры килмәве.

Кешесез производство — барлык эшне машиналар башкара торган, роботлаштырылган цехлар һәм предприятиеләр.

Клан (галл. clann — нәсел, токым) — фараздагы борынгы баба исемен йөртүче кан кардәшләр төркеме (клан җиргә уртак милекне, кан үчен, «канат астына» алуны һ.б. саклаган); бүтенге, нигездә чит ил әдәбиятында клан «ырут» атамасына тиң кулланыла.

Коллык — кешеләрне тулы хокуксызлык һәм иң чик тигезсезлек белән янәшә торучы кабалага төшерүнең икътисади, социаль һәм юридик формасы.

Конституция (лат. constitutio — корылыш, төзелеш) — дәүләтнең иҗтимагый һәм дәүләти төзелешен, хакимиятнең вәкаләтле органнарын булдыру тәртибен һәм принципларын , сайлау системасын, гражданнарның хокукларын һәм бурычларын билгели торган төп закон.

Контрмәдәният — өстенлекле кыйммәтләргә каршы торучы, алар белән низагка кергән субъектив мәдәният.

Конфликт (низаг) (лат. conflictus — бәрелеш) — һәр як тарафыннан югары бәяләнә торган нәрсәне үзенеке итү өчен ике яисә берничә кеше, социаль төркемнәр, дәүләтләр бәхәсе, бәрелеше.

Конфронтация (франц. confrontation) — төркемнәр, сыйныфлар, шулай ук аларның мәнфәгатьләре һәм инанулары каршылыгы, бәрелеше.

Коррупция (лат. corruptio — кемне дә булса акчага кызыктырып сатып алу) — вазыйфаи затның хезмәт урынын шәхси баю өчен турыдан-туры файдалануы.

Көндәшлек (конкуренция) (лат. concurrere — бәрелешү) — билгеле бер иҗтимагый олкәдә охшаш максатларга, яхшы нәтиҗәләргә ирешүдә кешеләр, төркемнәр яки оешмаларның ачыктан-ачык ярышуы.

Көч — башка кешеләргә аларның теләкләреннән тыш, үз ихтыярыңны тагу максатында физик йогынты — көч куллану.

Кулланучы — товарлар алучы, хезмәт күрсәтелүче һәм аларны шәхси көнкүреш ихтыяҗларында файдаланучы кеше.

Культ (лат. cultus — табыну) — дини табынуны чынбарлыкта чагылдыру яисә табынучыларга Ходайдан кодрәт (илаһият) иңдерелүне максат итеп куйган гамәлләр (төрле хәрәкәтләр, билгеле бер текстларны уку яисә җырлау һ.б.).

Күп буынлы гаилә — балалардан, ата-аналардан һәм әби-бабайлардан торган гаилә.

Күп партиялелек — илдә ачыктан ачык гамәл кыла торган партияләрнең саны икедән арткан сәяси система.

Кыска вакытлы казначылык векселе — дәүләтнең 1 елга кадәр срок белән чыгарыла торган кыйммәтле кәгазе, гадәттә дәүләт аны соңыннан кире сатып алгандагы номиналь бәя белән чагыштырганда түбәнрәк бәягә сатыла.

Легаль (лат. legalis – законлы) — законлы, танылган, закон рөхсәт иткән.

Легитим — законлы.

Лидер (ингл. leader — алып баручы, җитәкче) — 1) сәяси партия яки иҗтимагый оешма башлыгы; 2) кече төркемнең иң абруйлы әгъзасы; 3) спорт ярышларында катнашып, алда баручы.

Мавыгу — кыска вакытлы тәэсирле һәвәслек.

Манералар — кешенең үз-үзен тотышының тирә-юньдәгеләрнең уңай яки тискәре бәясен алган тышкы формалары; аерымлык сыйфатлары.

Маргинал (франц. marginal — чит-читтагы, кырыйдагы) — бер мәдәниятне, ил, катлау, сыйныф, төркемне ташлап киткән һәм башкаларының кыйммәтләренә, яшәү рәвешенә кушылмаган кеше.

Маркетинг (ингл. marketing — market — базар сүзеннән) — предприятиеләрнең җитештерү-сату эшчәнлеге белән идарә итүнең базарны комплекслы өйрәнүгә нигезләнгән бөтенге системасы.

Матриархат (сүзгә сүз — ана хакимияте) — җәмгыятьтә, гаиләдә, мирас, никах белән бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә һ.б. хатын-кызның өстенлекле булуы белән характерлана.

Мәгълүмати җәмгыять — җитештерү көчләренең нигезен белемнәр һәм мәгълүмат тәшкил итә торган постиндустриаль җәмгыять.

Мәдәни ареал — төрле мәдәниятләрнең төп сыйфатларында уртаклыклар табыла торган географик район.

Мәдәни комплекс — башлангыч элемент базасында барлыкка килгән һәм функциональ яктан аның белән бәйләнгән мәдәни сыйфатлар һәм элементлар тупланмасы.

Мәдәни плюрализм — бер дәүләттә төрле халыкларның дус-тату яшәве.

Мәдәни уртаклыклар — географик урынга, тарихи вакытка һәм җәмгыятьнең социаль төзелешенә бәйсез рәвештә барлык мәдәниятләргә дә хас булган нормалар, кыйммәтләр, традицияләр һәм үзенчәлекләр.

Мәдәният (лат. cultura — эшкәртү, тәрбияләү, белем, үсү, хөрмәтләү) — хәзер яшәүчеләрнең тәртибен җайга сала һәм иртәгә яшәүчеләргә тапшырыла торган традицияләр, гореф-гадәтләр, социаль нормалар, кагыйдәләр җыелмасы.

Менеджер (ингл. manager — идарәче) — предприятиедә, бүлектә, фирмада, оешмада идарә итү буенча белгеч.

Миграция (лат. migratio, migro — күчәм, күченәм) — кешеләрнең бер урыннан икенчесенә күченүе. Тышкыга — илдән илгә (эмиграция, иммиграция), эчкегә – авылдан шәһәргә, бер районнан икенчесенә, вакытлы, сезонлы һ.б. күченүгә аерыла.

Милек — мөлкәткә хокукый ия булу.

Милек мөнәсәбәтләре — нинди дә булса милек яки әйберләр мәсьәләсендә хокукый мөнәсәбәтләр.

Милләт — әгъзалары яшәешенең нигезен уртак кыйммәтләр һәм институтлар тәшкил иткән, территориаль кысалар белән чикләнмәгән автоном сәяси төркем.

Милли азчылык — халыкның төп өлеше яшәгән урыннан яки шул исемдәге дәүләттән читтә яшәүче өлеше.

Мин-концепция — үзең, тулаем дөньяда һәм мохиттә үз ролең турында күзаллаулар системасы.

Мистика — кеше тормышына илаһилык бирү максатында башкарыла торган үзенчәлекле йолалар.

Миф (грек. mythos — риваять) — билгеле бер халыкларда бик борынгы чорларда булган кайбер вакыйгаларны символик чагылдыру буларак тасвирлау.

Мифология — кешенең — коллективка, коллективның — табигый булмаган дөньяга, ә соңгысының — космоска тоташуының га-

ять киң кагыйдәләр системасы (иң беренче кешеләр тарафыннан билгеләнгән гореф-гадәтләрдән башлап).

Мода (франц. mode, лат. modus — чара, ысул, кагыйдә) — тормышның яисә мәдәниятнең нинди дә булса өлкәсендә билгеле бер зәвыкның кыска вакыт хакимлек итүе, кием формалары һәм үрнәкләренең алышынуы, тиз узучы популярлык.

Модернизацияләү — заман таләпләренә җавап бирерлек итеп үзгәртү, камилләштерү (мәсәлән, җиһазларны модернизацияләү)/

Монополия (грек. monos — бер, бердәнбер һәм poleo — сату-алу итәм) — эшчәнлекнең нинди дә булса өлкәсендә дәүләтнең (мәсәлән, тышкы сәүдә монополиясе), оешмаларның, фирмаларның һәм башка шундыйларның кагылгысыз хокукы; тар мәгънәдә – базардагы тәкъдимнәрнең гомуми күләменә һәм товар яки хезмәт күрсәтүләрнең бәясенә йогынты ясарга сәләтле аз санлы (сирәк кенә – бердәнбер) сатучылар булуын характерлый торган хәл.

Мораль (лат. moralis – әхлакый) — гадәти гореф-гадәтләрдән һәм традицияләрдән аермалы буларак яхшылык һәм явызлык, бурыч, гаделлек һ.б. идеалларына нигезләнгән әхлакый нормалар җыелмасы; мораль таләпләрен үтәү бары тик рухи йогынты (иҗтимагый бәяләү, хуплау яисә гаепләү) рәвешләре белән генә санкцияләнә; аларга мәңгелек рухи идеаллар, шулай ук тарихи үзгәрүчән нормалар һәм принциплар керә; мораль махсус фәлсәфи фән — этиканың өйрәнү предметы булып тора.

Мотив (франц. motif, лат. moveo — хәрәкәтләндерәм) — кешенең үз-үзен тотышының акылга нигезләп аңлатыла торган сәбәбе.

Натуральләштерү — затны аның үз үтенече буенча нинди дә булса дәүләткә гражданлыкка яисә подданныйлыкка кабул итү (мәсәлән, бик озак еллар шул дәүләттә яшәгәннән соң).

Неолит революциясе (неолит — яңа таш гасыры) — аучылыктан һәм җыючылыктан игенчелеккә күчү.

Нәрсәгәдә булса ирешүне мотивлаштыру — кешенең камилләшүгә, хезмәт баскычыннан югары күтәрелүгә, иҗади алгарышка ачыктан-ачык көчле омтылышы.

Нәфис мәдәният — сүз, музыка, театр, сынлы сәнгать һәм башка шундый сәнгать төрләре җыелмасы; сәнгать эшчәнлегенең продукты һәм процессы, атап әйткәндә, сәнгать әсәрләрен тудыру, саклау, тарату, аңлау, бәяләү, өйрәнү, шулай ук рәссамнарны, тама-

шачыларны, тәнкыйтьчеләрне, сәнгать эшлеклеләрен тәрбияләү дә шуңа ук кирә.

Никах — ир белән хатынның бер-берсенә, аларның икесенең үз балаларына, туганнарына, тулаем җәмгыятькә карата хокукларын һәм бурычларын билгеләүче формаль күрсәтмәләр.

Никах контракты — ир белән хатынның уртак милекне тотуының, бер-берсен матди яктан тәэмин итүенең гомуми шартларын билгеләүче юридик документ.

Норма (лат. norma – җитәкче башлангыч, кагыйдә, үрнәк) — социологиядә төркемдәге яисә җәмгыятьтәге формаль яки формаль булмаган кагыйдәләр җыелмасы.

Нуклеар гаилә (лат. nucleus — төш) — ата-анадан һәм балалардан, социаль һәм биологик төштән (нәсел үрчетү һәм иҗтимагый элемтәләр өчен житәрлек) торган гаилә.

Община — берничә йөз кешенең кан-кардәшлеге, никахлар, күмәк хезмәт, үзара ярдәмләшү, территорияне бергәләп саклау аша үзара берләшүе.

Олигополия (грек. oligos — аз санлы һәм poleo – сатам, сату итәм) — тармак продукциясенең төп массасын житештерүгә һәм сатуга базарда ярыша торган берничә эре фирманың монополия урнаштыруы.

Оферта (лат. offero — тәкъдим итәм) — граждан-хокукый шартнамә төзергә тәкъдим ясау.

Оят — 1) эчке контроль механизмы; б) кешенең кабул ителгән нормаларга яки әйләнә-тирәдәгеләрнең өметләренә туры килмәвен, димәк, хатасын (гаебен) тануы.

Өстенлекле мәдәният — җәмгыятьнең күпчелек әгъзалары тарафыннан кабул ителгән кыйммәтләр, дини ышанулар, традицияләр һәм гореф-гадәтләр җыелмасы.

Парламент (ингл. parliament, франц. parler — сөйләү) — тулаем яки өлешчә сайлаулар юлы белән төзелгән, законнар чыгара торган югары вәкаләтле хакимият органы.

Патриархаль гаилә — ир кеше гаиләнең башлыгы булган һәм аның берничә буынын берләштергән зур гаилә.

Поп-мәдәният (поп-культура) — массакүләм, популяр мәдәниятнең сленгта аталышы.

Постиндустриаль җәмгыять — төп житештерүче көчләрен фән һәм яңа интеллектуаль технологияләр тәшкил иткән җәмгыять.

Күпчелек хезмәткәрләре хезмәт күрсәтүдә: сәүдә, финанс, транспорт, сәламәтлек саклау, ялны оештыру, фән, мәгариф өлкәсендә, хөкүмәт даирәләрендә мәшгуль.

Предприятие — законда билгеләнгән тәртиптә төзелгән мөстәкыйль хуҗалык субъекты.

Прогресс — җәмгыятьнең андагы уңай үзгәрешләр (алгарышлар) тискәреләреннән күбрәк булган үсеше.

Прогрессив салым — салым салына торган керемнең артуына бәйле рәвештә салым ставкаларын арттыру принцибына корылган җыем.

Процент — чит кешеләрнең акчасын яки капиталын файдаланган өчен түләү.

Расачыл изү — гражданнарның, этник төркемнең хокукларын милләтенә яки расасына карап системалы төстә кысу.

Рациональ (лат. rationalis — аңлы, ratio — аң) — акылга нигезләнгән, мантыйкый исбатлауларга, максатка яраклылыкка корылган.

Регресс (лат. regressus — кире кайту, кире чигенү) — начараю, түбәнрәк дәрәҗәгә төшү, үсешнең югарырак формадан түбәнгә тәгәрәве, артка чигенү; җәмгыятьнең тискәре үзгәрешләре уңайларыннан артып киткән үсеше; прогресның (алгарышның) киресе.

Рекрутинг (нем. rekrut — хәрби хезмәткә ялланган яисә анда берәр гаебе өчен алынган зат) — кадрлар, персонал сайлап алу системасы.

Респондент — сораштырулар уздырганда социологка җавап бирүче зат.

Республика (лат. respublica, сүзгә-сүз — җәмәгать эше) — ил белән халык яки махсус сайлау коллегиясе тарафыннан сайланган дәүләт башлыгы (мәсәлән, президент) идарә итү рәвеше; законнар чыгару хокукы сайланып куела торган вәкаләтле органга (парламентка) бирелә.

Ресурслар — акча, кыйммәтләр, запаслар, мөмкинлекләр, керем чыганаклары (мәсәлән, табигать ресурслары, икътисади ресурслар).

Ресурслар сирәклеге — аерым төр ресурсларның чикләнгәнлеге, аларның житештерү өлкәсе ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җитмәве.

Референдум (лат. referendum — хәбәр ителергә тиешле нәрсә) — гомуми тавыш бирү юлы белән законнар кабул итү яки дәүләт тормышының мөһимрәк мәсьәләләрен хәл итү формасы.

Рецидивист (лат. recidivus — кире кайта торган) – кабаттан җинаять кылган һәм элегрәк хөкемгә тартылган зат.

Ритуал (лат. ritualis — йолага караган нәрсә) — билгеле бер социаль һәм мәдәни кыйммәтләрне чагылдыручы йола төре, катлаулы символик гамәлләр рәвеше, билгеле бер тәртипкә салынган гамәлләр системасы.

Роль — кешенең үз-үзен тотышы моделе, статусның бер өлеше.

Рольләр күплеге — билгеле бер статус белән бәйләп карала торган рольләр җыелмасы (рольләр комплексы).

Рэкет — көчләү юлы белән (шантаж, куркыту, физик җәзалау) кемнән дә булса аның табышын тартып алу.

Сайлау хокукы — дәүләт башлыгын, вәкаләтле органнарны һ.б. сайлау тәртибен билгели торган хокукый нормалар җыелмасы.

Салымнар — дәүләт (хакимиятнең үзәк һәм җирле органнары) тарафыннан физик һәм юридик затлардан дәүләт бюджетына һәм җирле бюджетларга алына торган мәҗбүри түләүләр.

Сальдо (итал. saldo — исәп-хисап, калдык) — бухгалтерия балансында дебет һәм кредит суммалары арасындагы аерма.

Санкция (лат. sanctio — катгый карар) — уңай яки тискәре йогынты чарасы.

Сәнгать — 1) гомумән алганда нәфис сәнгать: кеше эшчәнлегенең әдәбият, архитектура, скульптура, рәсем, графика, декоратив-гамәли сәнгать, музыка, бию, театр, кино кебек дөньяны танып-белүнең художество образлары рәвешендә берләштерелә торган төрләре; 2) бары тик сынлы сәнгать кенә; 3) эшчәнлекнең теләсә кайсы өлкәсендә югары дәрәҗәдәге осталык.

Сепаратизм (лат. separatus — аерылган) — аерымлануга, ялгызлыкка омтылыш.

Сәясәт — асылы социаль агентларның (индивидлар, оешмалар, социаль төркемнәрнең) хакимлек итү һәм буйсындыру буенча үзара мөнәсәбәтләре тәшкил иткән иҗтимагый тормыш өлкәсе; әлеге мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә җәмгыятьтә билгеле бер социаль-сәяси тәртип урнаша, ә соңгысы исә, үз чиратында, бу мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Сәяси партия — социаль төркемнәр мәнфәгатьләрен чагылдыра һәм аларның активрак вәкилләрен берләштерә торган сәяси оешма.

Сәяси программа — җәмгыятьнең киләчәк төзелешен тасвирлый торган, хакимлек итүче хөкүмәтне тәнкыйтьләүне, халыкны бор-

чыган көндәлек социаль һәм икътисади проблемаларны чишү чараларын һәм механизмнарын чагылдыра торган нигезләмәләр җыелмасы.

Сәяси режим — дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру алымнары системасы, шәхеснең демократик хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру дәрәҗәсе, хакимиятнең үз эшчәнлеге хокукый нигезләренә мөнәсәбәте, рәсми конституцион һәм хокукый формаларның реаль сәяси тормыш белән нисбәте.

Сәяси философия — җәмгыятьнең идеаль төзелешенә карашлар системасы, үзенең тамырлары белән теге яки бу дөньякүләм сәяси системага — коммунизмга, социализмга, либерализмга, консерватизмга, фашизмга барып тоташа.

Символ — матди предметны алыштыра ала торган идеаль билге.

Сленг (ингл. slang) — инглиз телендә сөйләшүче илләрдә жаргон төшенчәсенә тәңгәл кулланыла; сөйләм теленең әдәби тел нормаларына туры килми торган варианты.

Социализм — иҗтимагый милеккә һәм икътисадны планлы җайга салуга нигезләнгән җәмгыять.

Социаль — күп кешеләрнең үзара эш итүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән иҗтимагый кыйммәт.

Социаль бүленеш — халыкның катлауларга бүленү процессы (һәм аның нәтиҗәсе).

Социаль институт (лат. institutum — урнаштыру, оештыру) — җәмгыятьнең аның мөһим ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җайлаштыру чарасы; социаль нормалар нигезендә җайга салына.

Социаль институтлар — уртак эшчәнлекне оештыруның нормалар, традицияләр, гадәтләр белән җайга салына торган, җәмгыятьнең фундаменталь ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән һәм тарихи урнашкан тотрыклы формалары.

Социаль инфраструктура (лат. infra — түбәнрәк, аскы һәм structura — төзелеш, урнашу) — социаль даирәнең (мәктәпләр, хастаханәләр, театр, стадионнар һ.б.) эшләве өчен кирәкле корылмалар, биналар, системалар һәм хезмәтләр җыелмасы.

Социаль программалар — халыкның матди яшәү мөмкинлекләре абсолют ярлылык чигендә яки аннан түбән, ягъни яшәү минимумы дәрәҗәсендә яки аннан да түбәнрәк булган аз керемле, картайган, эшсез, гарип һәм башка төркемнәрен яклау буенча дәүләт бюджетыннан финанслана торган чаралар.

Социаль төркем — социаль әһәмиятле критерийлар (җенес, яшь, милләт, раса, профессия, яшәү урыны, керем, хакимият, белем һ.б.) буенча аерып алынган кешеләр төркеме.

Социальләштерү агентлары — мәдәни нормаларга өйрәтү һәм социаль рольләрне үзләштерү өчен җаваплы кешеләр һәм учреждениеләр.

Социальләшү — мәдәни нормаларны һәм социаль рольләрне үзләштерүнең гомер буе дәвам итә торган процессы.

Статус — индивидларның төркемдәге яки җәмгыятьтәге социаль позициясе (хәле).

Стратификация (лат. stratum — катлау һәм ... фикация) — социаль катлауларның (төркемнәрнең) керемдә, белем дәрәҗәсендә, хакимлек итүдә, һөнәри абруйлылыкта тигезсезлек билгесе буенча өстән аска таба урнашуы.

Структура (төзелеш) — катгый урнашкан һәм үзара бәйләнешле элементлар җыелмасы.

Субмәдәният — гомуми мәдәниятнең бер өлеше, зур социаль төркемгә хас кыйммәтләр, традицияләр, гадәтләр системасы.

Суверенлык (дәүләт суверенлыгы) — аңа тулаем бөтен җәмгыять исеменнән эш йөртү, җәмгыятьнең бөтен әгъзалары мәҗбүри үтәргә тиешле норматив актлар һәм законнар чыгару, суд эшләре алып бару хокукы бирелүдә чагыла.

Сыйныф — кешеләрнең житештерү чараларына ия булган яки ия булмаган, иҗтимагый хезмәт бүленеше системасында билгеле бер урын тоткан һәм керем алуның үзенчәлекле ысулы белән характерлана торган зур социаль төркеме.

Сынлы сәнгать — пластик сәнгатьләрнең рәсем сәнгатен, сынлы сәнгатьне һәм графиканы берләштерүче бүлеге.

Табыш — товар сатудан аны җитештерүгә һәм сатуга тотылган чыгымнарга караганда артыграк файда алу.

Тантана (церемония) — символик мәгънәгә ия булган нинди дә булса вакыйгаларны яисә даталарны бәйрәм итүгә багышланган гамәлләр эзлеклелеге.

Тармак — бер үк төрле продукт җитештерә, охшаш технологияләр яки бер үк төрле чимал куллана торган фирмалар төркеме.

Ташлама — нинди дә булса өстенлекләр бирү, билгеләнгән кагыйдәләрне, бурычларны үтәүдән өлешчә азат итү яисә аларны үтәү шартларын җиңеләйтү, мәсәлән, салым ташламалары.

Тәкъдим — җитештерүченең (сатучынын) үз товарларын тәкъдим итү нияте.

Тәкъдим күләме — әлеге урында һәм әлеге вакытта сатучылар төрле бәя белән сатуга тәкъдим итә торган товарлар һәм хезмәтләр күләме.

Теләктәшлек — нинди дә булса фикерләргә һәм гамәлләргә эш белән теләктәшлек күрсәтү.

Тәңгәлләштерү (идентификация) (лат. identifico — тәңгәлләштерәм) — тиңдәшлекне тану; социологиядә: шәхеснең үзен башка кешеләр, төркем, үрнәкләр белән хисси дәрәҗәдә яисә башкача тәңгәлләштерүе.

Теология (грек. theos — Алла һәм ...логия) — үзе хакында кешегә вәхи (Алла тарафыннан пәйгамбәр күңеленә салынган фикерләр) аша гыйлем иңдерүче абсолют Алла концепциясе күздә тотылган дини тәгълимат; Алланың пәйгамбәр аша гыйлем иңдерүе (вәхи) анын әһәмиятле элементы булып тора

Тәүбә (исповедь) — христиан динендә: дингә ышанучы кешенең руханига үз гөнаһлары хакында сөйләве һәм әлеге руханиның Христос исеменнән үзен кичерүенә ирешүе («гөнаһларны ярлыкавына»).

Технология (грек. techne — сәнгать, осталык, кәсеп һәм ...логия) — продукция житештерү барышында чималны, материалны һәм ярымфабрикат әйберләрне эшкәртү, аларның халәтен, хасиятен, рәвешен үзгәртү ысуллары җыелмасы.

Тигезсез никах — ир белән хатынның нинди дә булса әһәмиятле билге — җәмгыятьтә тоткан урыны, яше, кереме буенча аерымлыгы.

Тигезсезлек — җәмгыятьнең дефицит ресурсларының — акчанын, хакимиятнең, белемнең һәм абруйлыкнын халыкның төрле катлаулары арасында тигезсез бүленүе.

Тинэйджер — 13 яшьтән 19 яшькәчә үсмерләр, яшь кешеләр.

Титуллар — аларга ия булган кешеләрнең хезмәттәге урынының һәм катлавынын, нәсел-нәсәбенең сүз белән билгеләнүе.

Титуллы этнос — исеме дәүләтнең исеме белән бердәй булган этник төркем.

Товар — хезмәт куеп, алмашу (сату) өчен җитештерелгән продукт.

Товар житештерми торган хезмәт — хезмәт күрсәтү.

Тормыш планы — алдагы тормышның идеаллаштырылган

күренеше, аның нигезен социаль карьераның фаразланган траекториясе һәм ихтимальй казанышларның суммасы тәшкил итә.

Тормыш рәвеше — кешеләрнең тормыш-яшәешенең, үз-үзләрен тотышының гадәткә әйләнгән ысулы.

Тоталитарлык (урта гасыр лат. totalis — бөтенләй, тулаем) — дәүләтнең, җәмгыятьнең барлык өлкәләренә тулы (тоталь) контрольлек итү, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне тулысынча бетерү, оппозициягә яисә башкача фикерләүләргә карата репрессияләр куллану рәвешләренең берсе.

Тотемизм (оджибве телендә «ототем» – аның ыруы) — борынгы җәмгыятьтә кешеләр төркемнәре һәм хайваннар арасындагы туганлык турындагы күзаллаулар белән бәйле инанулар һәм йолалар комплексы.

Төп статус — әлеге индивидка бик хас булган, тирә-яктагы кешеләр аны шуның буенча таный торган (яки тәңгәлләштергән) статус.

Традиция — элеккеге буыннардан мирас булып калган бар нәрсә.

Трансмилли — милләтара.

Триада — өч кешенең үзара актив мөнәсәбәте.

Тулы булмаган гаилә — ата-ананың берсе генә булган гаилә, ата белән ана аерылышкан яки икесенең берсе үлгән очракта хасил була.

Турыдан-туры салым — һәр гражданнан яки хуҗалык оешмасыннан аларның керемнәре күләме яки милекләре бәясенә бәйле рәвештә дәүләт файдасына алына торган җыем.

Үз-үзен яллаучы — бер үк вакытта ялланган эшче дә, милекче дә булып торучы зат.

Университет (лат. universitas — җыелма) — фундаменталь һәм күпләгән гамәли фәннәр, халык хуҗалыгының һәм мәдәниятнең төрле тармаклары буенча белгечләр әзерли торган югары уку йорты һәм фәнни учреждение.

Урбанизация — кешеләрнең шәһәрләргә күченүе һәм шәһәрчә яшәүгә омтылышның халыкның барлык катлауларына йоктырылуы.

Фактор (лат. factor — эшләүче, җитештерүче) — нинди дә булса процессның, күренешнең характерын яки аерым сыйфатларын билгели торган сәбәп, хәрәкәткә китерә торган көч.

Феминизм — хатын-кызларның ирләр белән тигез хокукларга ирешү өчен көрәшүе (хәрәкәте).

Фераль кешеләр — кешеләрдән аерым үскән һәм хайваннар арасында тәрбияләнгән кешеләр.

Фетишизм (фр. fetiche < португ. feitico — бөти; тылсым) — гайре табигый сихри көчкә ия дип уйланылган җансыз әйберләргә табыну.

Фирма (итал. firma) — юридик зат буларак хуҗалык эше алып баручы оешма.

Формаль — язылган кагыйдәләргә һәм законнарга нигезләнгән.

Фрустрация (лат. frustratio — уңышсызлык) — хәвеф тою хисе, чарасызлык, күңел төшенкелеге.

Функция — кемнең дә булса яисә нәрсәнең дә булса билгеләнеше, әһәмияте, башкара торган роле.

Хакимият — закон яки традицияләргә нигезләнеп йогынты ясау, ягъни закон яки гореф-гадәтләр кысаларында башка кешеләргә физик булмаган тәэсир итү, аларның теләкләренә бәйсез рәвештә башка кешеләргә үз ихтыярыңны яки карарларыңны көчләп тагу мөмкинлеге.

Халык — ыруг һәм милләт арасындагы урынны биләүче, тел һәм территория ягыннан, икътисади һәм мәдәни яктан тупланган берлек.

Халык мәдәнияте — һөнәри әзерлеге булмаган аноним иҗатчылар тарафыннан тудырылучы мәдәният.

Халыкның социаль составы — зур социаль төркемнәр җыелмасы.

Хәерчелек — иң чик ярлылык.

Хәерчеләр — бары тик физик ихтыяҗларын гына канәгатьләндерергә сәләтле, биологик тереклекләрен генә кайгыртучы, хәергә яшәүче кешеләр.

Хезмәт — товар җитештерү, хезмәт күрсәтү өчен кешенең энергиясен, вакытын һәм сәләтен файдалану.

Хезмәт күрсәтү — акча түләнү хисабына башкарыла торган файдалы эшчәнлек.

Хезмәт хакы — эшләнгән эшнең вакыт берәмлеге (атна, ай) белән үлчәнә торган бәясе; эшләнгән вакыт күләмен билгеле бер ставкага тапкырлап исәпләнә.

Хезмәт хокукы — хезмәт процессында һәм хезмәткә кагылышлы мәсьәләләр буенча эш бирүчеләр белән эшчеләр (хезмәткәрләр) арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салучы нормалар җыелмасы.

Хокук — кешенең үз-үзен тотышының дәүләт тарафыннан билгеләнгән яки рөхсәт ителгән гомуммәҗбүри кагыйдәләр (нормалар) җыелмасы.

Хокук нормасы — кешеләрнең үз-үзләрен тотышларында нинди дә булса хокукый хәл килеп туганда мәҗбүри башкарылырга тиешле билгеле бер кагыйдә.

Хокукый дәүләт — җәмгыятьтә законнарның өстенлеге, кеше хокукларын һәм ирекләрен саклау, халыкның яхшы яшәве турында кайгырту, халыкның аз керемле катлауларына актив ярдәм итү.

Хокукый сәләтлелек — кешенең хокукларга һәм бурычларга ия булуы.

Хокукый статус — кешенең хокуклары һәм бурычлары җыелмасы.

Хосусый милек — граждан яки юридик затның конкрет мөлкәткә ия булуы рәвешләренең берсе.

Цивилизация — 1) «варварлык»ка алмашка килгән тарихи чор; 2) кешелек үсешенең югары этабы; 3) мәдәни-географик берәмлек, мәсәлән, Көнчыгыш, Көнбатыш, Кытай цивилизацияләре; 4) планетаны колачлаган глобаль цивилизация.

Цивильлек (цивиль) — тәрбия аша мәдәни нормалар сеңдерү, мәдәниләшү.

Циклы эшсезлек — барлык тармакларда, өлкәләрдә, төбәкләрдә эшче көчләргә ихтыяҗның гомуми кимүе белән бәйле рәвештә вакытлыча эшсез калу.

Чагыштырма ярлылык — кешечә яшәү дәрәҗәсен, яки берәр җәмгыятьтә кабул ителгән билгеле бер тормыш стандартын саклау мөмкинлеге булмау.

Чимал — алга таба эшкәртелергә тиешле материаллар (мәсәлән, чыгарылган руда).

Чиркәү — 1) дин тотучыларның («тугрыларның») мистик берлеген аңлатучы христианлык өчен хас төшенчә; әлеге берлектә күмәк рәвештә кешенең Алла белән берләшү «тылсымы» (иң беренче чиратта евхаристия) башкарыла; 2) христианнар храмы; 3) теге яисә бу динне тотучыларның дини тәгълимат һәм культ уртаклыгына нигезләнгән оешмасы.

Читләтелгән салым — гражданнардан һәм хуҗалык оешмаларыннан алар тарафыннан билгеле бер гамәлләр кылынганда, мәсәлән, кайбер төр товарларны сатып алганда дәүләт файдасына алына торган җыем.

Чукындыру — христианлыкка кабул итү һәм беренчел гөнаһны чикләү инициациясе.

Шартнамә — кешеләр, оешмалар, дәүләтләр арасындагы килешү.

Шәхеснең хокукый культурасы — хокукның мәгънәсе һәм аны аңлау, шулай ук аларга нигезләнеп эш итү.

Шәхси статус — кешенең кече яки башлангыч төркемдә үзенең шәхси сыйфатлары ничек бәяләнүгә карап тоткан роле.

Шөгыль — хезмәт хакы түләнә яисә керем китерә торган эшчәнлек төре яисә башкарыла торган эш.

Эгоистлык (франц. egoisme, лат. ego дан — мин) — үз-үзеңне ярату; кешенең үз файдасын гына кайгыртып гамәл кылуы, үз мәнфәгатьләрен башкаларныкыннан өстен кую.

Элитар мәдәният — җәмгыятьнең өстенлекле өлешендә тудырыла торган мәдәният; кагыйдә буларак, ул читләр өчен аңлаешсыз була.

Эмиграция (лат. emigro — күченәм) — сәяси, икътисади яки башка сәбәпләр аркасында гражданнарның үз илләреннән читкә даими (яки озак вакытка) яшәргә китүе.

Эмиссия (лат. emissio — чыгару) — банк яки казначылык билетларын, кәгазь акчаларны һәм кыйммәтле кәгазьләрне әйләнешкә чыгару.

Эскапизм (ингл. escape — качу, качып котылу) — кризис, көчсезлек, чарасызлык шартларында шәхеснең чынбарлыктан хыял, уйдырма, фантазия дөньясына качып котылырга тырышуы.

Этикет — аерым социаль даирәләрдә кабул ителгән бербөтен тәртип кагыйдәләре.

Этник кушылу — күп буыннар дәвамында төрле этник төркемнәрнең милләтара никахлар аша стихияле төстә кушылуы һәм бер милләт барлыкка килү.

Этнос (грек. ethnos — кабилә, халык) — кабилә, халык яки милләт барлыкка китерүче кан-кардәшләр төркеменең гомумиләштерелгән исеме.

Этноцентризм — үз мәдәниятеңне дөрес дип тану, башка мәдәният стандартларын ялгыш дип карау.

Эш — билгеле бер түләү хисабына башкарыла торган эшчәнлекнең теләсә нинди төре.

Эш башкаручы (җитештерүче яисә эшләп, әзерләп бирүче) — эшмәкәрлек статусына ия булган оешма яисә граждан.

Эшкә урнашу — эш эзләү һәм эшкә урнашу.

Эшмәкәр — предприятие хуҗасы, табыш алу нияте белән шәхси яки бурычка алып торган акчалары ярдәмендә яңа эшкә нигез салучы.

Эшмәкәрлек — товарлар җитештерү һәм хезмәтләр күрсәтү өчен шәхси яки бурычка алып торылган акча исәбенә хуҗалык оешмалары (фирмалар) булдыру һәм шул нигездә керем алу.

Эшсез — хезмәт хакы алмаучы, эшсезлек буенча пособие дигән махсус пособиегә яшәүче кеше.

Эшсезлек — хезмәткә яраклы һәм эш яшендәге кешеләрнең иҗтимагый җитештерүдә катнашмавы.

Эшсезлек дәрәҗәсе — эшсезләр санының хуҗалыкта мәшгуль кешеләрнең гомуми санына нисбәте.

Юньле яшәү дәрәҗәсе — кешенең җитәрлек дәрәҗәдә уңайлы тормыш рәвеше алып баруы, үзен кимсетелгән дип тоймавы, аның акылга сыярдай бөтен ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлеге бирә торган матди байлыклар күләме.

Ябык җәмгыять — түбән дәрәҗәдән югары дәрәҗәгә социаль юллар буенча күчү тулысынча тыелган яки шактый чикләнгән җәмгыять.

Ял — буш вакытның кеше үзенчә файдалана торган бер өлеше.

Яллы хезмәт — хезмәткәрнең үзе милекче булмаган предприятиедә яллану шартнамәсе нигезендә эшләгән эше.

«Яңа руслар» — безнең илдә базар мөнәсәбәтләре хөкем сөргән елларда барлыкка килгән эре, урта һәм вак буржуазия.

Ярлылык — акчасы, белеме, хакимлеге һәм абруе минималь булган кешеләрнең икътисади һәм социаль хәле. Ләкин ярлылык мәдәни күренеш тә әле ул.

Ярлылык чиге — иң аз керем сыйфатында рәсми төстә расланган акча суммасы (мәсәлән, долларлар яки сумнар белән исәпләнә), шуңа индивид яки гаилә азык-төлек, кием-салым, торак ала. Аны шулай ук «ярлылык дәрәҗәсе» дип тә атыйлар. Россиядә ул *яшәү минимумы* дигән өстәмә атама да алды.

Яшелчәчелек — кыргый үләннәр җыюдан бөртекле культуралар игүгә системалы күчү рәвеше.

Яшәү минимумы — фәнни күзлектән караганда, кешенең минималь ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җитәрлек товарлар һәм хезмәтләр (реаль сатып алу бәяләрендә) җыелмасы.

Учебное издание

Кравченко Альберт Иванович
Певцова Елена Александровна

ОБЩЕСТВОЗНАНИЕ

Учебник для 11 класса

(перевод с русского на татарский)

Редакторы *Р.С.Вафина*
Корректоры *Ә.Ф.Әхмәдуллина*
Компьтерда биткә салучы *Э.И. Уракова*

Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты.
420111, Казан, Тельман ур., 5.
Хатлар өчен: 420014, Казан, Кремль, а/я 54.
Тел./факс: (8432) 264-67-96

Оригинал-макеттан басарага кул куелды 30.09.10. Форматы 60x90 1/16.
Офсет кәгазе. «Таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 11,5.
Тиражы 4030 д. Заказ О-1385.

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы –
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

«РУССКОЕ СЛОВО»
«ХӘТЕР»